Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 11 (1427) 24 март 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

6

Татарстан башкаласында узган татар эшмәкәрләре жыены милләтебезнең булдыклы ир-егетләре, ханымнары өчен янә горурлык хисе уятты.

12

Магнитогорскидагы иң куәтле металлургия комбинатын да, шәһәр нигезен дә безнең кыерсытылган, бихисап газап кичкән татар төзеп бирә.

24

К.Тинчурин театрының «Аферист» спектакле һич тамыры корымый торган караклык, ялагайлык, ришвәтчелек проблемаларын үзәккә куя.



Калебләргә сәмави нур өстәр Рамазан-шәриф айлары!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендә XVIII гасырда төзелгән ташландык төрмә бинасыннан мәдәни үзәк ясарга ниятләнә.
- Удмуртиянең Воткинск шәһәрендә Татарстан әдипләре катнашында шагыйрь Риза Шәфинең 100 еллыгына багышланган шигърият бәйрәме булды.
- Испаниянең Каталония провинциясендәге Льорет-де-Мар шәһәрендә Пиреней ярымутравы территориясендәге татар-башкорт ассоциациясе эшли башлады.
- «Апуш» татар балалар театр студиясе 26 мартта 9-15 яшьлек балалар һәм үсмерләр арасында өстәмә кастинг үткәрә.
- Россия империясе башкаласында Җәмигъ мәчете төзелү һәм анда беренче гыйбадәт кылуны искә алып, Санкт-Петербургта «Мөселманнарның Россиядәге роле: тарих һәм перспективалар» дип аталган фәнни-гамәли конференция узды.
- Әүвәл Татарстанның Конституция суды рәисе вазыйфаларын башкарган Фәрхәт Хөснетдинов Болгар ислам академиясенең яңа ректоры итеп билгеләнде.
- Свердловск өлкәсенең Әрәкәй авылы милли-мәдәни комплексында Сәрдәрия Нигъмәтова исемендәге XIII халыкара татар халык иҗаты конкурсы узды.
- Балтач районы Чепья авылында урнашкан «Халыклар дуслыгы» музееның директоры, сугыш ветераны Гарифҗан Галиев 96 яшендә вафат булды.
- Режиссер Айдар Җаббаров Россия Президентының яшь мәдәният әһелләренә бирелә торган премиясенә лаек булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Гүзәл СӘГЫЙТОВА, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары:

«XX гасыр башында да ул бинада (Тинчурин театрында) бер көнне опера уйнаганнар, икенче көнне – драма спектакле... Тарихи яктан да бик туры килә кебек. Ләкин бүгенге көндә бу бина музыкаль театр таләпләренә туры килми. Аның өчен яңа театр, яисә инде опера һәм балет театрының киңрәк эшли башлавы кирәктер. Якын киләчәк турында сөйләшәбез икән, соңгысы бүгенге вәзгыятьтә чынбарлыкка якынрак. Финанс ягыннан «каешларны кыскан» чорда яңа театр ачылуга ышаныч аз».

СЫНАМЫШЛАР

Кар кояштан эресә – ашлык уңа, яңгырдан эресә – корылык көтелә ● Акчарлаклар килгәч, елгада боз кузгала ● Кар барында күк күкрәсә, ашлык уңмас ● Боз тиз эреп бетсә, уңыш яхшы була ● Торналар килгәч, җылыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 38 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 04 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 26 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **31 мартта 12 сәгать 59 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

24 март – язучы, әдәбият галиме Мөхәммәт Вәли улы Гали (Галиев)нең тууына 130 ел (1893–1952).

25 март – язучы, Татарстанның атказанган икътисадчысы Таһир Нәбиулла улы Нәбиуллинның тууына 90 ел (1933–2009).

26 март – язучы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Роберт Мөхлис улы Батуллинга 85 яшь (1938).

29 март – скульптор, Татарстанның халык рәссамы Садри Сәлах улы Ахунның тууына 120 ел (1903–1987).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(15-21 март)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 2 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ



Чылбырны кем тоташтырыр?

Бүгенге өлкән буынның күбесе бала чакларында әби-бабалары тәрбиясендә үсте. Әти-әниләре көне буе эштә булды. Әби-бабайлар оныкларын ашатты, хәреф танырга, яшәргә өйрәтте, аларның киләчәгенең нигезен салды. Мондый хәлгә бераү дә зарланмады, ризасызлык күрсәтмәде. Кулларын юмыйча, бисмилла әйтмичә берәү дә өстәл артына утырмады. Әби-бабайга булышуны бала-чага бурыч дип санады. Өй эшләрен бергәләп башкардылар. Эштән кайтканда әти-әниләрен чип-чиста өй, өстәл тулы ризык каршы алды.

Хәзер әби-бабайларның күпчелеге авылда да, шәһәрдә дә балаларыннан, оныкларыннан аерым яши. Алар әби-бабайлар янына бары тик каникуллар вакытында гына килә. Анда да әле хәзерге балалар сыйланып ял итүдән башканы белми. Хәзер гаиләләрдә дә, мәктәпләрдә дә тәрбия бирү икенче планга калды шул.

Галимнәр һәм укытучылар арасында бүгенге мәгариф системасын консерватив дип санаучылар бар. Бер дәреслек языла да балалар еллар дәвамында шуның буенча укый. Ул дәреслекләрнең эчтәлеге искерә, тормыш бер урында гына таптанмый бит. Яшәү, эш шартлары үзгәрә, производствого яңа эш алымнары кертелә. Ә менә мәгариф һәм тәрбия тормыштан артта кала.

Шактый илләрдә 20-30 ел саен мәгариф системасына реформа ясыйлар. Бу бик табигый хәл. Бездә дә 1958 елда мәктәпне тормыш һәм хезмәт белән бәйлибез дигән тезис нигезендә реформа эшләтеп җибәрелде. Производствого өйрәтү цехлары төзү, мәктәпләрне завод-фабрикаларга беркетү аша балаларга хезмәт тәрбиясе бирә башладылар. Ләкин балалар эшче яшьләр белән аралашып, шул тормышның кыйммәтләрен үзләштерә башлагач кына: «Ничек инде минем улым көне буе пычрак токарьлар, слесарьлар арасында йөрсен» – дип реформа хәрәкәтенә таяк тыгучылар булды. Шул рәвешле әһәмиятле башлангыч таркалды, юкка чыкты.

Яңа мәктәп биналары төзү, классларны яңача җиһазлау, яңа дәреслекләр чыгару, укытучыларның белемен күтәрү, мәгарифне финанслау ил белән Никита Хрущев җитәкчелек иткән заманда ныклап яхшыра башлады. «Мүкләнеп яткан мәктәп системасы урыныннан кузгалды», – дигән иде 2001 елны республиканың мәгариф министрлыгын 17 ел җитәкләгән Мирза Мәхмүтов. Мирза әфәнде – заманында мәктәптә проблемалы укыту идеясе белән илне шаулаткан галим. Әлеге идея нигезендә укучы баланы үзлегеннән фикерләргә өйрәтү идеясе ята. Бу идея мөстәкыйль фикер йөртүне беренче планга куя. Кызганыч, бүгенге Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгының илнең башка төбәкләренә әллә ни яңалык тәкъдим иткәне юк шул.

Балаларга әхлакый тәрбияне дөрес бирү өчен мохитебезне, яшәү рәвешебезне үзгәртү зарур. Бүген күп кенә гаиләләр акчасын очын-очка ялгап яши. Торак-коммуналь хезмәтләр, азык-төлек, кием-салым, дарулар, бензин бәяләре көннән-көн артып тора. Фатир алырга теләсәң, кредитсыз булмый. Дәвалану, белем алу, һөнәр үзләштерү дә нигездә түләүлегә әверелеп бара. Хәерчелек белән имансызлык – әхлаксызлыкның төп сәбәбе. Халык үзенең тотрыклы киләчәген ачык күрмәсә, диңгез дулкынындагы йомычка шикелле чайкала башлый. Нинди генә матур вәгъдәләр бирсәләр дә, аларга ышанмый.

Коммунистлар тырыша-тырыша наданлыкны, укый-яза белмәүчеләрне бетерде, демократлар исә һәркемгә ирек куйды. Теләсәң – укы, теләмисең икән – синең үз эшең. Матбугат хәбәрләренә караганда, Россиядә мәктәп яшендәге миллионга якын бала укый-яза белми. Мәктәпкә йөрүче балаларның да шактый өлеше тиешенчә укымый, селкенеп кенә йөри. Өендә дә дәрес хәзерләп көчәнми, телевизор карап, интернетта уйнап вакытын үткәрә.

Элек авыл мәктәпләренең, хәтта шәһәр мәктәпләренең дә җиләк-җимеш, яшелчә үстерү кишәрлекләре, теплицалары бар иде. Балалар анда чиратлашып эшләде, хезмәт күнекмәләренә өйрәнде. Класс бүлмәләрен дә бер дә иренмичә җыештырдык. Хәзер мондый тәртип тә бетерелде. Янәсе, мәктәп ул – белем алу урыны, бөтен вакыт белем үзләштерергә бирелергә тиеш. Хезмәткә өйрәтү дә укытуның бер төре бит югыйсә. Ул кеше хәтерендә гомер буе сакланачак.

Бүген мәктәп эшчәнлегенә бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләреннән чыгып бәя бирелә. Укучылары күп балл җыйган укытучы иң сәләтле санала, бүләкләргә лаек була. Ата-аналар да балаларының бердәм дәүләт имтиханын яхшы бирүе өчен тырыша. Чөнки шунсыз ул югары уку йортына кабул ителми. Тәрбия бирүне арткы планга күчергән, балаларның психикасына авыр йогынты ясый торган бердәм дәүләт имтиханын һәм балл системасын гамәлдән чыгарырга күптән вакыт.

Икенче чиккә тайпылышлар да көчәеп китте. Совет чорын, аның җитәкчеләрен сүгү гадәткә кереп керде. СССРга нигез салучы В.И.Ленинның уңай якларын бөтенләй телгә алмаска тырышалар. Ульяновск шәһәрендә элеккеге исеме – Семберне кире кайтару турында бәхәсләр барды. Социализмнан кабат капитализмга күчү чорында Ленинград Санкт-Петербургка әйләнде. Өлкә үзәкләре атамаларындагы Свердловск, Куйбышев, Горький исемнәре дә алыштырылды. Казанда да Ленин исемен юкка чыгару буенча даими эш бара. Ленин районы юкка чыкты. Ленин урамы Кремль урамына әйләнде. Хәтта Идел буе федераль университеты оештырылганда уку йорты исеменнән «Ульянов-Ленин исемендәге» дигән сүзләр дә алынды.

Мондый хәл бигрәк тә өлкән буында ризасызлык уята. Дөрес, совет чорындагы җитәкчеләрнең хаталары да аз булмады. Революциядән соң ук кулак тамгасы тагып бик күпләрнең сөргенгә җибәрелүе, бөтен милекләрен тартып алу, үз фикерләре булган төрле тармактагы белгечләрнең «халык дошманы» дип атып үтерелүе, аерым кешеләрне генә түгел, тулы бер милләтләрне юк итү сәясәте һәм башка фаҗигаләрне һич кенә дә инкяр итеп булмый.

Дингә каршы көрәш, дин әһелләрен җәзалау, гыйбадәт йортларын туздырып ташлауны халык бик борчылып, нәфрәтләнеп кабул итте. Ләкин дин тәртип урнаштыра, аны бозмагыз, кешене кимсетмәгез, тәмәке тармагыз, сугышмагыз, сүгенмәгез дигән лозунгларны гына булса да хөрмәт итәргә кирәк иде.

Шулай да совет чорындагы һәр гамәлне кара чүпрәккә төреп күрсәтү белән килешеп булмый. Мин кечкенә генә авылдан килеп, зур конкурсны үтеп, бернинди блатны белмичә университетка кердем. Стипендия түләделәр, тулай торакта урын бирделәр. Практика үткәндә үк диплом алгач кайда эшләячәгебез билгеле иде, шул исәптән булачак хезмәт хакыбыз да. Ә хәзер баласын укыту өчен әти-әнинең ярты хезмәт хакы китеп бара. Институт бетергән белгеч эш таба алмый интегә, базарга барып сату итәргә керешә.

Хаталанулардан сакланырга чакыручы тагын бер мисал. Үткән гасыр ахырында колхоз-совхозларны таратып бетерделәр. Янәсе капиталистик системада алар була алмый. Авылны тулаем фермер җилкәсенә салырга тырыштылар. Ә фермер бу йөкне тулы күләмдә күтәрә алмады. Халыкның шактый өлеше эшсез калды, шунлыктан шәһәрләргә агылды. Авыллар бушап калды.

Акыл белән эш итүчеләр дә табылды. Мәсәлән, Әтнә районы җитәкчеләре бер генә колхозны да таратмады. Биредә хәзер теге яки бу тармак өчен белгечләр эзләп тә интекмиләр. Шушы авылда туып-үскән егет яки кызны хуҗалык исәбенә укырга җибәрәләр. Ул диплом алгач, аны кочак җәеп каршылыйлар, эшләү өчен бөтен шартларны тудыралар. Колхозларны җимереп заманга яраклашмаса да, Әтнә районы – республикада күп тармак буенча алдынгы. Биредә продукция дә мул җитештерелә, халыкның тормыш-көнкүреш шартлары да начар түгел.

Булганны җимереп ташлау ансат. Моның өчен баш ватып уйланасы да, акча туздырасы да юк. Соңгы елларда халык өчен бик кирәкле товарлар җитештерүче предприятиеләр юкка чыкты. Казанда гармун фабрикасын, «Сантехприбор», «Урак һәм чүкеч» заводларын, Арчада милли аяк киемнәре фабрикасын, дистәләрчә башка предприятиеләрне бетерделәр. Мондый гамәлләре өчен бер генә җитәкче дә җавапка тартылмады. Ә менә юк ителгән предприятие милкен үз кесәләренә салып куючы җитәкчеләр турында сүзләр тынып тормый.

Шулай да эшчеләр дә, җитәкчеләр дә һәр эшкә бергәләп, җиң сызганып керешсә, уртак максат куеп тотынса, һәркем канәгать калырлык нәтиҗәгә ирешеп була дип саныйм. Өзелгән чылбырны бергәләп тоташтырырга кирәк.

Мәҗидетән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ДӘРТ ҺӘМ ДӘРМАН

Җиһанда купкан һәм күп кенә хокукый киртәләрне җимергән геосәяси өермә белән бәйле билгесезлек шартларында, башка халыклар кебек үк, татар милләте дә бүген җиде юл чатында басып тора. Әмма, күпләрдән аермалы буларак, ул үз язмышында ни язылганын һич кенә дә онытырга җыенмый һәм метасәяси кыйбласын да төгәл белә. Иҗтимагый фикер йөртү дәрәҗәсе исә аның үзенә йөкләнгән илаһи миссияне дә дөрес аңлавын күрсәтә кебек. Тик шулай да, бүгенге рухи деградация чорында дәһрилек чытырманлыгында адашканнарга хак юлны төгәл күрсәтеп, үзенә йөкләнгән илаһи миссияне үтәүгә бердәм рәвештә алынырга татарның тәвәккәллеге әлегә җитми. Юкса, моның өчен аның бүген бөтен мөмкинлекләре дә бар кебек һәм узган язмаларыбызда ул хакта дәлилле сөйләшү инде булган иде. Әмма милләт яшәешендә аны изге эшләргә рухландыра торган җитди үзгәрешләр, яисә гамәл-фигылендә югары максатчанлык әлегә күренми. Гамәлсез гыйлем – җансыз тән, ди мәкаль. Шуңа күрә бүгенге сәер халәтебез сәбәпләренә инде бераз тәфсиллерәк тә тукталып үтик.

Фикер сөрешебез бу юлы милләт яшәешендә дәрт вә дәрман нисбәте турында булыр. Мәгълүм булганча, «дәрт» сүзе рухи күтәренкелек, омтылыш һәм рухи көч халәтен аңлата. Дөрес, аның бүтән мәгънәләре дә бар. Безнең очракта исә сүз иң элек яшәү дәрте хакында бара, чөнки ул үз эченә бу кәлимәнең барлык мәгънәләрен дә сыйдыра. «Дәрман» төшенчәсе инде адәми затның рухи һәм физик мөмкинлекләрен, көч-куәт вә егәрен, аның физиологик, рухи, матди һ.б. халәтен дә билгеләрә. Татарда бу сүзләрнең кулланышы ни өчендер күбрәк, «дәрт бар, дәрман юк» гыйбарәсе рәвешендә гадәткә кергән. Тарихи яктан бу, күрәсең, аның аңында үз дәүләтчелеген югалткач урнашкан рухи халәт вә физик мөмкинлекләре белән дә бәйледер. Әмма бүген инде җиһанда геосәяси вәзгыять тамырдан үзгәрде һәм кешелек дөньясы яшәешнең хәлиткеч этабына керде. Аның өчен үз киләчәген ышанычлы итүнең бер генә юлы калды: илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү. Ә илаһи миссияле милләт өчен бу инде аның төп җаваплылык чоры җитүен дә аңлата. Чөнки, чыннан да, язмыш аны моңа күп гасырлар дәвамында әзерләгән. Ул әзерлекнең төп этапларын янә бер кат барлап чыгыйк.

Тәкъдирнең иң зур бүләге – халкыбызның Урталык җирләрендә бар ителүе һәм аңа Дала хуҗасы булу мөмкинлеге бирелүе. Борынгы бабаларыбызга җиһангирлык һәм дөньяда тиңе булмаган (үз чоры өчен алдынгы, гадел принципларга корылган) көчле дәүләтләр кору сәләте бирелүе дә хак. Ә татар теленең Урталык җирләрендә күп гасырлар дәвамында һәм табигый рәвештә халыкара аралашу теле булып хезмәт итүе – үзе бер могҗиза. Иллә мәгәр, милләт тарихында фаҗигале этаплар да җитәрлек: тәкъдирнең дан-шөһрәт белән сынавын элгәрләребезнең уңышлы үтә алмавы; көчле дәүләтләрнең эчке каршылыклар һәм илаһият кануннарыннан тайпылу нәтиҗәсендә эчтән җимерелүе һәм таркалуы; шундый ук сәбәпләр аркасында татар ханлыкларының отыры тыштан җимерелүгә дә дучар ителүе; тәкъдирнең инде татар халкын дәүләтсезлек шартларында да сынавы һәм моның фаҗигале нәтиҗәләре. Боларны, әлбәттә, миссияле милләтне төп сынауга әзерләү этаплары дип тә карарга кирәк. Әмма күп гасырларга сузылган дәүләтсезлек шартларында да татар үзенең телен һәм асыл сыйфатларын саклап кала алган һәм үз дәүләтчелеген торгызу өчен көрәшен туктатмаган. Ислам варисы буларак, аңа хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлау сәләте бирелүен дә онытмыйк. Әлбәттә, югарыда әйтелгәннәр һәм милләтнең рухи яңарыш та кичерүе аның үзенә йөкләнгән илаһи миссияне үтәү өчен рухи әзерлеге җитәрлек булуы турында сөйли.

Димәк, төп эштә бүген инде аның «дәрманы бар, дәрте юк» булып чыга. Сизелә ки, моның сәбәпләре күбрәк субъектив өлкәдә ята. Ә төп сәбәп – кешенең чор янауларын җитди кабул итмәвендә. Күпләр исә, «миннән генә бер нәрсә дә тормый, башкалар ничек – мин дә шулай» рәвешендә дә фикер йөртергә күнеккән. Тора икән шул! Бүгенге хәтәр хәлләр өчен дә җаваплылык һәммәбезгә дә төшә. Киләчәктә вәзгыять әле тагы да катлауланырга мөмкин. Ә милләт миссиясенә килгәндә, ул бик тә гади нәрсәләргә кайтып кала: илаһият кануннары буенча (киң мәгънәдә) яшәүне үзеңнән һәм гаиләңнән башла; бу эшкә бүгеннән үк һәм аңлы рәвештә алын, юкса, синнән башка моны беркем дә эшләмәячәк; хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы югарылыгында аңларга тырыш, башкаларга да аңлат һәм, шул нигездә, Аллаһ юлында иҗтиһат кыл; башкалар өчен үрнәк һәм әйдәп баручы көч булуны максат ит. Зурдан алганда, язмыш татарга бүген үзенең һәм башка халыкларның киләчәген ышанычлы итүдә универсаль ысул, тәкъдири мөмкинлек һәм тарихи шанс та бирә. Аллаһ ихтыяры вә кодрәте белән мәрхәмәт ителгән мондый мөмкинлек өчен Аңа рәхмәтле булыйк!

Фоат УРАЗАЙ.

Татар китаплары күргәзмәдә

Бу атнада XXX Минск Халыкара китап күргәзмә-ярминкәсе эшли башлады. Белоруссия башкаласының «БелЭкспо» Күргәзмә үзәгендә уза торган бу күргәзмә-ярминкәнең «Россия стенды»нда илнең 14 нәшрияты үз китапларын тәкъдим итә. Алар арасында «Татарстан китап нәшрияты» басмаларын да күрергә мөмкин.

«Татарстан китап нәшрияты»ның баш редактор урынбасары Венера Шәмсетдинова хәбәр иткәнчә, Минск Халыкара китап күргәзмә-ярминкәсендә беренче генә катнашулары түгел. 2019 елда Белоруссия китап сөючеләренә татар халкының бай әдәбияты белән танышу мөмкинлеге тудырылган булган. Быел «Татарстан китап нәшрияты» Минскига иң яхшы басмаларын – тарихи, туган якны өйрәнүгә кагылышлы әдәбият классик язучыларыбыз әсәрләрен, татар теленә үзөйрәткечләр, сүзлекләр, балалар китапларын, бүләк-басмалардан тупланган төрле жанрдагы 200 ләп китап алып барган.

«Күргәзмә-ярминкә гөрләп тора. Ике сәхнәдә алтмышлап чара уза. Аларда яңа китапларны тәкъдим итәләр, Россия һәм Белоруссия язучылары белән очрашулар оештырыла, тәҗрибә уртаклашулар, түгәрәк өстәлләр, әдәби укулар бара, әдипләр, наширлар халык алдында чыгышлар ясый. Күргәзмәгә килгән балалар өчен дә кызыклы чаралар, осталык дәресләре үткәрелә, аларга күпсанлы мавыктыргыч, заманча эшләнгән, төсле китаплар тәкъдим ителә. Күргәзмәдә татар әдәбияты белән дә кызыксыну күрәбез. Безнең стендлар янында һәрвакыт халык. Без үз продукциябезне генә тәкъдим итеп калмыйбыз, үзара тәҗрибә уртаклашабыз, тегеяки бу нәшриятның алдынгы алымнарын күреп, аларны үзебездә булдырабыз», – диде В.Шәмсетдинова.

Сөембикә КАШАПОВА.

Көтектә – яңа мәчет



Арча районы Көтек авылында яңа мәчет ачылу тантанасы узды. Әлеге күркәм чарада катнашучыларны Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе Ренат Гатиятов һәм башкалар тәбрикләде. Мәчет ел ахырына төзелеп бетсә дә, рәсми ачылыш тантанасы рамазан-шәриф аен каршы алып үткәрелде.

Көтек авылының яңа гыйбадәтханәсе борынгы мәчет урынында, авылның иң матур җирендә төзелде. 2021 елның май аенда мәхәллә халкы җыелышы уза. Мәчет төзелешенә Көтек авылы фермеры Дамир Зәкиҗанулы Шакирҗанов алына. Шул ук елны июнь аенда мәчет төзеләчәк урында кое казыла, саф чишмә суы табыла, халык аның суын яратып өлгерә, нәтиҗәдә коены мәчет эченә кертеп, елның теләсә кайсы вакытында су алырга уңайлы булырлык итеп калдыралар. Мәчеттә су булу авылны да күпмедер дәрәҗәдә сусызлыктан коткарачак, чөнки йортларга су кертелмәгән.

Яңа мәчеткә исә берьюлы 60 кеше кереп намаз укый ала. Барлык уңайлыклар тудырылган тәһарәтханәсе көйләнгән. Биредә дин дәресләре алып бару мөмкинлеге бар, хәзерге вакытта хатын-кызлар өчен якшәмбе көннәрендә дәресләр оештырыла. Кызганыч, бу авылда мәктәп, балалар бакчасы, клуб биналары төзексез хәлдә, алар эшләми. Яңа мәчет исә яшен-картын намазга чакырып, берләштереп торачак.

Хәзерге вакытта мәчетне газга тоташтыру ихтыяҗы бар. Мәчет бинасы бүген электр белән җылытыла.

Эльмира СИРАҖИ.

Актанышта әдәби бәйрәм

Актаныш дәрәҗәле һәм мәртәбәле әдипләрне, кендек каннары монда тамган абруйлы өлкән каләмдәшләрен кабул итте. Делегацияне Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла җитәкләде.

Әдәби десант составында Мөхәммәт Мирза, Рөстәм Галиуллин, Факил Сафин, Газинур Морат, Нурфия Йосыпова, Әлфия Ситдыйкова, Лилия Фәттахова, Лилия Габидуллина, Айгөл Әхмәтгалиева, Айзирә Имамова кебек әдипләр һәм каләм әһелләре бар иде.

Республикада соңгы елларда дәүләт һәм туган телләрне саклау һәм үстерүгә аеруча зур игътибар бирелә. Бу максаттан Актанышның сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатында һәм башка мәктәпләрдә язучылар һәм шагыйрьләр укучыларга әдәби дәрес бирде.

Аеруча сөенечле вакыйга: Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, шушы районда туып-үскән Мөхәммәт Мирза исемендәге шигърият һәм татар теле бүлмәсе ачылды. Тантанада Актаныш районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дилбәр Әнвәрова, социаль һәм агарту бүлеге җитәкчесе Назил Латыйпов, мәгариф идарәсе җитәкчесе Раниза Шакирова да катнашты.

Алга таба әлеге әдәби-мәдәни тантана районның уку йортлары китапханәчеләре катнашындагы педагогик конференция белән дәвам итте. Җыенда бик күп көнүзәк мәсьәләләр күтәрелде, мәктәп программасындагы нәфис әдәбиятнең һәм китап-әсбапларның әчтәлегенең камиллеге буенча да фикерләр яңгырады. Түгәрәк өстәл эшен халык укытучысы, татар теле һәм әдәбияты мөгаллимәсе Ләйсән Әминова алып барды.

Әдәбият бәйрәме, Ә.Авзалова исемендәге Актанышның мәдәният учагында күренекле язучы, шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның зур иҗат кичәсе белән дәвам итте.

Юлай НИЗАЕВ.

1 нче биттә – Казанның Залесный бистәсендә урнашкан Әхмәдзәки Сафиуллин исемендәге мәчеттә 2022 елгы Ураза гаете намазыннан күренеш. Фото: rais.tatarstan.ru

Аксакаллар сәфәрдә

Татарстан мөфтиятенең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов җитәкчелегендә республика аксакаллары Әтнә, Арча, Кукмара районнарындагы дин-туристлык маршрутлары буенча күчмә киңәшмә узды. Әлеге маршрутлар борынгы мәчет биналары белән танышу, татар дин әһелләре һәм галимнәренең исемнәре белән бәйле урыннарда булу, милләт зыялылары җирләнгән каберлекләргә барып дога кылуны күздә тотты. Аксакаллар мәчет-мәхәлләләр катнашында татар-мөселман үзенчәлекләрен саклау буенча тәҗрибәне өйрәнде, рухи мирас һәм дини шәхесләрнең тормышын, иҗатын барлау үзәкләрендә, музейларда булды, махсус оештырылган күргәзмәләрне карады. Аксакалларның Казан арты районнарына эш сәфәренең төп максаты – халыкны, аеруча яшьләрне истәлекле урыннарга җәлеп итү һәм Татарстанның башка районнарында да ислам дине тарихы белән тыгыз бәйле урыннар буенча маршрут төзү мөмкинлекләрен өйрәнүдән гыйбарәт.

Аксакаллар беренче эш итеп Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылында реставрациядән соң ачылган таш мәчетне һәм шунда ук урнашкан музейны карады. Әлеге гыйбадәт йорты Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, 1769 елда салынган Казан читендәге иң беренче таш мәчет булуы белән үзенчәлекле. Ул, төзекләндерелеп, 2020 елның декабрендә ачылды. Әтнә районы имам-мөхтәсибе Наил хәзрәт Сәгъдиев һәм Түбән Бәрәскә авылы таш мәчетенең имам-хатыйбы Рамазан хәзрәт мәчетнең тарихы турында сөйләде, аны төзекләндерү этаплары белән таныштырды. Аннары Олы Әтнә авылы мәчетендә район башлыгы Габделәхәт Хәкимов белән очрашу узды.

Алга таба Татарстан аксакаллары Арча шәһәрендә Г.Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәгендә һәм Яңа Кырлай авылында урнашкан Г.Тукай музей комплексында булып киттеләр.

Икенче көнне кырыктан артык аксакал Кукмара районы Мәчкәрә авылына сәфәр кылды. Биредә кунаклар бай тарихи дини мираска ия булган Мәчкәрә авылының иске зиратында сакланучы кабер ташларын зиярәт итте, Коръән укып дога кылды, төзекләндерү эшләре башланган борынгы Беренче Җәмигъ мәчетенә сәфәр дә оештырылды. Аннары аксакаллар Кукмара шәһәренең Туеш мәхәлләсе һәм «Һидәят» тәрбия үзәге эшчәнлеге белән танышты.

Эльмира СИРАҖИ.

«Бетмибез» җыры – җиңүче

Рафис Корбан сүзләренә һәм Илгиз Закиров көенә язылган «Бетмибез» җыры III «Яңа татар җыры» бәйгесендә 1нче урын яулады. Җырны Рөстәм Насыйбуллин башкарды. Иҗатчылар 200 мең сум премия белән бүләкләнде.

«Пирамида» концертлар залында «Яңа татар җыры» бәйгесенең гала-концерты узды. Ваһапов исемендәге татар мәдәниятен үстерү фонды директоры Рифат Фәттахов биелгы бәйгегә 200 җыр килеп ирешкәнен белдерде. Шуларның жюри тарафыннан сайланып алынган уналтысын танылган җырчылар гала-концертта башкарды. Сәхнәдән шулай ук алдагы елларда җиңгән һәм хитка әверелгән җырлар да яңгырады.

Бәйгедә икенче урынны ике җыр бүлеште. Беренчесе – Хәйдәр Әхмәтшин сүзләренә һәм Равил Хисмәтуллин көенә иҗат ителгән «Сириннәр» җыры. Аны Артур Шөгаепов башкарды. Икенчесен – Фәридә Галиәхмәтова сүзләренә һәм Чулпан Зиннәтуллина көенә язылган «Мин синең кыргый гөлең» җырын Татарстанның атказанган артисты Иркә яңгыратты. Авторлар 150 мең сум премия белән бүләкләнде.

Өченче урынга да ике җыр лаек булды. Алар – Фәнәвис Дәүләтбаев сүзләренә һәм Инсаф Хәбибуллин көенә язылган «Казаным» җыры, Гөлсимә Зиннәтуллина сүзләренә һәм Рәис Ханнанов көенә язылган «Кайтыр юлым бар» җыры. Авторлар 100 мең сум премия алачак.

Быелгы бәйгедә яңа патриотик җырларны барлау максатыннан «Ил дәшкән чагында» дип аталган номинация кертелгән. Ике җыр беренче урынны һәм 200 мең сум премияне бүлеште. Аларның исемнәре – «Ил дәшкән чагында» җырының авторлары Алсинә Сәләхова һәм Азат Хәлимов, «Язлар быел сары түгел» җырының авторлары Рәфкать Шаһиев һәм Марат Галимов.

«Иң яхшы балалар җыры» номинациясендә өч урын бирелгән. Беренче урынны һәм 150 мең сум премияне «Бишек җыры» өчен Рамис Аймәт белән Айгөл Софийская алды. Икенче урынны һәм 100 мең сум премияне «Туган җирем» җыры өчен Лилия Гыйбадуллина белән Гөлназ Закирова алды. Өченче урынга һәм 75 мең сум премиягә «Ташбака җыры» лаек булды. Авторлары – Люция Әблиева һәм Эльвира Нигъмәтуллина.

«Буыннан-буынга» номинациясендә ике җыр җиңде. «Гозер» җыры авторлары – Ринат Мөслимов һәм Мәсгут Имашев. «Авылым» җыры авторлары – Рүзәл Минһаҗев һәм Илвир Габдрахманов. Аларга һәр җыр өчен 50 мең сум премия бирелде. Тагын дүрт җырга 50 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылды.

Рифат КАЮМОВ.

Халык фотостудиясе

Казанның С.Сәет-Галиев исемендәге мәдәният сараена «Казан» фотостудиясе күргәзмәсе ачылышына танылган фотографлар, фотография сәнгатен сөюче казанлылар җыелды.

«Казан» фотостудиясен алты дистә ел элек рәссам, фоторәссам, зәркәнче Виктор Ковалевский оештыра. Совет кешесенең беренче тапкыр космоска очкан, илдә техника һәм технологияләр үсеш алган, яшьләр фототехника белән кызыксынган еллар бу. Шул чорда С.Сәет-Галиев исемендәге мәдәният сараенда урнашкан «Казан» фотостудиясе төрле оешмаларда эшләүче, төрле һөнәр ияләре булган яшьләрне үзенә җәлеп итә – аларны фотография сәнгате белән мавыгу берләштерә. Һәм бүген ул Казанда сакланып калган бердәнбер халык фотостудиясе дияргә була.

Хәзерге вакытта студия белән танылган фотограф, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы фотохәбәрчесе Солтан Исхаков җитәкчелек итә.

Юбилей күргәзмәсе ачылышында иҗади коллективны Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе урынбасары Людмила Рыбакова котлады.

Казан шәһәре хакимияте исеменнән тәбрикләү сүзләрен башкаланың Туризмны үстерү комитеты директоры, шәһәр Думасы депутаты Дарья Санникова җиткерде. Ул фотостудия җитәкчесенә һәм коллективның актив әгъзаларына Рәхмәт хатлары, истәлекле бүләкләр тапшырды. С.Сәет-Галиев исемендәге мәдәният сарае директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Валентина Иванова да бай тарихка ия фотостудиянең бу көнгәчә гөрләп эшләп килүенә, халыкка хезмәт итүенә сөенечен белдерде.

Фотокүргәзмәдә исә инде 40-50 ел шушы студиягә йөргән авторлар да, яшьләр дә катнашты. Экспозициядә Солтан Исхаков, Людмила Зотова, Андрей Заһидуллин, Светлана Елагина, Светлана Рафаилова, Артем Гибадуллин, Анна Главатских, Лилия Гаделшина һ.б.ның фотохезмәтләре урын алды. Фотостудиягә нигез салган Виктор Ковалевский һәм элекке елларда актив хезмәттәшлек иткән шәхесләрнең дә коллектив архивында сакланган аклы-каралы фотографияләре тәкъдим ителде.

«Фотографларны, фотография сәнгатен сөючеләрне берләштергән «Казан» фотостудиясе җәмгыятебездә кешелеклелек кыйммәтләрен саклый торган оешма ул. Аның гомере бик озын булсын. Авторларның тарихта калырлык хезмәтләрен туплап, күмәк фотоальбом чыгарырга кирәк», – дип теләкләрен җиткерде күргәзмә кунагы, фотограф Эдвард Хәкимов.

Лилия ГАДЕЛШИНА.

Чын классик җырчы иде

Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде – җыр сәнгатенең күренекле вәкиле, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Эмиль Усман улы Җәләлетдинов вафат булды.

Ул 1933 елның 2 июлендә Үзбәкстанның Сәмәрканд шәһәрендә туа, Ташкент консерваториясендә укый башлый. Аннары укуын Казан консерваториясендә дәвам иттерә. 1962 елдан Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә җырчы солист булып эшли, концертлар белән Татарстан һәм илебезнең төрле почмакларында, чит илләрдә була.

Җырчы татар композиторлары белән тыгыз элемтәдә яши, Рөстәм Яхинның романсларын, Алмаз Монасыйповның «Тукай аһәңнәре» исемле циклын симфоник оркестрга кушылып җырлый. Аның репертуарында рус, итальян халык җырлары, чит ил, рус классик композиторларының романслары әһәмиятле урын алып тора.

Эмиль Җәләлетдинов белән хушлашу мәрасиме Мәрҗани мәчете ишегалдында узды. Мәрхүмнең җәсәде Казанның мөселман зиратында, хатыны Венера кабере янында, җир куенына иңдерелде.

● Алты ел буе Англиянең «Ливерпуль» командасының иң яхшы футболчыларыннан берсе булган, хәзер Германиянең «Бавария» командасында уйнаучы Садио Мане экраны чатнаган иске айфон белән йөри. Үзенә көн саен бер смартфон сатып алырга хәленнән килсә дә, спортчы яхта яки кыйбатлы машиналар белән мавыкмый, Сенегалның үзе туган районында яшәүче йөздән артык ярлы гаиләгә ай саен 70 шәр евро акча биреп бара. 2019 елда туган авылы Бамбалида мәктәп төзүгә 250 мең фунт стерлинг, 2021 елда шунда ук хастаханә төзелешенә 500 мең фунт стерлинг акча бүләк иткән.

● Криштиану Роналду Төркия һәм Сүриядә җир тетрәүдән зыян күрүчеләргә 8 миллион евро, Лионель Месси 3,5 миллион евро акча җибәргән. Чагыштыру өчен: Европа Берлеге илләре барысы бергә исә 6,5 миллион евро гына биргән.

ИНТЕРНЕТТА ТАТАРЧА МӘКТӘП



Интернетта «Татарча онлайн мәктәп» дигән платформа барлыкка килде. Биредә мәктәптә укытыла торган төп фәннәр буенча видеодәресләр карарга мөмкин.

Дәресләр татар телендә җиңел аңлаешлы итеп төшерелгән. Караучыны ялыктырмас өчен, алар уртача 7-10 минут дәвам итә. Предметлар буенча һәр сыйныфтан 16 төп тема алынган. Темаларны гимназиянең тәҗрибәле укытучылары сайлаган. «Татарча онлайн мәктәп» ярдәмендә мәктәп укучылары онытылып киткән теманы искә төшерә алса, укытучылар – дәрес конспектын, тема презентациясен йөкләп, үз дәресендә куллана һәм хезмәттәшенең тәҗрибәсе белән таныша ала. Ул ата-аналар өчен дә мәктәп материалын хәтердә яңартып җибәрү өчен файдалы булырга мөмкин.

«Ютуб» чикләнгән мәктәпләр өчен видеодәресләр «Гугл диск»та саклана. Сайтта бирелгән сылтама аша кирәкле видеоны берниндй чикләүләрсез компьютерга йөкләргә була. «Татарча онлайн мәктәп» платформасыннан куллану тулысынча бушлай. Теркәлү дә соралмый.

«Татарча онлайн мәктәп»нең эчтәлеге 5 юнәлешкә бүленгән:

- **Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем;**
- **Башлангыч мәктәп (1-4 класслар);**
- **Төп мәктәп (5-9 класслар);**
- **БДИга әзерлек (10-11 класслар);**
- **Өстәмә белем бирү – инженер дәресләре.**

«Татарча онлайн мәктәп» белән якыннанрак танышу өчен, Казанның 2 нче татар гимназиясе директоры Рамил Рәшит улы Гайнуллин белән әңгәмә кордым.

– Башка татар мәктәпләрендә бердәм дәүләт имтиханнарына, гадәттә, рус телендә әзерләнәләр. Татар телле материалларга ихтыяҗ булырмы?

– Имтиханнар рус телендә булгач, әлбәттә, русча да өйрәнмичә булмый, ләкин татар телендә белем алган бала профильле математиканы туган телендә җиңелрәк үзләштерә. Гомумән, фәнне 2 телдә белгән баланың фикерләү дәрәҗәсе көчлерәк, киләчәктә аның мөмкинлекләре зуррак була.

Мисал өчен, Равил Нияз улы Алишевның профильле математикадан бердәм дәүләт имтиханына әзерләү дәресләренә игътибар итегез. Материал дәреслекләрдәгечә түгел, ә мөмкин кадәр аңлаешлы һәм җиңел форматта бирелә. Укытучының тәҗрибәсе бик зур. Ул үзе мәктәптә укыганда математикадан бик сәләтле укучы булган һәм Россия күләм бәйгеләрдә уңышларга ирешкән. Хәзер исә аның укучылары имтиханнарны даими рәвештә 90-100 балларга бирә. Аның дәресләре татар телендә белем бирә торган укытучыларга да методик ярдәм була ала. Һәркайсы аны күзәтеп, шул форматта үз укучыларына аңлата ала. Равил әфәнденең дәресләренә үзебезнең укытучылар да кергәләп утырды.

– Ул сездә укытмыймы?

– Без Равил Нияз улы белән өстәмә белем бирү форматында хезмәттәшлек иттек. Бүгенге көндә аның белән «Татарча онлайн мәктәп» проектында эшлибез. Аның төп эш урыны – Казанның Халыкара мәктәбендә.

– Димәк, сез үз укытучыларыгыз белән генә чикләнмисез.

– Әйе, башка җирләрдән дә алдынгы укытучыларны җәлеп итәбез. Югары уку йортларында бирелә торган математиканы югары дәрәҗәдә татар телендә укыта алырлык белгечләр сирәк. Аларда булган базаны туплап, ә ул дәреслекләрдә юк, башка укытучыларга да күрсәтәсе һәм киләсе буыннарга тапшырасы иде.

БДИга әзерлек – ул 7-11 сыйныф материалларын кабатлау. Шуңа күрә бу видеодәресләр 7 нче сыйныф укучысына да, имтиханга әзерләнүчегә дә файдалы булачак. Авыл укытучылары бу ресурстан файдалана.

Башка укытучының эш алымы белән кызыксыну беркемгә дә комачауламый.

Әлеге ресурста дәрескә презентацияләр һәм дәрес планнары да беркетелә. Аларны да эштә кулланырга мөмкин. Икенчедән, бу дәресләрне урамнан килеп кергән кеше алып бармый. Монда уңышларын дәлилләгән укытучылар катнаша. Аларның күбесе – укучыларны олимпиадаларга, чыгарылыш имтиханнарына уңышлы әзерләп, югары нәтиҗәләргә ирешкән шәхесләр. Мәсәлән, Лилия Котдусовна Халиуллина – химия буенча имтихан эксперты, республикада иң көчле укытучыларның берсе.

Бу проект белән мин Свердловск, Чиләбе, Самара, Оренбург өлкәләрендә, Башкортстан Республикасында чыгыш ясаганда, укытучылар, мәктәп директорлары тарафыннан зур кызыксыну уянды. Самараның «Яктылык» мәктәбе бу ресурсны инде куллана башлады.

Күптән түгел безгә Чечнядан, Чабаксардан, Уфадан делегацияләр килеп, «Татарча онлайн мәктәп»не өйрәнеп киттеләр. Хәзер әлеге милләт вәкилләре шушындый проектны үз телләрендә булдырырга җыена.

– «Татарча онлайн мәктәп» идеясе ничек туды?

– Татар халкының революциягә кадәр булган бик бай гыйльми мирасы йә югалган, йә гарәп графикасында сакланганга күрә, әлегә кадәр тиешенчә өйрәнелмәгән. Бүген татар тормышында фәнне татарча бирә ала торган белгечләребез бар. Ул буын олыгаеп, эштән китсә, киләчәктә нәрсә буласын беребез дә белми, ә Интернетка элеккән әйбер юкка чыкмый, дигән гыйбарә бар. Гимназиягә килгәч, укытучыларның бай тәҗрибәсен видео форматка әйләндереп, архивлаштырып, киләсе буыннарга тапшыру теләге уянды. Физиканы да, биологияне дә, химияне дә татарча укытып була, дигән фикер алга таба да яшәсен иде.

Яңа гына университет тәмамлаган яшь белгеч физика укытырга килде, ди. Ул мәктәптә татарча укыган булса да, университетта русча белем алгач, аңа татар телендә дәрес алып бару кыен булачак. Интернетта рус телендә материаллар бик күп, ә татар телендә юк дәрәҗәсендә. Укытучы татар телендә булмаган видеоларны, презентацияләрне, план-конспектларны каян алсын? «Татарча онлайн мәктәп» – ул яшь укытучылар өчен бик файдалы чыганак булачак.

– Бу идеяне тормышка ашырырга Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе дә ярдәм итте, дип беләм.

– Әйе. Комиссиягә рәхмәт. Шәхсән Марат Әхмәтовка зур рәхмәт белдерәм. Марат Готыф улына бу проектны тәкъдим иткәч, ул безгә ышанды.

– Ялгышмасам, «Татарча онлайн мәктәп» проектына дәүләт ярдәменнән башка тотынган идегез.

– Үзебезнең инициатива белән башладык. Грант откач, зуррак мөмкинлекләр ачылды. Онлайн дәресләр үткәрү өчен студия булдырдык. Без киләчәктә бүтән мәктәпләрдә эшләүче укытучылар белән дә хезмәттәшлек итәргә телибез. Әгәр педагог үз фәнен кызыклы һәм үтемле итеп бирә белсә, без аның дәресен видеога төшереп, яки үзе төшергәнне безгә җибәреп, «Онлайн мәктәп» сайтына урнаштыра алабыз. Бер килгәндә, берничә тема төшерергә мөмкин. Дәрес өчен гонорар түләнәчәк.

– Видеодәресләр уртача 10 минут бара, дип карадым. 10 минутлык продукт чыгарыр өчен, укытучы камера алдында күпме вакыт эшли?

– Дәресләрнең төрлесе – 40 минутлыклары да бар. Күпчелеге, чыннан да, 10 ар минут тирәсе. Башлангыч чорда бер дәрес төшерү берәр сәгатькә сузыла иде. Укытучыларның камерага сөйләү осталыгы арткач, 20 минутка да сыеша башладылар. Монда актерлык осталыгы да кирәк. Тәҗрибә белән ул арта. Бу проектта катнашкан укытучылар иҗади яктан үсә. Алар бу турыда үзләре дә әйтә.

2024 елга мәктәпкәчә белем бирү модуле планлаштырылган иде, ә без аны гыйнвар аеннан башлап җибәрдек. Бүген иң күп карауларны шушы модуль җыя. Күрәсең, социаль челтәрләрдә безнең сәхифәләргә язылучыларның күбесе – мәктәпкәчә яшьтә баласы булган ата-аналар. Кечкенә балаларга кагылышлы видеоларны күпләп карыйлар. Инглиз теле дәресләре дә зур кызыксыну уята. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телендә белем бирә торган һәм шул ук вакытта кызыклы видеолар Интернетта юк дәрәҗәсендә иде. Шуңа күрә безнең видеоларга кызыксыну арткандыр да. Монда сүз татар теле дәресләре турында түгел, ә туган телдә белем бирү турында бара.

– Татар теле дәресләрен дә видеога төшерәчәксезме? Алар чит төбәкләрдә яшәүче татарларга кызыклы булыр кебек.

– Татар теле дәресләрен башлап җибәрдек. Татар телен өйрәнергә теләгән рус телле аудиториягә дә дәресләр яздыру планы бар.

Сайтка керүчеләрнең статистикасын карагач, «Татарча онлайн мәктәп» читтә яшәүче татарларга, чыннан да, кызыклы икән, дигән фикергә килдем. Бирегә Россиядән тыш, Төркиядән керүчеләр дә сизелерлек күренә. Шулай ук Германия, АКШ, Канададан керүчеләр дә бар.

«Татарча онлайн мәктәп»нең тагын бер яңалыгы белән бүлешәсем килә. Үзебез уйлап тапкан татар телендәге интеллектуаль уеннарны тәкъдим итә башладык. Шушы көннәрдә сайтта «Уеннар һәм кушымталар» дигән яңа бүлек барлыкка килде, һәм без анда үзебезнең уеннарны йөкләп барачакбыз. Алар СССР чорыннан килгән уеннарга нигезләнеп, заманча форматта ясалган. Татар теле укытучылары бу уеннарга зур бәя бирде.

Рифат КАЮМОВ.

intertat.tatar

«Без татар эшмәкәрләреннән үрнәк алабыз. Барысы да эшләрен үз көчләре белән алып бара. Татарлыкны да сакларга тырышасыз, гореф-гадәтләребезне киләчәк буыннарга җиткерәсез», – Республика Рәисе бу сүзләрне XI Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенында ихластан әйтте. Россиянең 47 төбәгеннән, 5 чит илдән килгән фермерлар, оешма вәкилләре, хуҗалык рәисләре, район җитәкчеләре үзләре дә шундый нәтиҗәгә килгәннәрдер, мөгаен.

Татар булып яшибез

● Башкортстанның Бәләбәй районы Мәтәүбәш авылы уңганы Гөлнара Зайруллина.

● Мөслимнең Зифа Басыйрова исемендәге мәдәният йорты үзешчәннәре.

● Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов автор башкаручы, алып баручы Ильяс Халиковны «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелү белән котлады.

600 дән артык делегатның Чуаштанда булдыклы татарларыбыз яши торган Тукай, Урмай һәм Шыгырдан авылларына барып, тезелеп киткән ике-өч катлы йортларын күрүе, аларның чын татарча итеп гомер итүләрен аңлавы да шушы фикерне ныгыта. Бу якларда гореф-гадәтләребез дә, ныграк сакланган. Җыенга килүчеләргә Камал театрында Мәхмүт Галәү әсәре буенча куелган «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектаклен карау да, Татарстан башкаласында театр сәнгатебез белән танышу мөмкинлеге тудырылды.

Милләттәшләребезнең булдыклылыгын Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыенының секция һәм пленар утырышы узган «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә оештырылган ярминкәдә дә күрергә мөмкин иде. Әйтик, Мордовия, Нижний Новгород яклары казылык белән данлыклы. Мордовиянең Аксюн авылыннан Наил Килдеев, Фаил Фәтхуллов ымсындырып торган тәмле колбасалар, ысланган ит алып килгән. «Предприятиебезне 2002 елда эшләтеп җибәргән идек. Хәзер көненә 600-700 килограмм әзер продукция җитештерәбез. 400 баш атыбыз, башка малларыбыз бар. 2000 гектар җиребездә терлекләргә җитәрлек азыкны да үзебез үстереп әзерлибез», – ди Наил Килдеев.

Башкортстанның Бәләбәй районы Мәтәүбәш авылыннан Гөлнара Зайруллинаның уңганлыгы хәйран итә. Ул, мәктәптә укытучы булуы өстенә, ире Марат белән бергә фермер хуҗалыгы ачып җибәргәннәр. Зур мәйданнарда бакча үстерәләр икән. Гөлнара ханым, җиләк-җимешләре күп булгач, как ясауны җайга салган. Алманы пешереп, аңа яңа җыйган җиләк-җимешне блендер аша чыгарып куша һәм киптерә, аннары аларны матур итеп төргәкләп, тартмачыкларга салып, халыкка тәкъдим итә. «Бер алган кешеләр ошатып тагын сорап киләләр. Почта аша да җибәрәбез», – ди Гөлнара ханым.

Гаҗәеп күркәм милли музыка уен кораллары янышнан тыныч кына үтеп китү һич мөмкин түгел иде. Аларның монда төрлесен күрергә мөмкин. Курай, әллә ничә төрле думбра, җәя кубыз, кыл кубыз, танбур дисеңме... Болар – борынгы көйләребезне яңартып халыкка тәкъдим итү белән мәшгуль «Алпар» татар музыкаль төркеме уен кораллары. Россия күләмендә танылган төркемнең музыканты Алмаз Әсхәдуллин думбрада милли көйләребезне уйнап та күрсәтте. Ул ун ел тирәсе этномузыка белән шөгыльләнә. Музыка кораллары исә Коркачыкта яшәүче Җәлил Вилданов остаханәсендә ясала. Ул курайларның – шпоннан, думбраларның арткы өлеше карагачтан, кайбер өлешләре өрәңгедән, эрбеттән, чыршыдан эшләнүе турында бик мавыгып сөйли. Агачларны кисеп, уеп бизәкләүче рәссам Җәлил ага музыка уен кораллары да, сандыклар да, люстралар, сәгатьләр дә, шкатулкалар да ясый.

Күргәзмәгә йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне яңартуда иң актив эш алып бара торган районнарның берсе – Мөслимнән аеруча зур делегация килгән. Мәдәният, музей хезмәткәрләре, фольклор ансамбль коллективы бергәләп үз районарының мәдәниятен тәкъдим итәләр. Күргәзмәгә килеп кергәндә үк, гаҗәеп матур мендәрләргә күзем төшкән иде. Аларның күбесе – Мөслимдә үткән Бөтенроссия каз өмәсе конкурсында җиңгән һәм районның «Туган як» музеенда чигелгән үрнәкләр. Арада колакча чигү ысулы белән бизәкләнгән мендәрләр дә бар. Аларны рәссам, татарларның борынгы бизәкләү ысулын яңарткан Әлфия Нурхәмметова чиккән. Республика рәисен җырлап-биеп каршылаучылар да мөслимнәр булды. «Туган як» музеенда төрле түгәрәкләр эшли, тамбур чигүен яңарттык. Быел мендәр тышларын каз төшереп чигеп бизәкләдек, сөлгеләр чигү белән шөгыльләндек. Кул эшләренә балаларны да җәлеп итәбез. Бакчага йөри торган балалар да шәҗәрәләрен, тарихыбызны өйрәнә, милли мәдәниятебезне күреп үсәләр», – ди музей директоры Назилә Бәдретдинова.

Шунда ук диварга эленгән картиналарга игътибар итәбез. Болар күптән түгел генә рәссамнарыбызның Мөслимдә үткән пленерында иҗат иткән картиналары.

Мәдәният, музей хезмәткәрләре, фольклор ансамбльгә йөрүчеләребез, «Казан халык сәнгать кәсепләре» техникумы укучылар һәм укытучыларының милли үрнәкләр белән бизәкләп чиккән күлмәкләре, жилетлары, итәкләре, алъяпкычлары, билбаулары, түбәтәйләре, читекләре теләсә кем кызыгырлык. Өлкән мастер Роза Әлмяшева аларны бик яратып күрсәтә.

Пленар утырыш барышында Россия төбәкләрендә яшәүче татарларыбызның булдыклылыгы, шул ук вакытта аларның милләт гамен дә уйлап эшләүләре сокландырды. Пермь крае Барда районы эшмәкәре Физия Акбашева 20 ел элек әнисе җитәкчелегендә икмәк һәм чәкчәк пешерү цехын ачып җибәргән. Хәзер бу эштә аның ике кызы һәм кияүләре катнаша. Хәзер 15 кешене эш белән тәэмин итәләр, җитештерә торган продукцияләре исә атнага бер тоннадан артып китә. Милли ризыкларыбызны борынгы рецептлар буенча әзерлиләр. Авызда эреп тора торган чәк-чәк өчен Барда ягында җитештерелгән сыйфатлы бал сатып алалар. Шулай ук җирле җиләк-җимешләрне кулланып ясалган тортлар, кызарып пешкән бәлешләрне халык бик ярата. Физия Акбашева ширкәте чәк-чәк җитештерү буенча Пермь краенда лидерлар рәтенә кергән. Алар 2009 елдан бирле Барда районының сәүдә челтәрләре белән хезмәттәшлек итә, ә 2011 елдан бирле продукцияләре Пермь крае һәм Свердловск өлкәләрендә сатыла. Шул ук вакытта Акбашевлар округның социаль әһәмиятле тормышында да актив катнаша. «Ел саен Сабантуйда, бәйрәмнәрдә Барда ягының мәдәни үзенчәлеген, гореф-гадәтләребезне күрсәтәбез. Махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм җыюдан читтә калмадык», – диде Физия Акбашева.

Түбән Новгород өлкәсе Сафаҗәй районы эшмәкәре Айрат Абдуллов кош-корт, мал үрчетә. Иттән исә манты, өчпочмак, пәрәмәч кебек милли ризыклар әзерлиләр. Айрат Абдуллов алар белән Россия күләмендә сәүдәгә чыгарга тели. «Татарстанга үз авылыбызга кайткан кебек кайтабыз. Гаиләбездә татар телендә сөйләшәбез, ләкин балалар русчаны да кушып сөйләшә башлады. Алар урамда җыелып футбол уйнейлар да русча сөйләшә башлыйлар. Бу телевизор, мультфильмнарның йогынтысы дип уйлыйм», – диде ул.

Чуаштаннан «Слава Картофель» агрофирмасы җитәкчесе Рамил Идиатуллин балаларын телефоннан аеруның үзенчәлекле һәм отышлы юлын тапкан, аларны бәрәңге бизнесына җәлеп иткән. «Белгәнебезчә, ана теленә мәхәббәт кечкенәдән башлана. Хәзер телефон тотып, башка телдә сөйләшеп йөрүче балалар безнең авылда да бар. Бу күренешкә каршы торырга тырышабыз. Шуңа күрә балаларыбызны бәрәңге бизнесына тартып керттек. Татарлыгыбыз белән горурланып яшибез. Газиз телебезне, гореф-гадәтләрне саклап калырга кирәк», – диде ул.

Р.Идиатуллин, университетны тәмамлап, авылга кайтканнан соң, эшен әкренлек белән башлап җибәргән. Беренче елларда бәрәңгене кул белән чүпләгәннәр. Хәзерге көндә 5 мең гектар җир эшкәртәләр, бәрәңге үстерү буенча федераль программада катнаша башлаганнар, алты ел элек лаборатория ачканнар һәм теплица комплексын булдырганнар.

Россиядә татар халкы гомер кичермәгән бер төбәк тә юк. Ставрополь краенда да тугыз меңгә якын татар яши. Алар 200 ел элек Казан һәм Нократ губернасыннан күченеп килгән, эре мал, сарык асрап, игенчелек белән көн күргәннәр. Милләттәшләребез әле дә шуның белән шөгыльләнә. Татарлар кайда яшәсә дә, Татарстанга, үз мәдәниятенә тартыла. Крайда татар мәдәнияте үзәге 2006 елда эшен башлаган. Барханчак авылы мәктәбенә Муса Җәлил исемен бирү буенча эш бара, аның бюстын да куюны планлаштыралар.

Башкортстанның Туймазы районы татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе татар кызы Индира Латыйпова былтыр икенче тапкыр үткәрелгән «Каз өмәсе» фестиваленең Бөтендөнья татар конгрессы башлап җибәргән уңышлы проектларының берсе икәнлеген әйтте. «Фестиваль күләмле чарага әйләнде. Ул милли гореф-гадәтләрне саклау һәм яңа буынны тәрбияләү өчен дә әһәмиятле. Шул ук вакытта ул татар авылларын саклау һәм үстерү ягыннан да отышлы», – диде.

Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев булдыклы милләттәшләребез белән һәр очрашуның зур горурлык, җаваплы булуын билгеләп үтте.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Әкбәр КОШАЛЫ

Яна-яна бөтерелик, ниһаять, Илһам килер, Каләм язар, Сүз калыр...

Танылган азәрбайҗан шагыйре, тәрҗемәче, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Бөтендөнья яшь төрки язучылар берләшмәсе җитәкчесе. Күпсанлы китаплар авторы. Бакуда яши.

ШӨКЕР

Тезем җиргә тияр вакыт,
көч-гайрәтем бардыр, шөкер.
Җаныма кабат нур иңә,
күңелемдә таңдыр, шөкер.

Якынлыгын озак белдек,
озаклыгы – салкын фикер.
Китнән – китте, без бетмәдек,
Мөхәммәд туды, мең шөкер.

Гомеремнең ахырында
нокта булмас, бәлки, өтер.
Әйтер сүз калса әгәр дә,
шагыйрь һәм шигырьгә шөкер!..

* * *

Әле иртә җитмәгән,
күбәләк тә китмәгән,
кешеләр йокы дигән
тын дөньяга бикләнгән.
Китәргә рөхсәт итче,
мәңгелеккә китимче.

Ай белән бергә килдем,
мин Ай юлында идем,
хәзер алар югалды,
булган хәл булып калды.
Буласы булган, әйдә,
мөмкинлек бир китәргә.

Килсәм, аерылулар –
бетәр җан авыртулар,
китсәм, төн тәмамланыр,
офык чиге алланыр.
Ничек кенә итәргә,
гөлдәй сулып китәргә?..

Китәм, ничек китүне
белмим, чыкмый төтене,
телем сөйли, җан тынган.
Кулымнан ал да юлдан
китәргә ирек бирмә,
китү – мәңгелек төрмә.

* * *

Бу гөнаһсыз иренне,
үбәр иреннәремне
күзләремнән агылган
тозлы суларга мандым...
Әмма чын сөю тәмен
онытмам, онытмадым...

* * *

Яхшы көн үзеңә калсын,
авыр көндә миңа кил...
Бары сөйләшеп утырыйк,
кил,
    килче
            син,
                янә кил…

* * *

Сүз табармын
буш бишеккә
көй көйләгән
ил кызына…
Әй-йа Тәңрем,
сабырлык бир
буш табутның
анасына…

КАРАНТИН ДӘВЕРЕНЕҢ ДҮРТЕНЧЕ ШИГЫРЕ

Кулымда бер рәсем,
Рәсемдә бер кәләш,
Кәләштә бер йөрәк,
Йөрәктә бер мин,
                бер мин...
                        14.05.2020

* * *

Күзләрем вакытсыз уянды,
ни ахшам әлегә, ни сәхәр.
Йөрәгем ни белән уйланды –
шатлыгы, сагышы ни кадәр?

Күзләрем багарлар, күрмәсләр,
Кулларым тиярләр, тимәсләр…

СОРЫ ШИГЫРЬ

Соры далада,
соры күкләрнең
соры катында
салкыннан соры
ныклы гәүдәсен
күтәргән егет
дошманның соры
күзенә ата.

Тоясыңмы соң
хәтер дигәннең
иң төпкелендә
гайрәтле рухын
соры бүренең?..
Тоясыңмы соң? –
канны кузгата,
җанны уята.

* * *

Бәйрәмнәр уздырмадым,
календарьлар алмадым,
барысын да гомернең
«өтере»нә санадым.
Нокта – Аллаһ кулында,
гомер болай да кыска!.. –
Мин исә, сине сөеп,
Өндәү куйдым тормышка!

* * *

Хөкем – бары Аллаһтан!
Карар бары Аллаһтан!
Фәрманы да Аллаһтан!
Бу дөньяда нәрсә бар,
Аңа кайта азактан.

* * *

Ай-яй, үз маенда кайнар әфәндем,
Тукта, күз яшендә йөзәр әфәндем,
Җиде кат күкләрдән төшеп, әйтерсең,
Күздән дә югалган гүзәл әфәндем...

* * *

Якын юлга баралмадым,
ерагына – вакыт түгел.
Хуш-бәхетне казанмадым,
көн дә күрер бәхет түгел?..

Аягым җиргә тиюгә,
җир җитмәде аягыма.
Юллар миңа төшмәде һич,
төштем юллар тозагына.

* * *

…көлү йөзләрдә тынды,
бактым – җаным очынды...
телем-авызым корыды
качкын шәһәрчегендә…

күз күрдем тозга тулган...
хәтерне яңартудан,
йөрәгем басылмады,
җаннар тозга тулмасын…
сабак онытылмасын!..

«Кил!» димә син миңа,
                «Кит!» димә,
Шикәр дә, агу да, юк, бирмә…

БЕР МИЗГЕЛ ТОЙГЫСЫ

Көчле җилләр искәндә
тутык йозак чайкала.
Ишекләр сорамасмы:
ачкычың, йозак, кая?

Мин дә үз көннәремнән
берне генә сакладым;
Һәр елны, шул ук көнне
үз-үземә бакмадым...

* * *

Яралан, яраланма,
бер гүзәлне тап та кит,
ихлас булган якка кит.

Иел, иелмә… әүвәл
башың и туган җиргә,
чәчәк таҗын үп, кил дә.

Искә ал, искә алма,
әрем исен иснәп кит,
Тәңрене син исләп кит…

* * *

Әремне иснәп,
атка менмибез.
Без китсәк, өскә
үлән капларлар
микән –
        белмибез?
Ант иткән чакта
йөзне тотмыйбыз
әләм-байракка,
йөзне тотмыйбыз
Күккә һәм Айга,
колак ятсына
бүре тавышын –
ул әллә кайда.
Соңрак әйтерләр:
синең дәртең ни?..

* * *

Туфрак –
авыр көндә байрак тоткан,
маңгайдагы җыерчыклар
катлы-катлы җанны йоткан
чын ирләрнеңнең йөрешендә
карыш-карыш сулу ала.

Туфрагы исә һәр җирдә
кабер белән мөһерләнгән,
нахак белән каһәрләнгән
бу милләтнең байрагы да
мәңгелектә торып кала...

* * *

Мин синнән аерылганда, үлеп,
сине күзләремдә сакладым.
Һәр көзге янынннан
узган мәлдә
сине генә күрәм, аппагым.
Терелеп күземнән төшәрсең күк,
Үзем дә күземнән төшерәм,
Төшә йөрәгем.
Җаннан кичерәм.
Саклый да алмыйм
сине күземдә,
нәрсә булса да,
син бит күземнең
хәтер эзендә.

КАЛЫР

Ике ташның арасында бер учак,
«Ике ташның арасында» бер гомер…
Учак янар, учак сүнәр, куз калыр,
Ата китәр, Угыл килер, Үз калыр.

Елларыбыз, яна-яна, көл булыр,
Янмасак та, берәр вакыт көл булыр...
Бала булыр – фәкыйрь булыр, көр[1] булыр,
Телебездә «нигә» калыр, «түз» калыр.

Болар барсы яхшы сүздер, һәм хәят,
Нигә кирәк янмас учак, кәм[2] хәят?..
Яна-яна бөтерелик, ниһаять,
Илһам килер, Каләм язар, Сүз калыр...

[1] *Көр* – бай мәгънәсендә.
[2] *Кәм* – аз мәгънәсендә.

Азәри теленнән
Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре.

«ИДЕГӘЙ» –

Заманында Алтын Урда дәүләте (Җучи олысы) составында булган халыклардан казахларда, каракалпак, нугай, башкортларда, Кырым һәм Себер татарларында атаклы «Идегәй»нең төрле вариантлары язылып алынган. Әлеге дастан иң элек Алтын Урданың Идегәй йогынтысындагы кыпчак телле олысларында җирле риваять-легендалар нигезендә туа башлаган дип исәпләнелә. Аның тәмам формалашып җитүе, төрле якларга таралып, күп санлы версияләре тууы да, нигездә, шушы халыкларның бабалары яшәгән җирдә – соңрак барлыкка килгән Нугай Урдасы кысаларында була. Аерып әйтергә кирәк: Иртыш, Тубыл елгаларына кадәрге Себер җирләре дә ул чакта Урда биләмәләре санала.

«Идегәй» дастанының Себер татарлары арасында теркәлгән вариантлары дистәдән артып китә. Аларның тулы булмаган борынгырак ике редакциясе К. Галибәкнең «Җәмигъ эт-тәварих» («Тарихлар җыелмасы») җыентыгы аша килеп җиткән. Өченчесе XIX йөз ахырында В. Радлов тарафыннан язып алынган, чагыштырмача тулырак варианты укытучы, журналист һәм галим Н. Хәким тарафыннан 1919 елда С.Зәйнетдинов исемле чичән башкаруында теркәлгән. Әсәрнең 1940 елда исә күренекле язучы һәм галим Н. Исәнбәт тарафыннан, әлеге текстны нигез итеп алып, шулай ук элекке һәм совет чорында язып алынган вариантларны да кертеп эшләгән җыйнама-тәнкыйди версиясе дөнья күрде. Хәзерге вакытта «Идегәй» киң җәмәгатьчелеккә төрле басмаларда урын алган нәкъ шушы гомумиләштерелгән текст буенча билгеле. Шул ук вакытта Ф. Әхмәтова төзегән җыентыкта (Татар эпосы. Дастаннар. – Казан: Раннур, 2004) дастанның Ситдыйк бабайдан язып алынган варианты да басылып чыкты.

«Идегәй» эпос-дастанында XIV йөз ахыры – XV йөз башында Алтын Урда дәүләтенең таркалу чорына керүе, Урта Азиядә Аксак Тимер (Тимерләнк) дәүләтенең көчәеп китүе дәверендәге вакыйгалар тасвир ителә. Бу вакыйгаларның үзәгендә өч тарихи шәхес тора: Алтын Урда ханы Туктамыш, кыпчаклашкан мангыт кабиләсеннән чыккан Идегәй, Урта Азиядәге төрки дәүләт хөкемдары әмир Аксак Тимер. Билгеле, дастанда эпик образ рәвешендә тасвирланган геройлар белән аларның прототиплары, ягъни әлеге реаль шәхесләр арасында тигезлек билгесе куеп булмый. Алар әсәрдә жанр эстетикасына һәм халыкның яки чичән-җырауларның күзаллавына бәйле рәвештә төрле үзгәрешләргә, трансформацияләнүгә дучар ителгән.

Алтын Урда ханы Туктамыш – Чыңгыз нәселеннән чыккан хөкемдар. Хакимият башына ул Аксак Тимер ярдәмендә килә, Урданың үзенә кадәрге ханы Тимер Мәликне үтереп, тәхеткә утыра. Аңарчы Идегәйнең әтисе Балтычак (Котлыкыя) – Тимер Мәликнең баш әмире, ә аның кызы – Идегәйнең апасы – әлеге хан хатыннарының берсе була. Үзенә хезмәт итүдән баш тартканы өчен, Туктамыш Котлыкыяны да үтерә. Тимер Мәликнең яшүсмер улы Тимер Котлык исә, күпмедер вакыт сарайда торганнан соң, Идегәй бәк ярдәмендә Аксак Тимер ягына кача.

Зур дәүләтнең хөкемдары булып алгач (1380), Туктамыш мөстәкыйль сәясәт үткәрә башлый: эчке фетнә-чуалышларга чик куя, үзенә каршы торучы Мамай гаскәрен тар-мар итә, идарәчелегенең баштагы 7 елы дәвамында Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга ирешә. 1382 елда Мәскәүне яулап алып, руслардан ясак түләтә. Шул ук елда бәйсезлеккә омтылган Идел буе Болгар дәүләтен яу белән килеп бастыра. Ә инде алга таба Туктамыш, дәүләтенең шактый көчәеп-үзәкләшеп китүеннән файдаланып, сугыш юлы белән Җучи олысының элекке хәрби данын һәм куәтен кайтаруга юнәлдерелгән ниятен үтәргә алына. Тарихчылар аның үзенә тәхеткә менәргә ярдәм иткән Аксак Тимергә каршы үзе башлап һөҗүм итүен, җиңелгәннән соң да, кат-кат 200 мең кешелек гаскәр җыеп, аның белән канлы сугышлар алып баруын шуның белән аңлата да (Исхаков Д. М., Измайлов И. Л. Этнополитическая история татар (II – середина XVI вв.). – Казань : Школа, 2007. – С. 206 –207; Жирмунский В. М. Тюркский героический эпос. – Л. : Наука, 1974. – С. 366 –367.).

Үз янәшәсендә Алтын Урда дәүләтенең көчәюен теләмәгән баскак Аксак Тимер өчен бу бәрелешләр кулай булып чыга. 1389, 1391 һәм 1395 елларда ике арада булган иң зур сугышларның өчесендә дә Туктамыш җиңелә. Соңгы сугышның нәтиҗәләре аеруча фаҗигале: Аксак Тимер гаскәрләре Туктамышны Иделгә кадәр эзәрлекләп килә һәм илнең башкаласы Сарайны яндыра. Бу җиңелү тарихчылар тарафыннан хаклы рәвештә Алтын Урда дәүләтенең куәте кимү һәм таркалуга йөз тотуының башы дип исәпләнә.

Шушы җиңелүдән соң Туктамыш, Литва кенәзе Витовт ярдәмендә кабат тәхетен кире кайтарырга тырышып караса да, хәтта соңрак, Аксак Тимер алдында гафу үтенеп, аның куәтенә исәп тотса да, ниятенә ирешә алмый. 1406 елда ул Алтын Урда ханы Шадыбәк гаскәрләренең аерым отряды тарафыннан Себердә, Төмән шәһәреннән ерак түгел җирдә үтерелә. Шунда сакланган бер курганны җирле халык хәзер дә Туктамыш кабере дип исәпли.

Алда әйтелгәнчә, Идегәй – чыгышы белән кыпчаклашкан мангыт нәселеннән. Ул башта Нугай олысы бәге була. Аннары үзенең сәләте аркасында Туктамыш хан сараенда карачы-бәк вазыйфасын башкаручы сул канат әмире дәрәҗәсенә күтәрелә. Элекке тарихи чыганакларга караганда, Идегәй үзенең әтисен үтергән усал холыклы Туктамыш алдында тыштан буйсыну, түбәнчелек күрсәтсә дә, асылда, һәрчак сакланып, качарга әзер булып яши. Һәм соңгы вакытта Туктамышның үзенә карата үзгәрүен сизенеп, кызмача чагында авызыннан янау сүзләре ычкындыруын ишетеп, араларын өзәргә була: башкалар абайламаган арада, чаптар аты белән Аксак Тимер янына качып китә.

Кайбер тарихчылар Идегәй әтисе өчен Туктамыштан үч алырга уңай вакыт җитүен генә көткән, Аксак Тимер янына да, асылда, шул планын әзерләү өчен киткән дип исәпли. Вакыйгаларның ары таба үсешеннән күренгәнчә, моның өчен Идегәй, әтисе үтерелгәч, Аксак Тимер янына качкан Тимер Котлыкны да үз «уенына» тартырга тиеш була, ягъни ул Чыңгыз нәселеннән чыккан әлеге хан улын, үз йогынтысына алып, киләчәктә аны Туктамышка каршы файдаланырга, аны Алтын Урда тәхетенә утыртырга ниятли. 1391 елда Туктамыш белән Аксак Тимер арасындагы сугышта әмир ягыннан Идегәй һәм Тимер Котлыкның да катнашуы әнә шуның белән аңлатыла. Тарихи чыганакларда бу сугышны ачучы, башлап җибәрүче Туктамыш та, шулай ук Аксак Тимер үзе булган диган карашлар да бар. Гарәп авторы Ибне Гарабшах исә Тимерләнкне Алтын Урдага яу белән барырга Идегәй котыртып күндергән дип язып калдырган. Алтын Урда ханы Туктамышның көчәергә, җирләрен орыш юлы белән киңәйтергә омтылуын исәпкә алганда, Сәмәрканд әмиренең исә үз иле белән янәшәдә сугышырга ашкынучы, кодрәтле хан идарә итә торган куәтле дәүләт булуын теләмәвен күздә тотканда, сугышка ике якның да әзерләнгәнлегe шик тудырмый.

Идегәйнең күңелендә йөргән үтә кыю һәм хәтәр план ике гигант хөкемдарның 1395 елгы өченче зур сугышыннан соң тормышка аша. Әлеге сугышта Туктамыш, җиңелеп, янган Сарайны ташлап качарга мәҗбүр ителгәч, Алтын Урда тәхетенә күпмедер ыгы-зыгылардан соң Тимер Котлык утыра. Чыңгыз нәселеннән чыкмаганлыктан, Идегәйнең хан булырга хокукы булмый, әмма ул хакимият башына үзе үк менәргә булышкан хан янында олуг карачы-бәк сыйфатында фактик идарәчегә әверелә һәм шактый еллар дәвамында аннан соң тәхеткә менгән Шадыбәк, Булат Солтан, Тимербәк исемле урта кул ханнар янында да, асылда, тулы хокуклы җитәкче булып кала. Чөнки олуг карачы-бәк Урданың идарә системасында урнашкан тәртип буенча әмирләр әмире, гаскәр башлыгы, суд һәм дипломатия эшчәнлеген үз кулында тотучы түрә булып исәпләнгән.

Туктамыш кебек үк, Идегәй дә Алтын Урданың бердәмлеген торгызуга һәм куәтен арттыруга алына һәм шушы юнәлештә җитди эшләр башкара: төрле реформалар үткәрә, шәһәрләрне төзекләндерә, сәүдәне киңәйтә, кол сатуны тыя. Шулай ук үзен хәрби башлык, кыю полководец буларак та таныта: башта тәхетен кире кайтару өчен көрәшүче Туктамышка ярдәм итәргә дип алынган Литва кенәзе Витовтның әлеге хан гаскәре белән берләштерелгән явын тар-мар итә, аннары Харәземне һәм Азовны яулап ала, Мәскәүгә һөҗүм итеп карый.

Идегәй Аксак Тимер белән мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча да оста эш итә, илчеләр һәм бүләкләр җибәрү, әмирне олылавын белдерү исәбенә аның яу белән килүен булдырмый кала. Шул рәвешле, ул илне кабат аякка бастыру, аның куәтен, абруен күтәрү буенча шактый гына эшчәнлек күрсәтә. Әмма, тарихчылар бик дөрес раславынча, Алтын Урда дәүләте аңа кадәр үк инде акрынлап таркалу дәверенә кергән була. Аны Туктамыш та, Идегәй дә туктатып кала алмый. Ханлыкка дәгъва итүче Чыңгыз оныкларының үзара көрәшүләре-тарткалашулары, урыннарда сепаратизм, ягъни аерылып чыгарга омтылышның көчәюе моңа зур киртә булып тора. Чыңгыз нәселенә карамаса да, олуг әмир Идегәй шул фетнә-алышларның корбанына әверелә: аны Туктамышның улы Кадыйрбирде явы белән ике арада булган сугыш вакытында үтерәләр.

Туктамыш белән Идегәйгә бәйләнешле реаль мәгълүматларга һәм вакыйгаларга болай киң тукталуыбызның сәбәбе, һичшиксез, «Идегәй» дастанының асыл мәгънәсен мөмкин кадәр объектив, дөрес итеп аңлау ихтыяҗы белән бәйле, чөнки фольклор һәм әдәбият белемендә әлеге әсәрне аңлау-аңлатуда бер-берсенә кискен каршы килә торган карашлар яшәп килә.

Шунысын искәртик: тарихи «Идегәй» эпос-дастаны алда сүз барган факт һәм вакыйгаларның шактыен жанр таләбенә буйсындырып файдаланган һәм, безнеңчә, иң күзгә бәрелгәне – аларны чичән-җырауларның (без монысын алда күрербез) социаль заказчыларның күзаллау призмасы аша да үткәргән. Шул ук вакытта әсәрдә эпос традициясеннән килә торган эпик уйланма һәм әкияти-мифологик элементлар да урын алган.

Дастан Туктамышның атаклы лачынын бирүне сорап язган хаты өчен Аксак Тимерне ямьсез итеп хурлавын бәян итүдән һәм, әлеге лачын балаларын аңа сатуда гаепләп, үзенең бөркет караучысы Котлыкыяны һәм аның гаиләсен юк иттерүен тасвирлаудан башланып китә. Әмма булачак каһарман могҗиза белән исән кала. Аны әтисенең дусты Җантимер бишектә чакта үз баласы белән алмаштыра һәм итек кунычына яшереп алып чыга, шуның өчен исемен дә Идегәй (Итекәй) дип куша. Җантимернең ишле гаиләсендә бала, елкы һәм куй көтеп, Кобогыл диган икенче исем белән үсә. Эпос жанрына хас батыр балачак һәм иртә өлгерү мотивларына бәйле рәвештә, елдан-ел гадәттән тыш сәләтен, искиткеч сыйфатларын арттыра барып, «уникегә җиткәндә, Алпамыштай ир булып» җитешә, ә инде унбишенә җиткәч, көрәшеп, җәйләүдәге балаларның барысын да берәм-берәм егып чыга да, аларның үзе тау итеп өйгән киемнәре өстенә утырып, «Туктамыш хан тәхетенә мин мендем» дип сөрән сала.

Шул рәвешле, әсәрнең башлам өлешенә борынгы халыкара сюжет килеп керә: әлеге традицион эпик сюжеттагы кебек, дастанда да югары катламнан чыккан герой – көтүче, әнә аның да ике исеме бар, ахырда ул да югары дәрәҗәгә ирешә. Белүебезчә, бу сюжет Сөләйман пәйгамбәрнең прототибы булган яһүд патшасы Соломон турындагы хикәяттән үк башлангыч ала.

Туктамыш хан белән очрашу вакытында, үзенең ифрат акыллы җаваплары белән шаккатырып һәм, Дөрмән бинең баласына карата чыгарган хөкеменең дә хан законы белән ярашуын исбатлап күрсәтеп, Кобогыл (Идегәй) үзенең гаҗәеп сәләтле булуын таныта. Аны хан сараена хезмәткә алалар. Монда ул тиз арада сул канат әмире дәрәҗәсенә күтәрелә һәм, батырлык күрсәтеп, читтән кергән дошман яуларын кыйрата. Өйләнгәч, Идегәйнең Норадын (Морадым) исемле улы туа. Үзе кебек батыр булып үссен дип, әтисе аны яуларга алып йөри. Гомумән, каһарман

ДАСТАН ҮРНӘГЕ

● Туктамыш хан.

һәр җирдә үзен чын пәһлеваннарча тота. Хәтта хан булып хан, ул килеп кергәндә, үзе дә сизмәстән, урыныннан торып баса. Хатыны Йәнбикә искәрткәннән соң, итәген тәхет белән тоташтырып чәнечкән энә шартлап сынгач кына, Туктамыш бу хәлгә үзе дә ышанырга мәҗбүр була. Шуннан соң алар Кобогылны агулап үтерергә хәл кыла, әмма ниятләре барып чыкмый – Идегәй исән кала.

Шулай итеп, төрле отышлы мотивлар, эпик алымнар ярдәмендә Идегәй образы гаять көчле шәхес рәвешендә, хәтта сарайның тәхет залында күренүе белән үк хан гаиләсен өркетә торган алып ир итеп тасвирлана. Болар каршына «Кобогыл исемле бу көтүче баласы кем икән?» дигән борчулы сорау килеп баса. Әмма ханның үз янына чакырткан тугыз кешедән торган бер генә батыры, бер чичән-җыравы да, шулай ук иң якын вәзире булган Җанбай да җавап бирә алмый. Шуннан соң вәзир һәм чичән Җанбай киңәше буенча Сарайга 195 яшьлек атаклы Субра-җырауны алып киләләр.

Төрле халыкларда иҗатында чичән-җыраулар (хәтта шаманнар да) гади җырчы гына түгел, ә төрле яшерен серләрне белүче, киләчәкне алдан күрүче күрәзәчеләр итеп тә тасвирлана. Субра-җырау да шундый ук сәләткә ия чичән була. Ул бал эчеп алгач, каршында торган Кобогылны кат-кат хикмәтле сораулар биреп сынагач, дөп-дөрес итеп ханга аның кем икәнен һәм киләчәктә нәрсә эшләячәген әйтеп бирә:

Бар Урдаңны алыр ул,
Тәхетеңә бау салыр ул...
Котлыкыя бәк улы
Идегәй ул – Кобогыл.

Субра-җырау, шулай ук форсаттан файдаланып, тиз арада качып киткән Идегәйне куып тотарга һәм башын кисәргә куша. Күрәзәлек итеп, бу юлы аңа карата кискен гаепләү сүзләре дә әйтә:

Исән-имин китсә ул,
Иделдән ары үтсә ул,
Шаһ Тимерне алып килеп,
Сарайны харап итәчәк.

Идегәй, билгеле, мәкерле, хәйләкәр Җанбайның хан исеменнән зур бүләкләр вәгъдә итеп чакыруына алданмый, Җантимер малайларын ияртеп, туп-туры Аксак Тимер иленә юл тота. Юлда барганда, ул әлеге солтанның Кара-Тиен (Тәгин?) Алып әсир итеп алган кызын коткара, Аксак Тимер боларны «алтын-көмеш тәңкәләр чәчтереп», зур хөрмәт белән каршы алганнан соң, Ак Беләк исемле әлеге кызга өйләнә.

Алтын Урданың һәм Туктамышның киләчәк язмышы Субра-җырау әйткәнчә булып чыга: Сарайны яндыруда үзе катнашмаса да, Идегәй, чыннан да (тарихи чыганакларга караганда, бу хәл 1391 елда була), Алтын Урда өстенә Аксак Тимер явын алып килә. Дастанда бу турыда болай диелә: «Сансыз чирү, кара яу – Идегәй аны апкилде». Үзенең туган иле Идел-йорт биләмәләренә килеп кергәч, аның күңеле тула, туган җир туфрагын үбеп, патриотик рухтагы сүзләрен тулгап әйтә. Әсәрнең бу гаҗәеп тәэсирле, образлы урыны хаклы рәвештә туган җиргә багышланган мәдхия-ода дип исәпләнә.

Ләкин туган җирен өзелеп яратса да, әтисен үтергән, аның үзен дә үтермәкче булган Туктамыш ханга карата Идегәйнең үч алу, ачу-куралмаучылык тойгысы көчлерәк булып чыга. Моңа шулай ук аның, Урта гасыр тарихчылары язганча, үзен зурга санап яки үз көчен сизеп, хакимият башына менәргә омтылуы да, һичшиксез, килеп ялганган булырга тиеш. Аннары тагын бер сәбәп: кат-кат җиңелүенә карамастан, Туктамышның зур чыгымнар, күп корбаннар таләп иткән сугышлар алып баруы, әлбәттә, халык арасында да ризасызлык тудырган. Дастанда бу тарихи факт «Халкы ханнан өркә инде, татарың белән нугаең ханга каршы купты инде» дигән сүзләр белән бирелә һәм Идегәйнең Туктамышка каршы яуда катнашуының янә бер сәбәбе итеп күрсәтелә. Димәк, үзенең шәхси дәгъваларын яки үз мәнфәгатьләрен тормышка ашыру өчен, яуда катнашканда, булачак хөкемдар илдәге эчке ризасызлыктан да файдаланган.

Дошман дәүләтнең гаскәрен Алтын Урдага китергәч, Идегәй, баш күтәрүчеләрне «каршы барып алам» дип, вакытлыча яудан аерылып китә. Аксак Тимер исә, ганимәт (трофей) байлыгын тизрәк үз кулына төшермәкче булып, сугышка башта үз гаскәрен, үз батырларын гына кертә. Әмма дастанда Туктамышның Кыпчак исемле пәһлеваны аларның барысыннан да көчлерәк итеп сурәтләнә, һәм әмир гаскәре хурлыклы җиңелү алдында кала. Бу – эпик уйланмага корылган, әмма, безнеңчә, баскак Аксак Тимергә каршы башта батырларча каршылык күрсәтелгәнлегенә ишарә итә торган бер дәлил.

Менә шул киеренке бер чакта яуга үзенең сугышчылары белән Идегәй килеп кушыла. Дастан, Кыпчак бинең батырлыгын калку итеп сурәтләгән кебек, Идегәйнең каһарманлыгын да героик эпостан килүче алымнар ярдәмендә гаять көчле итеп тасвирлый. Берүзе мәйдан тотып, ул «аждаһадай сулаган булат кылычы» белән Туктамыш гаскәрләрен кыра. Соңрак аңа баһадир итеп сурәтләнгән улы Нурадын да ярдәм итә. Кайбер хезмәтләрдә, Идегәйне акларга тырышып, әлеге сугышны Литва кенәзе Витовт гаскәре белән Алтын Урда арасында 1399 елда булган орышка кайтарып калдырырга тырышу бар. Бәлүебезчә, Бурсыклы елгасы буенда барган зур сугышта Витовтның Туктамыш гаскәре белән берләштерелгән явына каршы олуг карачы-бәк Идегәй җитәкчелек иткән гаскәр көрәшә, һәм, чыннан да, каршы якны җиңә, әмма дастанда ул хакта, асылда, бернинди дә сүз юк.

Алтын Урда җирендә булган 1391 елгы сугыш, әлбәттә инде, гомумиләштерү максатыннан чыгып, дастанда Аксак Тимернең 1395 елгы икенче җимергеч явы белән бергә кушып тасвирлана. Тарихи чыганаклардан мәгълүм булуынча, үзе катнашкан беренче сугыштан соң Идегәй баскынчы Аксак Тимер белән арасын тәмам өзә һәм, биш вакыт намазын укучы һәм гөнаһлары өчен куркучы диндар кеше буларак, әмирнең үз янына җибәргән илчесенә болай ди: «Үзегезнең хуҗагызга барыгыз да, кулын ялап, безнең араларышуыбызга инде чик куелуын, моннан ары минем аңа эшем-катнашлыгым юклыгын әйтегез, чөнки мин Аллаһтан куркам».

Туктамыш ханның, Сарай шәһәрен һәм тәхетен ташлап, яраннары һәм исән калган яугирләре белән качып китәргә мәҗбүр булуы да Аксак Тимернең Идегәй бөтенләй катнашмаган икенче явы вакытына – 1395 елга туры килә. Киткәндә ул, илен дошман кулына калдыруы өчен уфтанып һәм «ерактан сине күрә алмам, тиз генә әйләнеп кайта алмам инде» дип, туган йорт-җире һәм халкы белән саубуллаша. Шушы уңайдан Туктамышның Идел-йортка багышлап әйткән мәдхиясе шулай ук гаҗәеп образлы булуы, лирик-эмоциональлеге белән аерылып тора. Чөнки, бердәмлеген һәм куәтен кайтару өчен, үзе күп көч салган дәүләте аның өчен дә бик якын, кадерле була.

Идегәй исә, Сарайда Аксак Тимерне калдырып, улы Норадын һәм яугирләре белән бергә шунда ук Туктамыш эзеннән киткән итеп тасвирлана. Димәк, монда да сәнгати-эпик гомумиләштерү, уйланма һәм булган хәлләрне бергә үрү дәвам итә. Әсәрдә хан, төньяк тарафка юл тотканда, үз артыннан җимерек хәрабәләр калдырып барды, «…әзгәри суккан Әтрәчне эргәсеннән куптарып, нократ (көмеш акча) суккан Болгарны нөргәсеннән куптарып, төнгә үтте Туктамыш» дип күрсәтелә. Һәм шушыннан алда гына Туктамышның әлеге текст белән авазлаш булган «…айлык юлым алдан алырмын, Болгардаен калам бар, Болгар йортын алырмын» дигән сүзләре дә китерелә. Белгечләр раславынча, мондый урын, дастанның башка вариантларында юк. Җыйнама версияне төзегән Н.Исәнбәт үзе әлеге урынны бер укытучы вариантыннан алдым дип күрсәткән. Ничек кенә булмасын, Туктамыш хан Болгар каласын җимерүче итеп күрсәтелгән сүзләрдә фактларны бутау, анахронизм ярылып ята. Чөнки Туктамыш гаскәрләренең баш бирергә теләмәгән Болгар җирен яу белән бастырып китүе чынлыкта 1382 елга туры килә. Ә инде Болгар каласы, асылда, Туктамыш та, Идегәй дә дөнья куйганнан соң гына, ягъни 1431 елда Мәскәү кенәзе Василий Тёмныйның гаскәр башлыгы Фёдор Пёстрый тарафыннан җимерелә. Бу мәгълүмат исә дастанда «урысның бер гавере – авызы төкле кенәзе» изге шәһре Болгарны һ. б. калаларны «яндырып, көлгә-ташка болгап» китте рәвешендә бирелә.

Әмма Туктамышны эзәрлекләп барганда, Идегәй үзенә карата да кискен шелтә-гаепләү сүзләре ишетә. Болгар хәрабәләре арасында утырган ил агасы Бодайби, аның йөзенә бәреп, мондый сүзләр әйтә:

Бу җиһанның фетнәсе
Аксак Тимер дошманны
Сарайга алып китердең,
Йөз баһадир ирәннән
Йорт-җиреңне бастырдың.

Күренүенчә, бу сүзләрдә туган йорт-җир белән чит илнең баскак ханы капма-каршы куела. Идегәйнең исә, халык әйткәнчә, өрә белмәгән эттәй үз оясына бүре китерүе, Аксак Тимер белән союзга кереп, аның явын үз иле өстенә алып килүе кырыс хөкем ителә. Дастанда «шул ук вакытта иленә яу килүгә Туктамыш үзе дә гаепле» дигән фикер дә урыны-урыны белән чагылып китә. Мәсәлән, Аксак Тимернең, яуга чыгар алдыннан, «минем кулдан нан җыеп, такка (тәхеткә) менгәч мас булган (масайган) Туйгуҗа улы Туктамыш» дип әйткән сүзләре һәм аның үз иленә (Сәмәркандка) басып керүен гаепләп телгә алуы – моңа бер мисал.

(Дәвамы киләсе санда).

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы.

Атананың сәяси мизгелләре

ИҢ ЮГАРЫ ХӨКЕМНЕ ДӘ ОНЫТМЫЙК

Халыкара җинаять суды (МУС) узган атнада, Россия Президенты В.Путин белән балалар омбудсмены М.Львова-Белованы, хәрби җинаять кылуда шик белдереп, кулга алуга ордер биргән. Алар Украина территориясеннән балаларны законсыз төстә һәм күпләп Русиягә депортацияләүдә гаепләнә икән. Искәртеп үтик, Рим статуты буенча МУС дөньяның 123 илендә ратификация үткән. Алар аны таный һәм карарларын да үти. Ә Россия аның юрисдикциясен танымый һәм карарларын да әһәмиятсез дип саный. Анда хәтта әлеге хөкем карарын чыгарган судьяларга карата санкцияләр кертергә дә чакырганнар. Биредә күпләр өчен бүген иң гадел суд булып, мөгаен, Басман хөкеме саналадыр. Тик, иң югары хөкем барлыгын да онытмасак иде.

20 март көнне Россиягә өч көнлек визит белән КХР рәисе Си Цзиньпин килде. Мәскәү аны кабул итүгә нык лап әзерләнде. Россия Президенты В.Путин аңа кадәр «Жэньминь жибао» газетасында «Россия һәм Кытай – киләчәккә юнәлдерелгән партнерлык» дигән мәкалә дә бастырып чыгарган. Ул анда бу ике илнең дөньяда күпполярлы һәм гадел дөньяви тәртип урнаштыру өчен тырышулары турында язган. Украина мәсьәләсендә Кытай тәкъдим иткән планны хуплавы һәм Россиянең андагы кризисны сәяси вә дипломатик юл белән хәл итүгә әзер булуы турында белдергән. Әмма бүген анда урнашкан геосәяси чынбарлыкны исәпкә алу шартын да куйган. Мәскәүдә исә Кытай лидеры белән ике арадагы сөйләшүләр төрле форматларда үтәчәк.

Узган атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. РФ Президенты В.Путин Кырымга һәм Мариупольгә сәфәр кылды. Тикшерү комитеты башлыгы А.Бастрыкин Украинада кылынган җинаятьләр буенча Россиядә ниндидер халыкара суд органы булдырырга һәм анда карау өчен мөмкин кадәр күбрәк материаллар тупларга тәкъдим иткән. Президент В.Путин махсус хәрби операциянең Ростовтагы команда пунктында үткән киңәшмәдә катнашкан һәм аннан соң озак кына вакыт Генераль штаб башлыгы В.Гепасимов белән киңәш-табыш иткән. НАТОның Рамштайн форматында үткән утырышында Украинага яңа хәрби ярдәм күрсәтергә карар кылынган. В.Путин Мәскәүдә үткән «Күпполярлы дөньяда Россия-Африка» дигән халыкара парламент конференциясендә чыгыш ясаган.

Фоат УРАЗАЙ.

Афзал ШАМОВ

Яңгырлы кичтә

Күзгә яңгырлы кичләрнең берсе иде. Мондый кичләр Камиләгә, үсеп бара торган шәһәр читендәге яңа йортларның берсендә кечкенә кызы белән генә яшәүче ирсез хатынга, ничектер авыр, моңсу тәэсир итә иде. Нигә шулай тәэсир итәдер. Әгәр сез моны аның үзеннән сорасагыз, ул сезгә аны теле белән аңлатып бирә алмас, бары, зур коңгырт күзләре белән гаҗәпләнеп карап, елмаер гына иде. Нәрсә бу, күңелнең ерак почмагында сакланып, йомылып яткан сагышның уянуымы, табигатьнең караңгылык белән алып килгән кичке моңсулыгымы, әллә утыз яшендәге сәламәт тәнле хатынның җенси юксынуымы? Яисә көндезләрен төзелештә шау-гөр килеп эшләп йөргәннән, кешеләр белән аралашканнан, сөйләшкәннән һәм иптәшләрчә, дусларча шаярышканнан соң, бу аерым фатирга кайткач, ялгыз калгач, күңелнең мондый яңгырлы, җилле кичләрдәге беркадәр шаулы тынлыкны кабул итеп бетерә алмавымы? Нәрсә генә булмасын, мондый кичләрдә, бигрәк тә вак яңгыр сибәләп торган сәгатьләрдә, Камилә үзенең күңел тынычлыгын нигәдер югалта. Нәрсәдән бу, ялгызлыктанмы? Юк, ялгызлыктан булмаска тиеш. Чөнки Камиләне ялгыз дип әйтеп булмый. Әнә бүлмәнең бер читендә, кечкенә тимер караватта аның кызы, уң кулын яңагы астына куеп, тыныч кына йоклап ята. Төрле төстәге ситсы кисәкләреннән кораштырып сырылган юрганы муеныннан ук ябынган, кыска кара чәчләре, чәбәләнеп, тузгып, мендәр өстенә төшкән; кулын яңагы астына куйганга булса кирәк, иреннәре кемнедер үчекләгән сыман бераз бөрешеп, кыйшаеп тора, ә үзе бер уңайга сузып-сузып сулый.

Кызы быел гына мәктәпкә керде. Әнә карават башында букчасы эленеп тора. Аның эчендә әлифбасы, дәфтәрләре, карандашлары һәм көн саен диярлек каләме бозыла торган ручкасы.

Юк, Камилә ялгыз түгел, үзен ялгыз итеп сизми. Шулай да ул мондый моңсу кичләрдә, җитмәсә, җиле, ара-тирә көчәеп китеп, вак яңгыр тамчыларын тәрәзәгә китереп сипкән сәгатьләрдә, күршедә торучы берәр иптәшенең яисә башка берәр якын кешенең көтмәгәндә аның ишеген дусларча ачып килеп керүенә чын күңелдән шатлана. Шундый чакларда ул, җанланып, ачылып китә, иптәше алып килгән яңа хәбәрләрне тыңлый-тыңлый, газлы плитасын кабыза, чәйнегенә су тутырып, кайнарга куя, бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлгә табын әзерли. Иптәшләренең, искә алып, килеп чыгуларына шатлануын бу минутларда аның теле белән әйтелгән сүзләреннән генә түгел, йөзеннән, бөтен торышыннан, җитез, җиңел хәрәкәтләреннән, хәтта аяк адымнарыннан аңлап була.

Кызы да әнисенең шатлыгын сизә. Ул да, кунакның игътибарын үзенә җәлеп итәргә теләп, тәкелдәштергәләп, алар тирәсендә айкала, өстәлгә йә тегесен, йә бусын алып килеп куя, әнисенә булыша, үзенең дөньяда барлыгын, «зур кыз булып үсеп килүен күрсәтә.

Камилә бүген дә бу моңсулыкны ялгыз гына кичермәс кебек. Кемдер аның ишеген шакылдатты. Күршедәге дусларыннан берсе булса кирәк. Ай, рәхмәт яугырлары, кешенең эче пошуын, моңсулыгын каян беләләр дә каян кереп җитәләр! Ләкин нигә шакыйлар, нигә звонокка басмыйлар? Әллә бозылганмы?

Камилә, кулындагы типчүен бер читкә куеп, урыныннан торды да, ялангач аякка кигән туфлилары белән әкрен генә басып, ишек катына барды:

– Кем ул?

Сорауны ишетмәделәр ахры. Яңадан шакылдаттылар. Камилә, бер кулы белән ишек тоткасын, икенче кулы белән бикне тотып, тавышын күтәрә төшеп, кабатлап сорады:

– Кем бар анда?.. Кем кирәк?

Тыштан ниндидер ир кешенең тавышы ишетелде:

– Бу мин... Мин. Камилә Закирова монда торамы?

«Кем икән бу? Нигә Закирова?..»

Закирова аның кияүгә чыкканда язылган, соңыннан алыштырылган фамилиясе иде. Ул фамилияне инде Камилә онытып бара. Дөресе, оныттыра, күңеленнән сызып ташларга, аны бервакытта да исенә төшермәскә тели ул.

Ишекне, ачарга теләп, тартып карадылар һәм әлеге сорауны яңадан кабатладылар.

Хатын ишек төбендә бер мизгелгә тынып калды, нәрсә дип җавап бирергә белмәде. Аннары, үзе дә сизмәстән, каушап, кабалана төшеп, чәчен төзәтте, өстендәге күлмәгенә карап алды һәм шундый ук тизлек белән чөйдәге халатын алып киде, җыеп, җыйнак итеп, билбавын кысып бәйләде. Зәңгәр җирлеккә вак алсу чәчәкләр төшкән озын халат хатынны алыштырган сыман, кинәт буйга үстереп, зурайтып җибәрде. Ул үзенең яхшы сакланган буй-сыны, бугач нечкәреп, нәфисләнеп киткән биле белән бу чәчәкле халат эчендә балалы хатынны түгел, ә буйга җиткән, өлгергән кызны хәтерләтә иде.

Ул арада тышта тагын бер кеше тавышы ишетелде. Бусы – күрше Шәйхулла карт тавышы. Шакылдатканны ишетеп чыккан булса кирәк. Аның шундый яхшы гадәте бар. Алар нәрсәдер сөйләшеп алдылар. Шуннан соң кайсыдыр звонокны басты. Ул, Камиләне сискәндереп җибәреп, баш очында кискен генә шалтырап алды һәм шуның артыннан ук Шәйхулла карт тавышы ишетелде:

– Кызым, ач, сине сорыйлар. Авылдашың.

Камилә инде бу кешенең авылдашы түгеллеген күңеленең ниндидер бер сизгер өлеше белән төшенеп алган иде. Шулай да әле ул аның кем икәнен белми. Нәрсәнедер, кемнедер хәтерләтә торган тавыш. Кем булуы мөмкин?

Әгәр Шәйхулла картның тавышын ишетмәсә, аның шунда, ишек төбендә басып торуына ышанмаса, мондый караңгы кичтә ул ят кешегә ишеген ачмас иде. Картның тавышы аның күңелен тынычландырып җибәрде.

Ишек төбендә ике кеше басып тора. Берсе Шәйхулла карт (чыннан да, ул шакылдату тавышына чыккан икән, өстенә дә киеп тормаган, гадәттәге калын бумази күлмәгеннән). Икенчесе соры плащлы, күн итекле, кара кепкалы кеше. Күләгәдәрәк басып торганга, төсен-битен, яшен аерырлык түгел. Басып торышына караганда, утыз белән кырык арасындагы кеше булса кирәк. Кулында юл һәм дөнья газабын шактый күргән чемодан.

Камилә, танырга теләп, текәлеп карады: «Кем соң бу?»

– Үзеңә кунак килгән, ә үзең ишегеңне дә ачмыйсың, – диде Шәйхулла карт һәм, якын итеп, кеткелдәп көлеп җибәрде.

Кунак та тавышын чыгарды:

– Исәнме, Камилә!.. Әллә танымыйсың да инде?

Хатын гаҗәпләнеп кычкырып җибәрүдән үзен чак тыеп калды. Бу – «ул» иде, кайчандыр аның ире булган, соңыннан аны ташлап киткән, озак еллар хәбәрсез югалып торган, бүлмә эчендә йоклап ятучы баланың әтисе булып саналган, әмма бер минут та әти булмаган һәм булырга теләмәгән кеше иде.

«Кертергәме, юкмы?» – дип уйлады хатын. Башына беренче килгән уй шул булды. Ул, нәрсә дип җавап бирергә һәм нишләргә белмичә аптырап, телсез калып, ишек яңагына сөялде. Бу минутта аның берәр төрле сүз әйтерлек, телен һәм кулын кыймылдатырлык көче юк иде. Ничектер ул үзен кинәт хәлсезләнгән, кыйналып ташланган кебек хис итә иде.

(Дәвамы киләсе санда).

Азнакайдагы Балтач

(Дәвамы.
Башы 10 нчы санда.)

Авылдагы өченче, ярлы катлау (чәчүлекләре 4 дисәтинәгә кадәр) базар белән аз бәйләнгән. Аларның җитештергәне гаиләне туйдыруга китеп барган. Еш кына алпавыт һәм кулак хуҗалыкларына төрле эшләргә ялланганнар.

Иң түбән катлау – авыл пролетарийлары. Аларның чәчүлек җирләре бик аз (0,15 дисәтинәгә кадәр) яисә бөтенләй булмый. Шуңа да күп вакыт көнлекчелеккә йөриләр яисә батрак булып эшлиләр.

Билгеле дәрәҗәдә Балтачта һөнәрчелек тә үсеш ала. Беренче чиратта, агач эше осталары. Алар арасында балта осталарын (Вәлиулла Габитов, Сәлахетдин Йосыпов, Мөхәммәтсафа Гәрәев, Хәбибулла Шәрифуллин, Әфләтүн Айчуаков, Йосыф Шәрәфетдинов, Нәбиулла Кәлимуллин, Мөхәммәтзарип Ихсанвәлиев) һәм столярны (Габделбәдигъ Габделвәлиев; ул балта остасы да) күрәбез. Мөхәммәтзарип Шәриповның 25 яшьлек улы кирпеч сугу белән шөгыльләнә. Хәйрулла Әхмәдиев (54 яшь) итекче буларак билгеле. Хәсәнша Гыймазетдинов (36 яшь) – йон тетү остасы.

Балтачка читтән килеп төпләнгән һөнәрчеләр дә була. Беренчесе – тимерче Гайфетдин Хәйретдинов (26 яшь), Тайсуганда туып-үскән. Монда Сәлахетдин Йосыповка айга 50 тиен түләп фатирда тора. Аның аттан башка мал-мөлкәте юк.

Тегүче Хәбибулла Әдһәмов (37 яшь) ерактан, Казан шәһәреннән килеп яши башлый. Үз йортында хатыны (30 яшь), улы һәм кызы белән тора. Аның аты, сыеры, 3 сарыгы, 1,88 дисәтинә чәчүлеге була. Тегүчелек белән күп вакытын – яз (2 ай), җәй (1), көз (3) һәм кыш (3) айларында шөгыльләнә.

Кышка керү белән Гайфулла Габделхәбиров (41 яшь), Фазулла Мәндикәевлар (46 яшь) кәйлә, чүкеч, лом, тимер чөй, көрәк, канат, кыршау һәм чиләкләр алып тирә-як авылларга, якындагы хутор-имениеләргә кое казырга чыгып китә. Башкалары кебек, бу шөгыль дә үзенә күрә осталык-тапкырлык таләп иткән. Теләсә кайдан түгел, су өстәрәк яткан катламны белеп-өйрәнеп казырга кирәк бит. Югыйсә, хезмәтең юкка чыгуны көт тә тор.

Читтә йөреп эшләүчеләрдән тагын Кашшафетдин Әхмәткәримов (35яшь), ул Бөгелмәдә кучер булып урнашкан. Хатыны белән 2 кызы авылда яши. Мал-туары юк, ә читтән арендага алган басуда арыш һәм борай чәчүлекләре нибары 0,94 дисәтинә була.

Шулай итеп, Балтачта халыкның игенчелек һәм терлекчелектән тыш та шөгыльләре күп булуы күзгә ташлана. Югарыда телгә алынган кешеләрнең күпчелеге өчен һөнәрчелек өстәмә табыш чыганагы булып тора. Ә менә чәчүлексез хуҗалыкларда ул – төп яшәү чыганагы.

Авылның социаль-икътисади хәлен тасвирлауны төгәлләр алдыннан тагын бер-ике мәгълүматка тукталыйк. 1900 елда Балтачта 207 хуҗалык исәпләнә. Аларның бише (исемнәре югарыда телгә алынды) читтән күчеп килгән. Авыл этап юлында урнашкан. Шунлыктан монда этап фатиры була. Тоткыннар һәм аларны озатучы конвой тукталган анда. Әлеге фатир Габдулла Ярмөхәммәтов (21 яшь) йортында урнашкан була. Моның өчен ул елга 40 сум күләмендә аренда хакы алган.

1908 елның көзендә Балтач халкы икенче җәмигъ мәчет салырга рөхсәт ала. Яңа мәхәлләгә 1910 елның язында мөәзин һәм мөгаллим булып Таҗетдин Хәйретдинов раслана. Ә көзгә кергәч, хатыйблыкка Габделгали Әхмәтвәлиев указ ала. Әлеге яшь хәзрәт – беренче мәхәллә хатыйбы Әхмәтвәли Габделбәдигъ улы Баязитовның улы. Әхмәтвәли хәзрәт үзе Мофаздал Мөхәммәтвафа улы Динмөхәммәтов (ул 1909 елдан имам һәм мөгаллим) белән бергә эшләгән.

Яңа мәчет ачылу үзе бер зур вакыйга булса, икенчесе – кырчылыкка мал чөгендере культурасын кертү. 1913 елда «Самара крестьян хуҗалыгын яхшырту җәмгыятенең» турыдан-туры катнашы белән башкарыла бу эш. Моның өчен җәмгыять Туйкә кредит ширкәте аша Туйкә, Уразай, Әсәй һәм Балтач авылларындагы 44 хуҗалыкка бушлай ярты пот мал чөгендере орлыгы өләшә. Балтачта чөгендер 9 хуҗалыкта үстерелә. Аларга 0,12 фунттан 0,25 фунтка (фунт – кадак, гөрәңкә, ягъни 409,5 граммга тигез булган үлчәү берәмлеге) кадәр орлык өләшенә. Габделвәли Исламголов, Заһидулла Яруллин, Мөхәммәди Мөхәммәтҗанов, Әхмәтҗан Мөхәммәтҗанов, Гыймаделислам Фәхрелисламовлар 10-16, Шәфыйгулла Галиуллин, Минһаҗетдин Низаметдинов, Габдулла Мөхәммәтҗанов, Закир Габделвәлиевләр 2-7 пот чөгендер уңышы алуга ирешә. Статистиклар беренче ел өчен әйбәт кенә күрсәткеч, дигән нәтиҗәгә килә.

Әмма аның икенче елында сугыш башлана. Дистәләгән балтачлылар беренче айларда ук мобилизациягә эләгә. 1915 елның апреленә 73 кеше (Миңлегали Айчуаков, Якуп Әхмәдиев, Хәбибрахман Әхмәтгалимов, Ибраһим Әхмәтҗанов, Исхак Әхмәтҗанов, Зәки Габделлатыйпов, Әхмәтлатыйф Галиев, Миңлехәлим Галиев, Нургали Габделвәлиев, Габдрахман Галимов, Әхмәтзарип Галимов, Фазулла Гарифуллин, Ибраһим Гафиятуллин, Кашшафетдин Гыймадетдинов, Котдус Йосыпов, Газизулла Кәлимуллин, Нигъмәтулла Латыйфуллин, Фазулла Латыйфуллин, Габделислам Миңлебаев, Солтангали Миңлекәев, Мостафа Мөхәммәдиев, Мөстәкыйм Мөхәммәдиев, Вәлиулла һәм Мөсәгыйть Нәбиуллиннар, Габделбәдигъ Нәфыйков, Сабир Нәфыйков, Әхмәтлатыйф Низаметдинов, Закир Рәхимҗанов, Шакир Рәхимҗанов, Садретдин Низаметдинов, Габделгали Нургалиев, Габдулла Сафиуллин, Баһман Сафиуллин, Ногман Сафиуллин, Насретдин Сәетбатталов, Садретдин Сәетбатталов, Фазулла Сәйфуллин, Хәйрулла Сәйфуллин, Миңлегали Сәлимгәрәев, Корбангали Сәфәргали, Мәүләви Ситдыйков, Әхмәтгали Ситдыйков, Габдулла Фазуллин, Заһид Хәбибрахманов, Латыйфулла Хәбибрахманов, Мөхәммәтгали Хәбибрахманов, Шәфыйгулла Хәбибрахманов, Мөхәммәтшакир Хәйдәров, Миңлегали Хәйруллин, Миңлевәли Хәйруллин, Заһидулла Хәлиуллин, Җиһангир Шаһивәлиев, Хәбибулла Шаһидуллин, Шәйхулла Шаһидуллин, Җиһангир Шаһидуллин, Миңлегали Шаһиев, Исмәгыйль Шаһимәрданов, Мәүлетислам Шәйхелисламов, Насретдин Шәйхетдинов, Солтангир Шәйхетдинов, Минаҗетдин Шәрәфетдинов, Сәлахетдин Шәрәфетдинов, Нигъмәтулла Шәфыйгуллин, Габдулла Ярмөхәммәтов, Шаһимөхәммәт Ярмөхәммәтов, Шәмсулла Ярмөхәммәтов, Галиулла Яруллин, Заһидулла Яруллин, Гариф Җаббаров, Мөхәммәтгали Җаббаров, Тәхаутдин Җамалетдинов) герман сугышына китә.

Әлеге исемлектә бертуганнар күп. Галиев, Мөхәммәдиев, Низаметдинов, Рәхимҗанов, Сафиуллин, Сәетбатталов, Сәйфуллин, Хәбибрахманов, Ярмөхәммәтовлардан һ.б. нәселләрдән берьюлы икешәр яисә аннан күбрәк кеше сугышка алына. Күпчелеге – 1914 елда, калганнары 1915 елның апрель аенда мобилизацияләнә.

1915 елның көзендә авыл тагын 26 ир-атны сугышка озата. Болар – Габделгалим Әхмәтҗанов, Насыйбулла Вәлиуллин, Закир Габделвәлиев, Габделкадыйр Галимов, Зиннур Гарифуллин, Шаһидулла Гарифуллин, Гыймаделислам Гафиятуллин, Әхмәтвәли Зөлмөхәммәтов, Рухылбаян Мөхәммәтзакиров, Мөхәммәтсабир Мөхәммәтсафин, Шәфыйгулла Мөхәммәтшакиров, Фәхрулла Нәбиуллин, Хәйдәргали Нургалиев, Габделхисан Сафиуллин, Хәбибулла Сафиуллин, Сәлимҗан Сәлимгәрәев, Миңлегали Сөләйманов, Садретдин Фәхретдинов, Миңлегали Харисов, Шириәздан Йосыпов, Шаһидулла Равилов, Шакир Шаһидуллин, Миңлегали Шәйхетдинов, Хәйретдин Шәйхетдинов, Хөснулла Шәфыйгуллин, Миңнулла Яруллин (ТР ДА, 1124 фонд, 1 тасв., 28 сакл. бер.).

Шулай итеп, 14 ай эчендә Балтачтан 99 кеше мобилизацияләнә. Калган чор буенча мәгълүматлар юк, шулай да 1917 елга чаклы тагын шул чама кеше хәрби хезмәткә алынган дип фараз кылсак, ир-атларын сугышка озатмаган гаиләләр авылда бик аз кала түгелме? Шуннан гына да бу сугыш күпме кайгы-хәсрәт һәм авырлыклар алып килүен чамаларга була.

1916 елда Балтачта 250 хуҗалык, 568 ир-ат һәм 664 хатын-кыз була. Ир-атлар күпкә азрак, әмма сугыш әле бетмәгән. Төбәккә качаклар да килеп урнаша. Балтачта дүрт ир-ат качактан тыш, 2 сугыш тоткыны да яши.

Авыр сугыш елларында да балтачлылар күп терлек асрый һәм мул иген үстерә. Монда 522 ат (шул исәптән 435 эш аты), 607 мөгезле эре терлек (305 сыер), 1631 сарык һәм 198 кәҗә исәпләнә. Чәчүлекләр мәйданы 863,95 дисәтинә тәшкил итә. Шуның яртысыннан күбрәген арыш (415,15 дисәтинә), калган өлешен солы (127,20), карабодай (101), борчак (55,5), тары (48,10), бодай (44), борай (35) алып тора.

Россиядә большевиклар хакимияте урнашкач, Балтачта авыл башкарма комитеты оештырыла. 1918 елда Шакир Хәйруллин – комиссар, Шакир Җомаголов һәм Габдулла Галиевлар комитет әгъзалары итеп сайлана. Ул вакытта сайлаучылар 800 кешедән торган.

1920 елда монда 291 хуҗалыкта 1363 кеше (шул исәптән 15 рус) яши. 1926 елда әлеге күрсәткечләр шактый кимрәк – 232 хуҗалык һәм 1037 (шул исәптән 10 рус) кеше. Авыл Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә.

Утызынчы елларда балтачлылардан беренче репрессия корбаны Абдулла Ярмөхәммәтов була. Аны икенче категория белән раскулачивать итәләр. Мал-мөлкәтен хөкүмәткә алалар, үзен авылдан сөрәләр.

Бүгенге көндә Балтачта дүрт йөзләп кеше яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, почта бүлеге, медпункт һәм кибет эшли.

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

● Безне Магнитогорск каласы вокзалында «Соңгы татарлар» дип язылган плакат тотып каршы алучы милләттәшләр.

● Шәһәрнең «Татар рухы» мәдәни үзәге.

Урал татарлары:

Әлеге калада булганым юк иде. Уралга сәяхәт турында сүз кузгалуга ук, маршрутка Магнитогорскины да кертүләрен үзем тәкъдим иттем. Андагы иң куәтле металлургия комбинатын да, шәһәр нигезен дә безнең кыерсытылган, рәнҗетелгән, сират күпередәй газапларны кичкән татар «кулаклары» төзеп бирүен яттан белә идем, шулар салган таш каланы күрәсе, алар каны белән алар тире тамган туфрак алдында баш иясе килде...

● Без Магнитогорск шәһәр китапханәсендә.

Урал елгасы ярларының шушы урынында металлургия комбинатын төзү беренче бишьеллык планга ук кертелә. Ярар, план туды-тууын, ләкин бит әле эчке көчләр эзләп табасы бар. Менә шул чагында ил буенча урта хәлле һәм таза тормышлы крестьяннарны кулакка чыгарып читкә куу нияте дә туа. Советлар Союзы дигән аждаһадай илгә бушка җигә алырдай эшче куллар, күндәм коллар кирәк. «Кулакны сыйныф буларак юкка чыгарабыз!» – дигән тилемсә шигарь астында аларның байлыкларын тулысынча талау, ә үзләрен ярым-ялангач көенчә читкә сөрү башлана. Безнең татар – хуҗалар тәлинкәсен ялауда алыштыргысыз куштан, иң тугры кол. Татарстан буйлап акыл ышанмастай бәйге кузгала. Без бүген талантлы шагыйрьләр дип белгән Гамил Афзал, Басыйр Рәфыйков, сөрелгән җирдә туган рәссам Рафаил Бакировның әти-әнисен хәтта бүген дә сокланырлык өйләреннән куып, ат арбаларына чыгарып утырталар. Шолохов Щукарена тиң колхоз әктифләре – җыен әтрәк-әләм «сабыйга тимәсләр әле» дигән өмет белән 9 яшьлек Гамил астына яшерелгән яңа фуфайка белән яңа оекбашны да тартып ала. Күз яшьләренә чумып, авылдашларын каргый-каргый чит җиргә юл алган колонналар белән барча пристань һәм вокзаллар тула. Татарстан, үзендәге һәрбер район, һәр авылдан «кулак»ларны куып, алар санын 45 меңгә җиткерә һәм Бөтенсоюз «ярыш»ында Белоруссия, Казахстан, Азәрбайҗаннарны да узып, өченче урын яулый. Үз туганнарына карата милләт кылган мондый вәхшилекне чал кешелек тарихы әлегәчә белми...

Магниторск каласы һәм металлургия комбинаты калкып чыгачак Урал ярындагы далага 30 мең татарны китереп тутыралар. Чәнечкеле тимерчыбыклар белән уратылган 6 лагерь әзер, этләр, солдатлар бар, ә ни рәвешле урнашу, ни белән туклану, ничек исән калу турында коллар үзләре баш ватсын. Бер чарасыз халык һәр лагерьда әүвәл 75 әр чамасы землянка казып керә. Татар эшкә уңган бит, тиз арада кызыл балчыкка мал тизәге, үлән-салам өстәп һәм аны бала-чага, йөкле хатыннарга, «кулак»лар белән бергә сөрелгән әби-бабайларга кадәр күмәк таптап, сәмән «кирпеч»ләр ясыйлар. Бераздан лагерьлар эчендә сәмән бараклар пәйда була, аларны кызыл ләм белән буяп чыгалар, акшарлыйлар, түбәләре кояш астында кызып, стеналардан сасы исләр таралмасын өчен, такталар өстенә камыш сабаклары да җәяргә онытмыйлар. Монысы – үзләре һәм балалары өчен, ә иң мөһим һәм мәҗбүри булганы – комбинат төзелешен кызулату кирәк. Мылтыклы солдатлар һәр иртәдә ирләрне сафларга тезеп, төзелешкә куа. Анда исә КамАЗ төзелешендәге шикелле экскаватор вә бульдозерлар көтеп тормый, силос базыдай иң тирән котлованнарга тикле тимер көрәк белән актаралар. 1932 елда комбинатның тәүге корпуслары әзер була, чуен эретердәй мичләр сафка баса. Тик мылтыклы солдатлар эт өере кебек ябырылып торса да, землянка һәм бараклар эчендә әтиләренә ияртеп куылган сабыйлар бар бит әле. Алар өчен мәктәп төзү башлана, мөгаллимнәрен «кулак» хатыннары арасыннан эзләп әзерлиләр. Эшчеләрне азык белән тәэмин итү коточкыч хәлдә булгач, «кулак»ларга тавык-каз, кәҗә бәтиләре, хәтта сыер сатып алырга да рөхсәт бирәләр. Аларны әби-бабай, бала-чага карый, болыннарга йөртә. Чәнечкеле чыбык артына чыгып, бәрәңге һәм яшелчә дә үстерә башлыйлар. Инде йөзәрләгән сабый белән картлар төрле чирдән вафат булганнан һәм Татар зираты барлыкка килгәннән соң, шулай итеп, туклану да читкә сөрелгәннәрнең үз җилкәсенә калдырыла. Комбинатны тулысынча аякка бастыргач, беренче чиратта, шул ук кичәге «кулак»лар һәм аларның җитлегә башлаган уллары мартеннар һәм станоклар артына эшкә баса.

Ул вакытта татарлар милли йөзен саклый, урыслаштыруга да һич бирешми әле. Татарстанның һәрбер районыннан 500 гә якын мулла да, кулакка чыгарылып, «бөек төзелеш»кә сөрелгән була бит. Аларның байтагы муллалыгыннан баш тартса да, калганнары вафат булганнарга яшереп кенә җеназа да кыла, яңа туган сабыйларга исем куша, башлыкүзле булучыларга никахын да укый. Нәкъ шулар тәэсирендәдер,

● Дуслык йортындагы музейда татар почмагы.

● Шәһәрнең Халыклар дуслыгы йорты.

Магнитогорск

● Дуслык йортында үткәрелгән кичәдән соң.

катнаш мәктәпләрдә әүвәл татар сыйныфлары ачтыралар, аннары инде шәһәрдә дүрт татар мәктәбе дә эшли башлый. Калада Татар бистәсе, татар театры, татар базары, җыр һәм бию түгәрәкләре хасил була...

Чиләбе каласыннан Магнитогорск вокзалына поезд белән килеп төшкәндә үк, безне шәһәрнең «Татар рухы» исемле җирле автономия рәисе Кадиминур Таһиров белән Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институтының әлеге каладагы филиал башлыгы Салават Әхмәтҗанов «Соңгы татарлар» дип язылган үзе шомлы, үзе шаян плакат тотып каршы алган иде (икесе дә этиләренең чыгышлары буенча Аксубай районыннан). Берничә минутлык әңгәмәдән соң ук металлургия комбинатының Урал елгасы аръягында ятуын ачыкладык. Димәк, безнең рәнҗетелгән татар «кулак»лары да шул ук сул ярдагы лагерьларда газап чиккән, тәүге бараклар да шул урында калыккан бит инде. Шәһәр буенча сәяхәт кора башлагач та, без Салават әфәндедән безне «бабаларыбыз»ның тәүге нигезләре белән таныштыруын үтендек һәм Л.Лерон, Р.Галиуллин белән бергә Урал елгасының аръягына күчтек. Тәүге татар мәктәбе дә биредә эшли башлаган, тәүге зират та шунда. Ни кызганыч, зиратны кыргый агач үсентеләре каплап киткән, аннары утызынчы елларда безнең халыкка кабер ташлары бастырып куярга да ирек бирмәгәннәр. Яшереп кенә җеназа укыган, тәүге мәчет ролен үтәгән урыннарны да яңа производство цехлары, тимер юллар каплап алган инде...

Авыр сугышлардан соң, 1948 ел җиткәч кенә, ниһаять, читкә сөрелгән гөнаһсыз татарларга паспорт өләшә башлаганнар, ләкин якташлары тарафыннан нахакка рәнҗетелгәннәрнең берсе дә туган-үскән ягына кайтырга теләмәгән. Гамил абый Афзал, мәсәлән, туган авылы Такталачыкка сыңар тапкыр да кайтып күренмәде. Әти-әниләре Мамадыштан куылган Басыйр Рәфыйков та туган төбәген янә үз итмәде. Аларның һәркайсында бөтенләй башка бизмән; гаепләп тә булмый, чөнки аларны куганнарның берсе дә, читкә сөрелгәннәр кебек, мылтык түтәләрен дә, этләр талавын, юеш землянкаларны, каторгадай эш газабын, мал көтүедәй шыплап тутырылган сәмән баракларны кичереп яшәмәгән. Алар читкә тибелгән, әмма горурлыкларын гомерлеккә саклый белә торган кавемнән. Аларны читкә сөргән авыл Щукарьлары түгел, болар сокланырлык...

Сугыштан соң Уралның уң ярында яңа кала төзү башлангач, янә шунда камытка җигелгәннәр. Шәһәрнең күпчелек урамнары Сталин чорында төзелгән, биек түшәмле кирпеч йортлардан һәм Хрущев заманында Ленинград проекты белән аякка бастырылган, бишәр катлы панель «бараклар»дан хасил. Мондагы татарлар шушы яңа каланы һәм илдәге иң зур металл кою комбинатын төзүдә катнашулары, дәүләт көчләренең аларны сындыра, тезләндерә алмавы белән горур. Бәлки шуңадыр да, ел ярым элек җанисәп уздырган чагында да биредәге татарлар, Бөтенрәсәй күләмендә бердәнбер төбәк булып, үз сафларын 8,3 процентка арттыруга ирешкән. Магнитогорскида бүген рәсми рәвештә 28 меңгә якын татар яши, ә чын саны 45 мең чамасы тәшкил итә. Янә бердәнбер кала булып, алар 12 томлы репрессия корбаннарының «Хәтер китабы»н да нәшер иткән, «Халыклар дуслыгы» йортының да эшчәнлеген бүген татар вәкилләре тартып бара. «Татар рухы» атлы шәхси үзәкләре, телевидение пункты, үз газеталары бар. Хәзер инде яңа җәмигъ мәчете төзү нияте белән яналар, җир алып куелган, матди мая туплау ягын гына кайгыртасы калган. Шәһәр уртасында үзәк татар мәчете булган-булуын да, ләкин милләтне гасырлар буе эзәрлекләгән һәм коллыкка төшергән таркаулык вә хөсетлек чире кара сакал кебек арттан калмый бит ул. Татарның бер томана, сөрген газапларын кичермәгән сәүдәгәре куштан татар, башкорт, үзбәк-таҗиклардан хасил мөселман җәмгыяте төзеп куйган да, үзәк мәчетне үз тырнагына эләктергән. Аннары ул шушы ук мәчеткә таҗик, үзбәк муллаларын керткән. Әлеге хилаф гамәлләрнең һәммәсен дә Уфа мөфтияте башлыгы Тәлгат Таҗетдин раслаган. Хәзер инде җәйләрен мәчет ихатасында базар ачып та акча сугалар. Мөфтият белән хакимият күз «йома», ә «Татар рухы» төзегән янә бер җәмгыять яңа мәчет булдыру өчен җан-фәрман көрәшә...

Шәһәр китапханәләрен дә айкап чыктык. Милли бүлекләрнең күпчелек киштәләрен Уфадан агылган 7 томлы «Башкорт энциклопедиясе», 16 томлы «Башкорт авыллары тарихы» һәм аңа өстәп Ә.Әсфәндияров тарафыннан чыгарылган өч томлы «История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий», 5 томлы «Башкорт халкы тарихы», 8 томлы «Башкорт теленең академик сүзлеге», 16 томлы «Башкорт халык иҗаты», дүртәр томлы «Башкорт халык сәнгате», «Башкорт халкының музыка сәнгате», өстәвенә әле «Башкорт хәрби энциклопедиясе», бихисап әдәби китаплар биләп алган. Магнитогорскидан Учалыга 40-50 чакрым гына ара, иртәгә ошбу төбәккә дә алар килеп мөһер салмагае. Магнитогорск татарлары алдында без бурычлы, ерак бабайлар калдырган гөнаһны да юа белү лазем.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

ДАМАНСКИЙ

Кытай белән СССРның Даманский утравы өчен сугышына 54 ел. Корбаннар күп булмаса да, ике социалистик илнең хәрби конфликты һәм атом-төш сугышын китереп чыгара язган бәрелеш буларак, тарих битләренә кереп кала ул. Татар дөньясын да читләтеп узмаган: Рамай Юлдашев шушы бәрелештә һәлак булган 19 яшьлек абыйсы хөрмәтенә Рамай исемен йөртә…



Мы горды... не щадя себя, ... тонки, выражаем ... героям той страшной войны. ... 101 наших земляка ... Доля наш назвать всех поименно. ... помнить о них, об их славном боевом пути, ... ценой своей жизни отстояв независимость нашей земли. Помнить не только погибших, но и с любовью и заботой относиться к тем немногим оставшимся в живых героям войны. Они это заслужили! Вечная слава и честь им на века! Вот имена павших. Для нас они священны!

• Абдуллин Галимулла Миннулович, родился в 1925 г. в с. Имай-Карамалы, рядовой, пропал без вести в мае 1945 г. (извещение Упр. по персональному учету погибших).

• Абдуллин Миннула Абдуллович, родился в 1925 г. в с. Имай-Карамалы, рядовой, пропал без вести в марте 1943 г. (извещение Упр. по персональному учету погибших).

• Абдуллин Хаматнур Мавлиярович, родился в с. Имай-Карамалы, рядовой, пропал без вести в 1943–45 гг. (по сообщению родственников).

• Арсланов Шавгарей Арсланович, родился в 1898 г. в д. Батраки, рядовой, погиб 19 августа 1942 г. в д. Овсяники Кармановского района Смоленской обл. (извещение № 938 ПП).

• Ахмадеев Рамай Ардуванович, родился в 1950 г. в с. Имай-Карамалы, погиб в марте 1969 г., о. Даманский (извещение Давлекановского РВК).

• Ахметзянов Минигали Ахметзарифович, родился в с. Имай-Карамалы, год гибели не установлен (1941–45гг.) (по сообщению родственников).

• Ахметзянов Миннсафа Ахметгарифович, родился в 1923 г. в с. Имай-Карамалы, рядовой, пропал без вести в декабре 1942 г. (извещение Упр. по персональному учету погибших от 28.08.1950 г.).

• Ахметзянов Хузиахмет Ахметзянович, родился в 1911 г. в с. Имай-Карамалы, погиб в 1941 г., места гибели в ...

Утрау инженер Станислав Даманский хөрмәтенә аталган. 1860 елда, Россия һәм Цин империяләре арасындагы килешү нигезендә, чик «Амур елгасының уң як ярыннан» дип билгеләнә. Моны кытайлар үзләре өчен кимсетү дип санный, чөнки крестьяннар Амур елгасы суыннан мәхрүм кала. Фактта кытайлар елга суын куллана, балык та тоталар – чик сакчылары судан файдаланган өчен дәгъва белдерми.

1919 елгы Париж конференциясе нигезендә, «илләр арасында елга булган очракта, чик фарватер (елганың кораблар йөзә алырлык тирән урыны) уртасыннан булырга тиеш» дигән канун чыга. Уссури елгасы фарватерыннан караганда, озынлыгы 1,7 км, киңлеге 700 метр булган Даманский утравы – кытай ягында. Кытайда коммунистлар партиясе лидеры Мао Цзедун «мәдәни революция» дип аталган идеологик кампания башлагач, СССРны «социалистик империализм»да гаепли, һәм ике ил арасында мөнәсәбәтләр киеренкеләнә. Шул сәбәпле, чик буендагы конфликтлар да барлыкка килә. КПССның Үзәк комитеты эгъзасы Рой Медведев әйтүенчә, Брежневның да «чик – фарватер уртасыннан билгеләнә» дигән кагыйдәне үтисе килми, Кытай ягы да, берниндн әһәмияте булмаган, язларын су баскан утрауны үзенә алырга тели.

Тарихчылар канлы бәрелешне Кытайның эчке сәясәте белән дә бәйләп карый – аларга, халыкны берләштерү өчен, тышкы дошман кирәк булган.

Бәрелешләргә кадәр кытайлар төрле провокацияләр үткәрә. 1969 елның 1 мартыннан 2 мартына каршы төндә карабиннар һәм автоматлар белән коралланган якынча 300 кытай хәрбие утрауга керә. Вакыйгалар урынына 32 совет чик сакчысы җибәрелә. Чик сакчыларының бер төркеме Кытай хәрбиләре янына юнәлә, СССР территориясеннән китүләрен таләп итә. Уртак фикергә килеп, ике як та үз ягына борылып китә дигәндә, кытайлар ут ача. 8 хәрби һәлак була. Аларның гәүдәләрен Кытай хәрбиләре төрлечә мәсхәрәли. Рядовой Геннадий Серебров һәм ефрейтор Павел Акулов исән кала. Акулов соңыннан аңсыз хәлдә әсирлеккә алына. Аның гәүдәсе, күпсанлы җәза эзләре белән, 1969 елның 17 апрелендә совет ягына тапшырыла.

Утрауда атышу турында хәбәр алгач, күрше застава башлыгы Виталий Бубенин һәм 23 хәрби ярдәмгә китә. Кораллы бәрелеш 30 минут чамасы дәвам итә. 13.00дә кытайлар чигенә башлый.

2 мартта сугышта 31 совет чик сакчысы һәлак була, 14 е яралана. Генерал-полковник Н.Захаров рәислегендә СССР КГБ комиссиясе бәяләвенчә, Кытай ягыннан 39 кеше үтерелгән.

Даманский утравына совет гаскәрләре китерелә. Кытай ягыннан 5 мең кешелек полк сугыш хәрәкәтләренә әзерләнә. 14 март көнне Кытай хәрбиләре кабат утрауга керә. 15 е иртән Кытай артиллериясе ут ача, һөҗүмгә күчә.

Кытай хәрбиләре совет гаскәрләреннән күбрәк була, көчләр тигез түгеллеге ачыклана. КПСС Үзәк комитеты политбюросы күрсәтмәсен бозып, ул вакытта яшерен булган БМ-21 «Град» реактив залп снарядыннан ут ачыла. Снарядлар Кытай хәрбиләренең күпчелек материаль-техник ресурсларын юкка чыгара. Совет гаскәрләре кабат һөҗүмгә бара. Нәтиҗәдә, кытайлар позицияләреннән китә һәм дәүләт чигенең бу участогына бүтән һөҗүмнәр ясамый.

1969 елның 11 сентябрендә СССР һәм КНР дошманлыкны һәм үзләре биләгән чикләрдә бәрелешләрне туктатырга килешә.

Бәрелешләр вакытында совет гаскәрләренең 58 хәрбие, шул исәптән 4 офицер һәлак була, 94 кеше, шул исәптән 9 офицер яралана. Кытай ягының югалтулар әлегә кадәр ябык, алар төрле исәпләүләр буенча 100-300 кешене тәшкил итә. Кайбер мәгълүматлар буенча аларның саны 900 гә якын.

СССР бу бәрелештә җиңеп чыга. Союз таркалганнан соң, 1997 елда, чикнең Көнчыгыш участогы кабат ачыклана һәм Даманский утравы Кытайга күчә. Аны «Чжэньбао» дип атыйлар, тәрҗемәдә ул «кыйммәтле» дигәнне аңлата.

Даманский утравындагы канлы бәрелештә 19 яшьлек татар егете Рамай Әхмәдиев та һәлак була. Бу хакта аның туганнан туган энесе – Татар милли хәрәкәте активисты, Марий Эл республикасының Татар мәдәнияте үзәге хезмәткәре Рамай Юлдашев хәбәр итте. Аңа исемне дә сугышта һәлак булган абыйсы истәлегенә кушканнар. Рамай Әхмәдиевнең әнисе Рабига – Рамай Юлдашевның әнисе Гадиләнең апасы.

«Аның шулай яшьли һәлак булуы – 53 ел узса да, безнең нәсел өчен зур фаҗига. Ул безнең хәтердә, безнең күңелләрдә. Туганнар әле дә аны искә ала», – ди Р.Юлдашев.

Рамай Ардуан улы Әхмәдиев Башкортстанның Дәүләкән районы Имай-Карамалы авылында туа. Аның әтисе Ардуан Гыйльман улы Бөек Ватан сугышында катнашкан, хатыны Рабига белән 7 бала үстергәннәр. Рамай башкорт авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетының читтән торып уку бүлегенә укырга керә һәм шул ук вакытта «Родина» колхозында терлекче булып эшли башлый. Туганнары һәм авылдашлары истәлекләре буенча, ул хәрби хезмәткә 1968 елның көзендә Дәүләкән хәрби комиссариаты тарафыннан чакырыла. 1969 елның 1-2 мартында Даманский утравындагы бәрелеш вакытында һәлак була.

Даманский утравында һәлак булган күп кенә чик сакчыларын туганнар каберлегендә җирләгәннәр. «Абыем Рамайның әтисе Ардуан абый, меңнәрчә чакрымнар үтеп, Дальнереченскига бара һәм күп мәетләр арасыннан улын миңеннән таный. Кытайлар аны үтергәч, күзләрен чокыган, баш сөяген ваткан, колакларын кисеп алган була», – дип сөйли Р.Юлдашев. Аның фикеренчә, Әхмәдиев диверсантлар һөҗүме вакытында һәлак булган.

Ардуан абый улының мәетен цинк табутта Имай-Карамалы авылына алып кайта. Даманский утравында һәлак булганнарны туганнар каберлегендә җирләгән булалар. Әмма Ардуан абый аны туган җиренә кайтарып җирләргә карар кыла. Ул 10 көн буе поездда бара, нindидер ысуллар белән мәетне алырга рөхсәт юнәтә, 10 көн буе мәетне туган ягына алып кайта.

Җеназада цинк табутны ачалар. Хушлашу мәрасиме 2 көн була. Матәм митингына кешеләр күп җыела. Хәрбиләр аны мылтыктан атып озата. 1969 елның 28 мартында солдатны зиратка түгел, мәктәп янында җирлиләр. Ардуан Әхмәдиев улын югалтуны авыр кичерә, 3 елдан соң вафат була. «Бер елдан соң мин туганмын, миңа Рамай абый хөрмәтенә исем кушканнар», – ди Р.Юлдашев.

Рамай Әхмәдиевнең 6 туганы була. Хәзер Рамай Әхмәдиевнең абыйлары, сеңелләре калмаган, аларның балалары гына исән. Каберне Имай-Карамалы мәктәбе укучылары карап, чистартып тора.

Авылдашы һәм балачак дусты Илдус Солтанаев Рамайны болай дип искә алган: «Без Рамай белән бер урамда яшәдек, яшьтәшләребез белән «сугышлы» да уйнадык, Карамалка елгасында буалар төзедек, коендык. Ул вакыттагы барлык яшьләр кебек, Рамай һөнәр алырга, үз җирендә эшләргә, икмәк үстерергә хыялланды. Ләкин бу хыяллар тормышка ашырга насыйп булмагандыр, Кытай пулясы 19 яшендә аның гомерен өзде».

Даманский утравындагы бәрелештә катнашкан һәм һәлак булган Совет Армиясенең күп кенә чик сакчылары һәм хәрби хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре бирелә. Батырлыклары өчен 5 хәрби Советлар Союзы Герое исеме ала, шуларның 3 се – һәлак булганнан соң. 3 хәрби – Ленин ордены, 10 сы – Кызыл Байрак ордены, 31 е – Кызыл Йолдыз ордены, 10 сы – III дәрәҗә Дан ордены, 63 е – «Батырлык өчен» медале, 31 е – «Сугышчан казанышлары өчен» медале белән бүләкләнә.

Даманский утравындагы канлы бәрелештә Татарстан егетләре дә һәлак була. Әгерҗе районы Татар Шаршадысы

ФАҖИГАСЕ

авылында туган Әнвәр Әхкыям улы Зәйнетдинов хәрби хезмәткә Әгерҗе хәрби комиссариаты тарафыннан чакырылган. Тын океан чик округының 69 нчы чик буе отрядының маневр төркеме өлкән сержанты, техник. 1969 елның 15 мартындагы бәрелештә һәлак була, 1969 елның 21 мартында Приморье краеның Ханкай районы Таш-Рыболов авылы үзәк мәйданындагы туганнар каберлегендә җирләнә. Һәлак булганнан соң «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән.

Исламгали Солтангали улы Насретдинов Башкортстан АССРның Нуриман районы Үкәрле авылында туган. Татар. Хезмәткә Чиләбе өлкәсенең Златоуст комиссариатыннан чакырылган. Рядовой, радиотелеграфист, Тын океан чик буе округының 57 нче чик буе отрядының 1 нче чик сакчысы. 1969 елның 2 мартындагы бәрелештә һәлак була, 1969 елның 6 мартында Приморье краеның Пожарский районындагы «Сопки Кулебякины» 1 нче чик сакчылары заставасы территориясендә туганнар каберлегендә җирләнә. 1980 елның 30 маенда Приморье краеның Дальнереченск шәһәр

зиратының хәрби участогында, «Һәлак булган геройларга дан» мемориалына күчереп җирләнә. «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән (үлгәннән соң).

Рамай Әхмәдиев турында исә берничнди рәсми фактлар да юк. Дәүләкән комиссариатында Рамайның хезмәткә алынуы турында да, һәлак булуы турында да бер мәгълүмат юк икән. Рамай Әхмәдиевнең туганнан туганнары Сәлимә апа Габдрафикова һәм Р.Юлдашев бу хакта ныклап белешергә уйлаган.

– Мин бу вакыйгаларда катнашучылар, үлүчеләр, яраланучылар һәм бүләкләнүчеләр исемлеген карадым. Сайтларга, җәмгыятьләргә, бу вакыйга тарихын өйрәнгән кешеләргә чыктым. Рамай Әхмәдиев ул исемлекләрнең берсендә дә юк. Дәүләкән хәрби комиссары белән сөйләштем. «Без хәрби часть номерын белмибез. Барлык документлар да «яшерен». Ул чик сакчысы булмаган, автобата хезмәт иткән», – диделәр. Интернетта бит хәрби часть номерлары да, үлгән, бүләкләнгәннәрнең исемнәре дә – бөтен әйбер бар, ә военкоматның бер мәгълүматы юк, – дип сөйләде Р.Юлдашев.

Аннары, кабер ташында үлгән көн дип, 1 март күрсәтелгән. Иң кискен бәрелешләр исә 2 март иртәсендә була.

– 50 ел узганнан соң да дәүләт һәм республика органнары солдатны «танымый», «белми». Рамай Әхмәдиевнең кабере бар, «Ленинец» республика газетасында 1969 елның 28-29 мартындагы аның турында басмалар бар, фотосурәтләр бар, Рамай Әхмәдиевнең җеназасында булган шаһитлар, якын туганнары һәм дуслары күп. Тик военкоматта исеме дә, фамилиясе дә, солдатка чакырылуы да юк. Кем соң ул алайса? Геройммы? Дезертирмы? Әллә инде гаепсезгә зыян күргән кешеме? – ди Р.Юлдашев.

«Минем максатым – Рамай Әхмәдиевнең Даманскийда һәлак булганын рәсми раслату. Бу – аңа нииндидер медаль, орден алу өчен дә түгел. Тарихи дөреслекне ачыклыйсы иде. Мин Оборона министрлыгына мөрәҗәгать итәчәкмен», – ди Р.Юлдашев.

Рамай Әхмәдиев – очсыз-кырыйсыз тарихта «югалган» солдат. Кабере булса да, тарихта эзе юк.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.

intertat.tatar

Тынгысыз Локман

Республика матбугаты белән танышып баручыларга Локман Закиров исеме яхшы билгеле. Аның төрле язмалары Татарстанда газета-журналларында даими басылып килә.

Бу көннәрдә Локман Закирның вакыты бигрәк тыгыз. Ул 95 яше тулу уңаеннан бәйрәм чараларын үткәреп йөрде.

Л.Закир 1928 елның 19 февралендә Мамадыш районының Түбән Ушмы авылында туа. Шушы авылдагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Локман Мамадыш педагогика училищесында белем ала. 1945-1948 елларда район мәктәпләрендә балалар укыта. Сүз уңаеннан шунысын да телгә алып үтәргә кирәк, Түбән Ушмы мәктәбеннән биш язучы чыккан. Закирдан тыш биредә Хуҗи Мәхмүтов, Зиннур Мансуров, Шаһинур Мостафин һәм Ринат Мөхәммәдиев белем алган.

1948 елда Локман Фатих улы хәрби хезмәткә чакырыла, авиатор булып хезмәт итә. Шушы китүдән соң Локман туган ягына тиз генә кайта алмый. Хәрби хезмәт срогы тулгач, армиядә кала. Киевтә авиация институтын (2000 елдан милли авиация университеты) тәмамлап, хәрби очучы була. Армиядә чирек гасыр хезмәт итә.

Бушрак вакытлары булуга, Л. Закиров кулына каләм ала. Истәлекләр язарга тырыша. Аның шактый мәкаләләре «Красная звезда» газетасында басылып чыга. Бу чорда ул документаль, ярымдокументаль материалларга, публицистикага өстенлек бирә. Киләчәктәге иҗаты өчен дә шактый материал туплый.

Пенсиягә чыккач, Локман иҗат эшчәнлегенә ныклап керешә. Шактый язмалары Мәскәү газета-журналларында басыла. Күп кенә мәкаләләрен «Огонек», «Москва», «Новое время», «Столица» журналлары соравы буенча әзерли. «Литературная газета», «Новая газета» да Локман язмаларын бик теләп бастыра.

«Огонек» журналында Л. Закирның «Сколько стоит загробная жизнь вождя?» дигән мәкаләсе басылгач, авторның абруе тагын да арта төшә. Билгеле булганча, сугыш чорында немецлар СССРның башкаласы Мәскәүне алу өчен күп көч куялар. Әлбәттә инде истәлекле урыннарны мөмкин кадәр җимерелүдән, юк ителүдән саклап калырга кирәк була. Совет хөкүмәтенең карары нигезендә В. И. Ленинның мавзолейдагы җәсәде Төмәнгә күчерелә. Локманның мәкаләсе шул турыда була. Мәкалә басылгач күп кенә газета-журналлар аны күчереп басалар. «Би-би-си», «Голос Америки», «Немецкая волна» һ.б. радиостанцияләр дә бу язманы халыкка җиткерә.

Күрәсең югарыдан шундый әмер булгандыр, үзгәртеп корулар башлангач, Казанда Локманның язмаларын бастыру тыела. 1995 елда «Таң – Заря» нәшриятында авторның «Мостафа» китабы чыккач, ул республика күләмендә «Ел китабы» дип танила, конкурста аңа беренче урын бирелгәч, чикләүләр бетерелә. Шушы чорда «Шәһри Казан» газетасында авторның Татарстан турында «Коммунизм утравы» дигән күләмле мәкаләсе дә дөнья күрә.

Авторның мәкаләләре дә, китап сюжетлары да танып белүгә, күпләргә мәгълүм булмаган факт-хәлләр аңлатуга корылган. Аларда фәлсәфә, психологик табышлар, уйланулар бар. Локман Закир иҗатына тәнкыйть күзлегеннән караучылар да аз түгел. Кайберәүләр автор фактлар белән чамадан тыш кыю эш итә дип саный.

Аның егермеләп китабы дөнья күрде. Аларда публицистика, документаль материаллар, хикәяләр, повестьлар... Китапларының барысын да диярлек үз акчасына чыгара. Шуңа күрә дачасын да, машинасын да сатарга туры килгән.

Локман китапларының күпчелеге русча. Күрәсең армиядә озак еллар хезмәт итү моңа йогынты ясагандыр. Авторның «Гнездо кукушки», «Вершина айсберга» китаплары Татарстан китап нәшриятында күптән түгел басылып чыкты. Андагы мәкаләләр, шәрехнамәләр кыскалыклары, җыйнаклыклары белән аерылып тора.

Локман Закир 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Ул Гаяз Исхакый премиясе лауреаты.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Тукайны олылаган әдип

Бу көннәрдә җәмәгатьчелек танылган әдип, драматург, шагыйрь, тәнкыйтьче, публицист, тәрҗемәче, либреттолар авторы, кыска гына гомерендә мул иҗат калдырган Әхмәт Фәйзинең тууына 120 ел тулуны билгеләп үтә. Шушы уңайдан әдәби музейда «Тукай хәятына чумып...» дип исемләнгән кичә узды, галимнәребез, язучыларыбыз әдипнең иҗатын, тормышын күз алдыннан үткәрде.

Әхмәт Фәйзинең иҗатына һәм тормышына багышланган кичәнең нәкъ менә Тукай әдәби музеенда үтүенең үз сере бар. Ул – Габдулла Тукайның тормышын һәм иҗатын тирәнтен өйрәнгән шәхес. Г.Тукай музее мөдире, филология фәннәре кандидаты Гүзәл Төхвәтова, кичәне башлап җибәргәндә үк, катнашучыларның игътибарын әдипнең 1930 елларда, беренчеләрдән булып, шагыйрь образын «Тукай Җаекта» һәм «Тукай» дигән пьесаларында чагылдыруына, «Тукай» кинолибреттосын язуына юнәлтте. «Әхмәт Фәйзи, гомумән, унлап әсәрен Тукайга багышлый. Бу аның Тукайга соклануын күрсәтә. Әхмәт Фәйзи Тукай образы аша аның иҗатын да буыннан-буынга тапшыра», – диде Г.Төхвәтова.

Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат искәртеп үткәнчә, Әхмәт Фәйзи – татар әдәбияты тарихында барлык жанрларны тигез дәрәҗәдә колачлап, актив иҗат иткән, һәркайсында үзен таныткан уникаль әдипләребезнең берсе. Алай гына да түгел, Г.Тукайдан 17 яшькә генә кече булган Ә.Фәйзи ул жанрларны тагын да үстергән. «Аның кебек, әдәбиятның барча жанрларына да үтеп кергән язучылар XX гасырда, бәлки, юктыр. Алар хәзер дә сирәк. Әхмәт Фәйзи поэзия, проза, драматургия, опера һәм балет сәнгатендә, тәрҗемә, әдәби тәнкыйть, балалар әдәбияты өлкәләрендә актив эшләгән», – диде Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат. Кыска гына гомерендә әдип тау кадәр хезмәт калдырган, кайсы гына жанрдагы әсәрен алсаң да, югары кимәлдә иҗат ителгән. Аның соңгы китабы – «Сайланма әсәрләр»е тууына йөз ел тулу уңаеннан нәшер ителгән булган. Аңа кадәр биш томлыгы басылган. Аннан соң инде тулы бер буын үсеп җитеште. Ә инде китабы чыкмый икән, ул нинди генә бөек язучы булса да, көннәрдән бер көнне аның исеме онытыла. «Әхмәт Фәйзи кебек олуг әдипләребез хәтерләрдән җуелырга тиеш түгел. Алар киләчәк буынны да тәрбияләргә лаек әдипләр. Китаплары да һәрдаим чыгып торсын иде» – диде Г. Морат.

Әдәбият галиме, профессор Тәлгат Галиуллин Ә.Фәйзинең татар поэзиясендә интеллектуаль башлангычны югары дәрәҗәгә күтәргән шагыйрьләребезнең берсе булуын да искәртте. Аның кайсы гына әсәрен карама, анда кешенең акыл егәрен тоемлыйсың, аларда иң әүвәл тирән фикер ярылып ята. Язучының әсәрләрен укыганда, аның сурәтләү, тел байлыгына да хәйран калырлык! «Умырзая» дигән җырын гына карагыз, анда татар халкының моңы чагылыш тапкан», – диде Т.Галиуллин.

Галим Ә.Фәйзинең «Их, шагыйрь булсаң иде!» дип, 15 яшендә иҗат иткән беренче шигырен искә төшерде. Чыннан да, максатына ирешә. «Ни сәбәпле Арчага кайтканын да аңладым: чөнки анда Кырлай, Тукай эзләре бар. Шунда яшәп, шагыйрьнең эзе калган урыннарын, аралашкан кешеләрен тикшереп, өйрәнеп кайта. Шуннан соң, аның «Тукай» романнары туа», – диде ул.

Тәлгат Галиуллин Тукайны өйрәнүдә дә Әхмәт Фәйзи белән янәшә куярлык кеше күп түгеллеген әйтте. Тукай аны миллилеге, фикере, татар халкына хас моңны әсәрләрендә чагылдыруы белән үзенә тарта. «Лаеклы шәхесләребезгә Тукай исемендәге әдәби бүләкне бирә башлауда да без Әхмәт Фәйзигә бурычлы. Ул Тукай бүләген булдырган, 1958 елда беренче Тукай бүләген ала һәм ике айдан соң вафат була. «1930 елларда язылган һәм совет чоры татар шигъриятенең үзенчәлекле казанышларыннан булган «Флейталар» поэмасы өчен генә дә Тукай бүләген алуга лаеклы шагыйрь ул», – диде Т.Галиуллин.

Әхмәт Фәйзи күп йөрергә яраткан. Хәтта Донбасска да барган, татар шахтерлары арасында гыйлем-мәгърифәт таратып йөргән. Арчада да эшләгән. 27 ел Мәскәүдә яшәп иҗат иткән. Әдәбият галиме, профессор Хатыйп Миңнегулов бу уңайдан Әхмәт Фәйзи төрле җирләрдә яшәсә дә, күңеленең һәрчак Казан белән бәйләнештә булуына, Мәскәүдә гомер иткәндә, татар мәдәни тормышының үзәгендә кайнавына, башка халыклар белән дә тыгыз мөнәсәбәттә торып яшәвенә игътибар иткән. «Башкалада һәрвакыт татар мәнфәгатьләрен яклауда әһәмиятле эшләр башкарган. Хәзер татар галимнәре, иҗат әһелләренең дуслыгы – юк дәрәҗәсендә. Бер-берсеннән көнләшеп яшиләр. Ә ул елларда Әхмәт Фәйзи, Муса Җәлил, Фатих Хөсни, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан белән аларның чын дуслык мөнәсәбәтләре булган. Бер-берсенең уңышлары өчен куанганнар», – диде галим.

Танылган әдәбият белгече, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин да Ә.Фәйзинең татар әдәбият һәм сәнгать әһелләре турында кайгыртып яшәвен белдерде. Әйтик, Салих Сәйдәшевнең җәсәден Мәскәүдән Казанга кайтартуда Әхмәт Фәйзинең роле искиткеч зур булган. «Аның кадерен, татар халкы өчен зурлыгын барыннан да элек аңлаган, күрәсең», – диде Фоат ага. Шулай ук Нәҗип Җиһановка карата салкынрак мөнәсәбәт тоюын, талантлы композиторга карата алай булырга тиеш түгеллеген дә искәрткән. Әхмәт Фәйзи: «Мине Казанда җирләгез», – дип васыять әйткән. Аның өчен Казан барыннан да якын булган. Фоат ага Галимуллин «Шүрәле» балетына музыка язган композитор Фәрит Яруллин белән бәйле вакыйганы да искә төшерде. Сәнгать эшлеклеләре композиторның әсәрен сугыш вакытында ук сәхнәгә күтәрә. Әмма Ә.Фәйзи Ф.Яруллинның гонорары, автор буларак, тиешле кешегә тапшырылмаганын сизеп ала һәм Татарстан Композиторлар берлегендә эшләгән Зәйнәп Хәйруллинага хат яза. Фәрит Яруллинның әтисе – Заһидулла аганың исән булуын, аны эзләп табарга кирәклеген әйтә. «Фәритнең үз улы булуы турындагы документларын әзерләп бирсен, башка мәшәкатьләрен үзем кайгыртам», – дип яза. Галим Әхмәт Фәйзинең бөеклеге әсәрләрендә һәм хатларында да ачыла, дигән нәтиҗәгә килгән. 1987 елда әдипнең биш томлыгы басылып чыккан. Бишенче томда Ә.Фәйзинең байтак хатлары кергән. «Аларны укыгач, әдибебезнең бөеклеге икенче яктан ачылды. Әйтик, Гомәр Бәшировка 1955 елда язган хатында: «Без Мәскәү Композиторлар союзы иҗат йортында Нәҗип Җиһанов белән Муса Җәлил турында опера язып ятабыз», – ди. Муса Җәлилнең халыкка яңа «кайта» гына башлаган вакыты. Алар инде опера иҗат итә икән. Ул Тукайны данлады, Җәлилне музыкаль яктан күтәрү өстендә эшләде», – диде Ф. Галимуллин.

Әдәбият галиме, Казан федераль университет профессоры Нурфия Йосыпова Әхмәт Фәйзинең архивы, «Тукай» романын өч кисәктән язарга ниятләгән булуы турында сөйләде, әсәрнең әллә ничә варианты саклануын әйтте. Аларның һәркайсы аерым папкаларга тупланган. Язмаларда «Тукай» романының планын да күрергә мөмкин икән. 1886-1896 еллардагы вакыйгаларны – «Үги еллар», 1896-1907 елларны – «Тынгысыз Җаек», 1907-1913 елларны «Казан өстендә яшен» дип исемләгән булган. «Әхмәт Фәйзи, романны яза башлагач, әсәрнең ике кисәктән торуы турындагы фикергә килә һәм ул шулай басылып чыга», – диде Н.Йосыпова.

Архивындагы бер язмасында Әхмәт Фәйзи бик җаваплы хезмәткә алынуы – Тукайга күләмле әсәр багышларга җыенуы турында хәбәр итә, хезмәтнең Тукайның тормыш юлын күрсәтү генә түгеллеген, шагыйрь яшәгән вакытны, чордашларын, якташларын өйрәнү дә булуын әйтә.

«Тукай» романы үз вакытында югарылыкка күтәрелә, чөнки ул шагыйрьгә багышланган һәм татар әдәбиятында тарихи-биографик жанрга нигез салган күләмле әсәр. Әдип «Тукай» романын 1947 елда яза башлый һәм беренче китабын 1950 елда тәмамлый. Шул ук елны роман «Совет әдәбияты» журналында, ә 1952 елны Татарстан китап нәшриятында аерым басма булып чыга. 1956 елда әсәрнең автор тарафыннан тулыландырылган икенче басмасы дөнья күрә. Тиз арада әсәр, тәрҗемә ителеп, берничә тапкыр рус телендә, аннары казах, үзбәк һәм болгар телләрендә басыла.

Ә Фәйзи 1956 елгы хатында романның икенче кисәгенә материаллар эзләве турында да язган. Ә инде 1957 елгы истәлегендә, романны Тукай үлеме белән тәмамламаска ниятләве, Октябрь революциясенә кадәр дәвам итәргә уйлавы һәм шагыйрьнең эшен Галимҗан Ибраһимовларның дәвам итүен күрсәтергә теләвен белдергән.

Гомере буе сәламәтлеккә туймаган Әхмәт Фәйзинең 1958 елда 52 яшендә гомере өзелә. «Ә.Фәйзи вафат булгач, Сибгат ага Хәким: «Шагыйребез бакыйлыкка күчте, аның артыннан җыр туды. Халык 1933 елда язылган «Умырзая» әсәрен җырга салды. Бик тә хикмәтле хәл булды: шагыйрьнең бәхете, иҗатының зурлыгы, халыкка кирәклеге шунда күренде», – дип әйткән иде», – диде Ф.Галимуллин.

Кичәдә Ильяс Әүхәдиев исемендәге музыка училищесы студенты Азалия Хафизова, концертмейстер Алсу Сөнгатуллина, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әлфия Хәбибуллина, Татарстанның атказанган артисты Айдар Габдинов, Татарстанның атказанган артисты, Камал театры актеры Илнур Закиров әдипнең әсәрләрен яңгыратты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Савап өчен

С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрында гадәти булмаган премьера – өченче дәрәҗәдә чикләнгән инвалид балалар өчен өй шартларында күрсәтелә торган Р.Киплинг әсәре буенча «Шаян фил малае» («Любопытный слоненок») әкияте чыкты. Режиссеры – Дамир Сәмерханов. Спектакль «Чикләрсез театр» проекты кысаларында, «Лотос» АКБО белән берлектә һәм «Президент грантлары фонды» матди ярдәме белән тормышка ашырылды.

Дамир Сәмерханов – Ф.Бикчәнтәевның укучысы, Минзәлә театрында 2009 елдан эшли. Т.Миңнуллинның «Мулла» әсәре белән иҗат юлын биредә башлап җибәрде, 10 ел дәвамында баш режиссер вазыйфасында булды. Аның кулының үзенчәлеге турында фикер йөрткәндә иң беренче чиратта чыгарган спектакльләрендәге әчке җылылык, самимилек, хәтта,балаларча беркатлылык тамашачыны җәлеп итә, диясе килә... Һәм инвалид балалар өчен өйгә барып уйный торган әсәр – шактый драмалар, комедияләр, әкиятләр чыгарган режиссерның яңалыкка омтылуымы, әллә башка сәбәпләре бармы? «Хәтерлисеңме, бермәлне танышым (фамилиясе ябык информация) инвалид баласын әкиятләргә йөртми башлады? Очрагач, нишләп килмисез, дип сорадым. Күтәрерлек, коляскага утыртырлык түгел, бик авыр, дип җавап бирде ана. Без бит игътибар итмибез, бөтенләй бу хакта уйланмыйбыз, чөнки, Аллага шөкер, балаларыбыз сау – сәламәт. Шактый вакыт тынгылык тапмадым, менә шуннан идея туды. Грантка өч тапкыр язып карадым, дүртенче талпынудан 500 мең грант оттык», – дип сөйли Дамир Мөдәрис улы. Театр директоры Илнур Гайниев режиссерның гамәлен баштан ук хуплады, грант язу буенча махсус укуларга җибәрде. «Әлеге спектакль – социаль проект, савап булсын, дип эшлибез. Белүемчә, Татарстанда бу – яңа формат, мондый проект беренче тапкыр тормышка ашырыла. Әлеге әкиятне Минзәлә, Актаныш, Сарман, Мөслим, Тукай районнарында яшәүче 48 инвалид баланың һәрберсенең өйләренә барып, күрсәтәчәкбез», – диде Илнур Зөфәр улы.

«Шаян фил малае» тамашасының рәссамы – «Әкият» татар дәүләт курчак театрының баш рәссамы – Сергей Рябинин Минзәлә театрында беренче тапкыр 2020 елда Н.Анкиловның «Солдат хатыны»н шулай ук Д.Сәмерханов белән чыгарган иде. Ике актер – Рөстәм һәм Диләрә Зиннуровлар уйный. Рөстәмнең балалар белән эшләү тәҗрибәсе зур, дип әйтү генә коры сүз булып ишетелә. Үзенә тарту көче, магиясе, харизмасы бар аның. Режиссер нәкъ менә Зиннуровларга таянды да инде. Әкиятне карарга беренчеләрдән булып Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Минзәлә районында халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры урынбасары Т.В.Паранина һәм белгечләр, Минзәлә педагогика көллиятенең психологы Г.Ә.Нуретдиновалар килде. Әсәрне сәхнәләштерү процессы тулысынча алар белән киңәшләшеп эшләнде .

Ике чемодан – ул чемоданнардан ни генә чыкмады – фил малае, зур маймыл, жираф,страус, пальма агачлары, зонт, ике яклы җәймә, банан, ананас, мандариннар. «Һәр гаиләгә индивидуаль әзерлек белән барачакбыз, – диде Татьяна Владимировна Паранина. – Чөнки, беренчедән, өйдә театр мөмкинлекләре, уйнар өчен мондый иркенлек булмаска мөмкин. Бик кечкенә балалар бар, бар үсмер балалар. Ләкин ул үсмер баланың да акыл дәрәҗәсе кечкенә баладагы кебек. Шуңа күрә берьяклы гына фикер йөртеп, менә шулай булачак, болай булачак, дип беребез дә гарантия бирә алмый. Гаилә белән башта белгечләр эшли, алар аңлата, әзерли һәм сезгә җиткерә, мәсәлән, бу балага кычкырыбрак сөйлисе, монысы белән тынычрак булырга. Чөнки эмоцияләрдән баланың башы авырта башларга мөмкин. Аутист бала утырып тормаячак, сезнең белән сикерәчәк, хәрәкәтләнәчәк, уйнап торган җирдән көйсезләнә башлаячак – нюанслар күп. Сез изге һәм бик катлаулы эшкә алындыгыз. Рәхмәт сезгә!».

«Шаян фил малае»ның беренче тамашачысы Минзәлә районы Усай авылында яшәүче 12 яшьлек Владислав Прозоров булды. «Белгечләр күзәтүе астында әкият яхшы гына барды. Бала артистларны шундук кабул итте. Иң каушап төшкән кеше үзем булганмындыр, – диде Д.Сәмерханов.– Владислав елмаеп, бик игътибар белән карады. Әкият азагына исә гел йомылып бетте, эмоцияләрне кая куярга белмәгәннән, дип аңладык. Баланың әбисе тәмам ачылып сөйләште».

Мөслим районында артистларыбыз бер көндә дүрт гаиләдә булды. 8 яшьлек Ш.Абдуллин, 17 яшьлек К.Каюмова, 12 яшьлек И.Садыйков, 4 яшьлек С.Харитонова – төрле дәрәҗәдә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар. «Диван белән телевизор арасындагы метр ярым урында шундый спектакль күрсәтеп булуына ышанып бетмәгән идек», – диде ата-аналар. Гаиләләр шулкадәр җылы кабул итте. Хәтта могҗизалар да булды – өзек-өзек сүзләр генә әйткән Сөмбел тулы җөмлә белән: «Тагын килегез», – диде. Ислам исә, җибәрәсе килмичә, баш киемен салдыра башлады. Мондый вакытта күз яшьләрен тыеп булмый. Әлбәттә, һәр спектакль беренче тапкыр уйнаган кебек булачак. Уйнау дигән сүз бәлки бераз урынлы да түгелдер. Бала күңеленә юл табу, яхшы мөнәсәбәтләр кору, минутында ситуациягә яраклашу диярсәңме? Минзәлә театрының бу изге башлангычы дәвамлы булсын, инвалид бала үстергән гаиләгә бер җылы очкын барып җитсен иде.

Нурсибә АДИЕВА,
театрның әдәби бүлеге мөдире.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

25 март (шимбә). ***Рамазан аеның 3нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 7.32 сәгатьтә калка, 0.19 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.31 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланууын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Кан басымын төшерү (1)

Гипертония интектергәндә, көненә 3 тапкыр яртышар стакан сары мәтрүшкә төнәтмәсе эчү файдалы. Яисә 1 лимон яки әфлисунны кабыгы белән бергә блендерда изеләрләр дә, шикәр йә бал кушалар, шуны 2-3 атна дәвамында көненә 3 тапкыр 1 әр чәй кашыгы кабалар. Кан басымын нормада тоту өчен, көненә 3 тапкыр яртышар стакан чәй гөмбәсе суын эчү нәтиҗәле. Яки баланны изеп, бал белән ашыйлар.

26 март (якшәмбе). ***Рамазан аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 7.48 сәгатьтә калка, 1.43 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.36 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Кан басымын төшерү (2)

Тигез микъдарда сукыр кычыткан, саз кипкәре, дүләнә чәчәге, шуларның яртыөлеше кадәр чыпчык җилемен (омела) кушып, 1 стакан катнашма өстенә 1литр кайнар су кояр да, төреп, 4 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, 3-4 атна дәвамында көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр аш кашыгы эчәләр. Яисә 2 аш кашыгы кипкән кара карлыганны 1 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 10 минут пешерәләр, 1 сәгать төнәткәч, сөзәләр дә, көненә 4 тапкыр чирек стакан эчәләр.

27 март (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 8.10 сәгатьтә калка, 2.58 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.40 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Әрекмән, шалфей, лимон...

Баш кавыкланса, шулар ярдәмгә килә. 3әр аш кашыгы вакланган әрекмән һәм кылыч үлән (аир) тамырларын 1 литр суда кайнатып чыгаралар да, сүрән утта 10 минут пешерәләр, суытып, сөзәләр. Атнасына 3 тапкыр җылы килеш баш тиресенә сөртәләр, чәчне юганнан соң, шуның белән чайкыйлар. Яисә 1 әр аш кашыгы дару ромашкасы чәчәге һәм

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

шалфей яфрагын 1 стакан кайнар суда 20 минут төнәтәләр, сөзәләр, шуңа 1 лимон согын сыгып, баш тиресенә сөртәләр.

28 март (сишәмбе). ***Рамазан аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 8.42 сәгатьтә калка. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 12.45 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

29 март (чәршәмбе). ***Рамазан аеның 7 нче көне.9 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 9.30 сәгатьтә калка, 3.59 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

Балан шифасы

Йөрәк авыртканда, балан төнәтмәсе эчү файдалы. 2 аш кашыгы җиләкне изеп, 1 стакан кайнар суга салалар да, яхшылап төреп, 1 сәгать төнәтәләр, 3-4 атна дәвамында, ашарга 30 минут кала, көненә 3-4 стакан эчәләр.

30 март (пәнҗешәмбе). ***Рамазан аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 10.33 сәгатьтә калка,4.41 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.54 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Сихәтле май

Җәрәхәтләрне төзәтә торган май болай әзерләнә: 1 әр аш кашыгы бал һәм балавызны суда эретеп, шуңа 10 г стрептоцид порошогы кушалар, суынганчы болгатып торалар. Суыткычта саклыйлар.

31 март (җомга). ***Рамазан аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 11.47 сәгатьтә калка, 4.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 12.59 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныр мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Юка вафля

6 йомырка, 240 ар г атланмай, шикәр һәм он, 8 г ванильле шикәрдән камыр туглап, вафля пешергечтә пешерәләр, кайнар килеш шундук төреп куя баралар, эченә төелгән чикләвек кушылган куертылган сөт яки шоколадлы паста салалар. Бу кадәр камырдан 20 вафля чыга. Кетердәп торган юка вафляны, төрмичә, шул килеш кенә ашарга да була.

Сорау вә җавап

Күптән түгел Казанның Мәрҗәни мәчетендә имам-хатыйб, Казан шәһәренең Аксакаллар шурасы рәисе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов җитәкчелегендә дин әһелләре, абыстайлар, остазбикәләр, мәчеткә белем өстәргә йөрүче ханымнар катнашында, мәрхүмнәргә Коръән укып дога кылу мәҗлесе узды. Мәчеткә гыйлем өстәргә йөрүче ханымнарның Мансур хәзрәткә сораулары да күп җыелган иде.

– Соңгы вакытта мәетнең өчесе, җидесе, кырыгы, елы кебек мәҗлесләр оештырып, мәрхүмнәр рухына Коръән сүрәләре укуны гаеп итү башланды. Янәсе, мондый мәҗлесләрне үткәрергә ярамый. Шул хакта фикерегезне әйтсәгез иде.

– Әйе, дөрестән дә, интернет сәхифәләрдәме һәм башка урыннардамы динебезгә каршы көрәш алып баручы кешеләр барлыкка килде. Мәрхүмнең җирләнүенә өч, җиде, кырык көн булгач, елы тулган көннәрне, аның туганнары, якыннары җыелып, хәзрәт чакырып, Коръән сүрәләре укып үткәрә икән, аңардан дингәме, шәригатькәме, җәмгыятькәме нинди зарар бар? Җыелышып Коръән укыйбыз. Өчесенә, җидесенә, кырыгына күбрәк әбиләр җыелыша, вәгазь, Коръән сүрәләрен тыңлый, ике дөнья турында да уйлана. Шул ук вакытта туган-тумача да үзара аралаша, бер-берсенә киңәшләрен бирә. Әйткәнемчә, мин монда бер начарлык та күрмим.

– Еш кына, хатын-кызларга мәчеткә керергә ярамый, дигән сүзләр ишетергә туры килә. Бу фикер ни дәрәҗәдә хаклыкка туры килә?

– Дин буенча хатын-кызга олуг дәрәҗә бирелә, хәтта җәннәт – аналар аяк астында, дип аңлатыла. Әмма Коръәндә хатын-кызга мәчеткә керү тыела, дип язылган урын юк. Әйе, шарты туры килеп бетмәгәндә ярамаска мөмкин, тыелган вакыты да бар. Әйтик, мәчеттә бер зал гына икән, җомга намазы вакытында бер залга ирләр һәм хатын-кызлар бергә кереп туларга ярамый. Әйе, хатын-кызларның мәчеткә керергә ярамаган көннәре дә була. Мәет белән барганда да, хатын-кызларның зиратка керүе бик хупланмый. Белгәнебезчә, хатын-кызларның күңеле нечкә. Мәетне кабергә төшергәндә, алар кычкырып елый башларга мөмкин. Ә бу тыела.

– Мин Коръән ашында булдым. Үз мәхәлләсендә йөри торган бер мулла абзыйны Коръән укырга чакырдылар. Ул телефонын чыгарды да шуннан «Тәбарәк», «Йәсин» сүрәләрен транскрипция белән укыды. Бу дөресме? Югыйсә мәҗлестә гарәп имлясын белүчеләр дә бар иде.

– Бу очракта гарәп язуын белүче кеше укырга тиеш иде. Чөнки тәҗвидне өйрәнгәндә, игътибар итәсездер, гарәп язуындагы кайбер авазлар транскрипциядәгедән күпкә аерыла. Бериш хәрефләр башка мәгънәне дә бирә. Тәҗвидне белмичә укыганда, хаталар китә. Ә инде мәҗлестә тәҗвидне белә торган башка кеше булмаганда, транскрипциядән укысалар да ярый. Әмма тәҗвидне белә торган кеше бар икән, Коръәнне ул укырга тиеш.

– Намаз вакытында «Әттәхият»не укыганда «әшхәдү» дигәч, имән бармакны югары күтәрү гадәте кереп китте. Бу гамәл фарызмы, сөннәтме?

– Бохарада укыганда, бу хәрәкәтне безгә дә өйрәттеләр, бармакны шунда ук кире төшерәсең. Гарәпләр бармакны күтәреп, боргалап тора. Моны шайтан куу дип аңлатучылар да бар. Төрекләр исә намазда артык хәрәкәт ясауны хупламый, алар, гомумән, бармакны күтәрми. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә «әшһәдү» дигәндә, бармагын күтәреп куя торган булган, дип әйтәләр. Шуннан аңлашылганча, бу – сөннәт гамәл.

– Мәҗлестә Коръән укый белүче ир-атлар булмаса, хатын-кыз абыстайлар укыса ярыймы?

– Чит ир-атлар янында ярамый. Алар бу вакытта чыгып торсыннар. Ирең, әтиең, балаларың янында ярый.

Сөембикә КАШАПОВА
әзерләде.

Инфак

Коръәни-Кәримдә 200 дән артык урында искә алынган инфак – малны һәм җанны Аллаһка багышлау дигән сүз. Ягъни Раббыбыз насыйп иткән нигъмәтләрне янә Аңа багышлап сарыф итүне белдерә. Шуңа күрә мөселман да мал-мөлкәтен дә, җанын да Аллаһка багышлаган зат була.

Иманның тәүге җимеше – мәрхәмәт. Аннан ерак күңел җан иясе, тере зат санала алмас. Һәр хәерле эшнең башы булган «бисмилла» һәм «Фатиха» Аллаһның мәрхәмәтен белдергән «Рахман» һәм «Рәхим» исемнәре белән башлана. Пәйгамбәрләр һәм вәлиләрнең тормышлары да шәфкать һәм мәрхәмәтнең иң югары үрнәкләреннән гыйбарәт гайре табигый күренешләр белән тулы.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мәрхәмәт кылучыларга Җәнабел-Хак мәрхәмәт күрсәтер. Сез җирдәгеләргә мәрхәмәт кылыгыз, күктәгеләр дә сезгә мәрхәмәтле булсын…» – дип (Тирмизи, «Бирр», Әбу Давыт, «Әдәб»), мөэминнәрне бөтен мәхлукларне колачлаган мәрхәмәткә өнди.

Мәрхәмәтлелек Аллаһ колының бер вазыйфасын тәшкил иткән инфак кылуда иң камил чагылыш таба. Туганлык хисләре зәгыйфьләнгән, иҗтимагый тынычлык һәм иминлек югалган, ачу-нәфрәт һәм дошманлык арткан җәмгыятебездә инфак юлында гомуми мобилизациягә ихтыяҗ бар. Шуны онытмаска кирәк: авырту-сызланулы һәм мохтаҗ кешеләр урынында без дә булырга мөмкин идек. Шуңа күрә безнең инфак кылуыбыз Раббыбыз каршында шөкер кылу бурычыбыз булып тора.

Җәнабел-Хак тәкъва бәндәләрнең сыйфатларын санаганда: «…Без ризык итеп биргән нәрсәләрдән (Аллаһ юлында) сарыф итәләр», – дип әйтә («Әл-Бәкара», 3).

Аллаһ ризалыгы өчен бирүнең гомуми атамасы булган сәдака һәм инфакның төрләре күп. Сәдака һәм инфак булганның артыгын бирүдән башлана. Һич малы-акчасы булмаган бәндә өчен исә хәтта ярты хөрмә дә күркәм сәдака санала. Сәдака биргәндәге ихласлыкка нисбәтле рәвештә бәндәне җәһәннәм утыннан саклар.

Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелекнең һәм боларның иң табигый нәтиҗәсе булган инфакның һәр мөселман өчен асыл холык сыйфатына әйләнүен теләгән Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез, бу яктан карарганда, һәр мөэминне бай дип саный, чөнки Ул үзенең хәдис-шәрифләрендә мөэминнәрнең хәерлегә өндәп, яманнан тыю, тәкбир әйтү, Аллаһның берлеген тану, кыерсытылганнарга ярдәм итү, кайгы килгәннәрне юату, мохтаҗларның күңелен күрү, юллардагы комачаулаган нәрсәләрне алып ташлау, авыруның хәлен белү һәм хәтта урынлы елмаю кебек һәртөрле изге гамәле бер сәдака хөкемендә каралуын белдергән. Шунлыктан чын байлык күңелдәге канәгатьлек белән бәйле. Һәркем үзенең канәгатьләнгәнлек дәрәҗәсенә карата бай. Күңеле бай бәндәләрнең хәтта бер елмаюы да сәдака дип саналыр, чөнки бай күңелленең елмаюы андагы мәхәббәт, тынычлык һәм эчке яктылыкны әйләнә-тирәдәгеләргә дә тарата. Чыннан да, нинди күркәм инфак була ул! Ә күңеле ярлыларны исә, киресенчә, бернәрсә дә баета алмый. Бу сүзләрне хәдис-шәриф тә раслый: «Чын байлык мал күплеге түгел, күңел туклыгы белән» (Бохари, «Рикак»; Мөслим, «Зәкят»).

Чын мөэминнәр, дигәндә, күңел байлыгы кебек илаһи нигъмәткә ия булып, инфак кылучылар күздә тотыла. Һәр мөэмин ия булырга бурычлы сыйфатлар – башкалар турында кайгыртучанлык һәм сизгер күңеллелек нәкъ менә инфакта камил чагылыш таба.

Ярмүк явында шәһид киткән Харис ибне Хишам, Икримә ибне Әби Җәһл, Ийаш ибне Әби Рәбига радыйаллаһу ганһүмнәрнең гомере никадәр гыйбрәтле! Соңгы сулышларында сусызлыктан үпкәләре кипкән килеш уттай кайнар комнарда кызганда, бу ислам каһарманнарының һәркайсы үзенә бирелгән бер чынаяк суны башкасына суза, нәтиҗәдә, үлем килгәнче, һичберсенә су биреп өлгерә алмыйлар һәм алар барысы да, бер йотым су эчә алмыйча, шәһитлек ширбәтен татый. Бер чынаяк су уртада утырып кала (Хаким, «Мүстәдрәк», III, 270). Бу каһарманнарның гамәле инфакның иң югары дәрәҗәсе – «исар» үрнәге булып тора. Ягъни мөэмин кардәшеңнең ихтыяҗын үз ихтыяҗыңнан өстен куя белү фазыйләте турында сүз бара.

Алтын тутыкмый

Күптән түгел, 2022 елның 25 ноябрендә Милли китапханәнең конференцияләр залында Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, халык шагыйре Рөстәм Мингалимнең тууына 85 ел тулу уңаеннан «Ак юллар салып уздым...» дигән әдәби-музыкаль кичә узды. Кичәнең сценарий авторы һәм режиссеры – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәрдия Сәфәргалиева иде. Мин ул кичәгә бик кызыксынып бардым. Нигә дигәндә, Фәрдия апа авторлыгында узган кичәләр бик сагынылган иде. Фәрдия апаның затлы хезмәтләре рәтендә Г.Тукай исемендәге Татар филармониясе уздырган кичәләрдән, Илһам Шакировның туган көненә багышланганнары (2013, 2014, 2018 елларда); Айрат Арслановны искә алу кичәсе (2013 ел); «Илһамият» клубының беренче кичәсе (2015 ел) дә бар. Алар барысы да матур хатирә булып күңелдә саклана.

Ә инде Р.Мингалимнең тууына 85 ел тулуга багышланган кичәгә килгәндә – А.Фәйзрахмановның, «Олы юл әйтте» циклыннан булган әдәби-музыкаль кичәләрендә (2016 елдан башлап ел саен филармониябездә уза), сәхнәдә Рөстәм Мингалим шигырьләрен яттан сөйләвен сокланып тыңлавым, шигъри юлларның күбесен күңелемнән кабатлап йөрүем, шагыйрь иҗатына чиксез кызыксыну уяткан иде. Әйе, «Барам, җиргә тоелмаслык дәрәҗәдә җиңел түгел мин...»; «Саумы әнкәй, шикәрең, чәең бармы...»; «Беләгемдә һаман салкын сәгать текелдәве каныма ишетелә...»һ. б.

Р.Мингалимне искә алу кичәсенең гамәлгә ашуы – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Зәйдулла һәм аның урынбасары И.Иксанова ярдәме нәтиҗәсе. Фәрдия апа, гадәттәгечә, сценарий язу алдыннан кичәнең герое турында мәгълүмат җыярга керешә, аның иҗатын өйрәнә башлый. Әлбәттә инде, Р.Мингалимнең китапларын сорап мөрәҗәгать итте. Соңрак шигырь сөйләүчене, берничә яшь җырчыны да тәкъдим иттем. Фәрдия апаның ул көннәрдә тырышып йөрүләре! Әйтерсең лә, ул зур залда хөкүмәт йөкләгән кичәне уздыра! Хәер, филармониядә эшләгән елларыннан ук беләм, аның өчен һәр кичә, һәр концерт «Менә дигән!» булырга тиеш.

...Көне килеп җитте. Фәрдия Сәфәргалиева әзерләгән кичәдәге җылы атмосфера күңелләрне биләп алды. Р.Мингалим шигырьләре, истәлекләре, аның сүзләренә язылган җырлар, замандашлары Рабит Батулла, Рәдиф Гаташ, шәкертләре Мөхәммәт Мирза, Газинур Морат чыгышлары шагыйрьнең иҗатын, тормыш юлын тамашачыга бәян итүдә саллы матур бизәкләрен өстәде. Әле бүген дә кичәдән калган тәэсирләр хозурында яшим. Кичәдәге чыгышлар күз алдыннан уза, күңелдә Р.Мингалимнең шигъри юллары кабатлана: «Кешеләр, Дусларым! Сөйгәнем! Тизрәк сез мине, исемемне табыгыз!»... («Билгесез солдат сүзләре); «...Үлән бүтән, яфрак бүтән, кайтмадың шул бик күптән...» («Үлән бүтән, яфрак бүтән»). Шагыйрь истәлекләреннән – әтисе кайчандыр чормага элеп киптергән катып беткән мал тиресен ваграк кисәкләргә турап, сындырып, йоннарын утта яндырып пешереп ашаулары... Ул еллардагы ачлык галәмәте... Әлегәчә тетрәндерә. Әйе, тамашачы әлеге кичәдән уйланып яшәрлек «җим» алып китте...

Алтын тутыкмый. Үз һөнәренең остасы буларак, гомере буе камиллеккә омтылган милләттәшебез Фәрдия апа Сәфәргалиева сәхнәләштергән кичәләр дә, шул алтындай, сыйфатын җуймый. Бүгенге көндә дә житез, зирәк, саф күңелле замандашыбызның гомере иҗатта уза. Замана белән бергә атлый, миллилекне югалтмый ул.

Мартта аңа 70 яшь тулды. Ул һаман да сценарийләр, шигырьләр яза, аларны һәм байтак шагыйрьләрнең шигырьләрен яттан сөйли. Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе музеена Фәрдия апаны чакырып, видеога яздырып алып мин аларны социаль челтәрләрдә дә күрсәтеп барам. Кичәләрендә катнашкан артистларның чыгышларын, анда яңгыраган җырларны, шигырьләрне тирәннәнрәк ачып бирү максатыннан, тамашачыларны сокландырган сәхнә бизәлешләренең – искитмәле видеоәртләрнең режиссеры да әле ул – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәрдия Сәфәргалиева!

Алсу ХӘКИМОВА.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

24 март – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
25 март – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
26 март – 11.00, 14.00 – «Кәҗә, сарык һ. б.» (И.Зәйниев). 18.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
28 март – «Көл» (К.Митани).
29 март – «Рәшә» (Ә.Еники).
30 март – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
31 март – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

25, 26 март – «Коппелия» (Л.Делиб).
30 март – «Лючия ди Ламмермур» (Г.Доницетти).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

24 март – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
25 март – «Аферист».
26 март – «Полиционер» (И.Зәйниев).
28 март – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци, К.Тинчурин).
29 март – «Төш» (Т.Миңнуллин).
30 март – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
31 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

24 март – «Йосыф» (Кол Гали).
25 март – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
26 март – «Микулай» (М.Гыйләҗев).
28 март – «Камыр батыр» (А.Житковский инсценировкасы).
29 март – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
30 март – «Нигез ташлары» (Т.Миңнуллин).
31 март – «Җырлап ящик» (Р.Латыйпов).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

24 март – 11.00 – «Сны Диснея» (И.Зәйниев). 18.30 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
25 март – Зур залда – «Приключения барона Мюнхгаузена» (Р.Э.Распе). Кече залда – «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай).
26 март – Зур залда – «Волк и семеро козлят» (Э.Гыйлемханова инсценировкасы). Кече залда – «Котбетдин маҗаралары» (Н.Гернет).
28 март – Фойеда – «Тыпырдык» (И.Зәйниев). Зур залда – «Маугли» (Р.Киплинг).
29 март – «Маугли» (Р.Киплинг).
30 март – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
31 март – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк әкияте буенча).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 март – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).
25 март – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
26 март – Җырчы Вил Усмановның юбилей концерты.
27 март – «Ромео һәм Джульетта» балеты (С.Прокофьев).
30 март – Фортепиано музыкасы концерты. Уйный Филлип Руденко.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

25 март – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрының композитор С.Рахманиновның 150 еллыгына багышланган концерты. Дирижер – Александр Сладковский, солист – Константин Емельянов.
27 март – La Primavera камера оркестрының Казан хосписына ярдәм йөзеннән оештырылган хәйрия концерты.

Йокы серләре

Академик Иван Павлов фикеренчә, йокы – баш мие ярымшарлары кабыгының эшчәнлеге туктап тору ул. Материалист галимнәр раславынча, йоклаганда баш мие көн буе үзләштергән мәгълүматны эшкәртә, анализлый. Йокыга китеп, бик озак уянмау мисаллары да бар. Норвегиядә Августа Ленгард уянмыйча 22 ел буе йоклый, ә Америкада Патрисия Магупра 18 ел уянмыйча йоклаган җиреннән үлеп китә. Баш мие комасының һәм мәрткә китүнең уртак сыйфаты – икесенең дә яшәү белән үлем арасындагы халәт булуы. Аермасы: кома – авыру нәтиҗәсе, ә мәрткә китү (летаргия) баш миенең көчле стресска, коточкыч курку хисе кичерүгә яки артык каты хәлсезләнү-йончуга карата реакциясе. Кома күп елларга сузылырга мөмкин, ә мәрткә китү гадәттә 2 атнадан артмый, авыру кеше йоклаган җиреннән җан тәслим кыла. Иң озак команы Элен Эспозито кичерә. 6 яшьлек чагында сукыр эчәгенә операциядән соң комага китеп, ул айнымый һәм 43 яшендә генә бакыйлыкка күчә – аңсыз килеш 37 ел да 111 көн ята. Ире белән талашканнан соң Наталья Лебеденко “йокы” га тала һәм 20 елдан соң гына уяна. Даһи физик Лев Ландау автомобиль һәлакәтеннән соң берничә атна аңсыз ята. Аңына килгәч, шәхес буларак сакланып калса да, физик-теоретик талантын тулысынча югалта. Беренче бөтендөнья сугышында мажар солдаты Поль Кернның чигәсенә пуля тия, баш мие җәрәхәтләнә, шулай да ул исән кала, әмма калган гомерен – 40 елны – бер дә йокламый үткәрә һәм моны бик җиңел кичерә. Америка галиме Натаниэл Клейтман, биологик сәгатенең Кояш яктысыннан башка нишләячәген сынау өчен, бер айга караңгы мәгарәгә күченә: әмма организмы үзе күнеккәнчә – һаман шул 24 сәгатьлек цикл белән яшәвен дәвам итә.

(“Лента.ру”).

Айсберг та шартлый белә

Кайчак диңгезчеләр гаҗәеп күренешнең шаһите була – океан киңлекләрен ярып бара торган галиҗәнап боз тавы кинәт шартлый! Эш нәрсәдә соң? Яңа гына яуган карда һава бик күп, тыгызланганда, ул айсбергның эчендә җыела һәм, андагы ярыклар аша, әкренләп тышка чыгып тора. Әгәр инде боз тавының ярыклары юк икән, һава айсберг эчендәге бушлыкта туплана, анда бик каты басым астында кала. Җылырак урынга күчкәндә, айсберг эри башлый, бушлыктагы һава киңәя һәм боз тавын шартлата.

(“Вокруг света”).

Яшел күзлеләр сирәк

Планетабызда яшәүчеләрнең күбесенең күзе коңгырт-кара төстә. Статистика буенча, Җир халкының нибары 2 процентының гына күзе яшел икән. Күзнең төсе организмдагы меланин микъдарына бәйле, яшел күзләрдә ул азрак, коңгырт-караларда – күбрәк. Урта гасырларда инквизиторлар җирән чәчле, яшел күзле никадәр кызны убырлы дип учакта яндырган! Яшел күзлеләр күнчыгыш һәм көнбатыш славян халыкларында, бигрәк тә немецлар һәм шотландиялеләр арасында күп. Шулай ук Исландия халкының 80 проценты яшел яки зәңгәр күзле. Төркиядә яшәүчеләрнең 20 процентының күзе яшел. Ә менә Көньяк Америка һәм Азия илләрендә яшел күзлеләр сирәк очрый.

(“The Mirror”).

Тирләү түгел, сулау ябыктыра

Шактый кеше, никадәр күбрәк тирләгән саен, шулкадәр күбрәк май югала, дип саный. Кайбер табибләр исә, физик күнегүләр ясаганда, организмдагы май җылылыкка яки энергиягә әйләнә, дип уйлый. Әмма Австралиядәге Яңа Көньяк Уэльс университеты галимнәре моның ялгыш фикер булуын исбатлаган. Тикшеренү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, без майны сулап чыгарабыз икән. 10 килограмм майның 8,4 килограмм углекислый газга әйләнүе дәлилләнгән, ул тәннән сулыш һәм 1,6 килограмм су (бәвел, тир, күз яше) сыйфатында чыга. Тикшеренү нәтиҗәләре буенча, 10 килограмм майдан котылу өчен, кешегә 29 килограмм кислород суларга (һәм шул арада 94000 калория яндырырга) кирәк. Мондый реакция вакытында 28 килограмм углекислый газ һәм 11 килограмм су барлыкка килә.

(“Fishki.net”).



Көн саен – 20 мең

Кытайның Хэнань провинциясендге Лаоцзюнь тавындагы бик матур урында галәмәт зур фуд-корт урнашкан. Биредәге 100 ашчы һәм 400 хезмәткәр көн саен якынча 20 мең туристны сыйлый. Әлеге бик популяр туклану зонасы кичке сәгать 5 тә ачыла һәм төнгә кадәр эшли.

Сигез кешелек өстәлләрдә туристларның бер партиясен икенчесе өзлексез алыштырып кына тора. Биредә нибары 10 юаньлык (100 сум чамасы) комплекслы әбәт әзерләнә, аңа 10 төрле ризык, шул исәптән тәмле аш һәм кыздырылган ит белән балык та керә.

(“Интересно.cc”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

27 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+
10.00, 23.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.35, 17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Ватандашлар». 16+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «У ВАС БУДЕТ РЕБЕНОК». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «МИЛЛИОНЕР». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПЕРЕЕЗД». 12+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «48 ЧАСОВ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
15.30 «Всегда на страже!» 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.40 «Большая игра». 16+
23.40 «ПОЧКА». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Царица Небесная. Феодоровская икона Божией Матери».
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Колчак.
7.35, 18.35 «Жозефина де Богарне. Любовь Наполеона».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.25 «МЕЛОЧИ ЖИЗНИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Откройте занавес».
12.25 «Забытое ремесло».
12.40 Линия жизни. Эра Зиганшина.
13.45 «Юрий Гагарин. Звёздный избранник».
14.15 Уроки режиссуры. «Как актеру стать режиссером».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
17.35 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова. «Колокола». Симфоническая поэма для солистов, хора и оркестра. Дирижер Роберт Тревиньо.
18.20 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Хранители жизни. Боткин».
21.25 «Сати. Нескучная классика...»
22.10 «СТАРОМОДНАЯ КОМЕДИЯ».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Сишәмбе

28 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+
10.00, 23.30 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ». 12+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Теймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00, 22.10 «Трибуна Нового Века». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Ватандашлар». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «У ВАС БУДЕТ РЕБЕНОК». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПЕРЕЕЗД». 16+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись».
7.35, 18.35 «Лоренцо Медичи. Некоронованный король Флоренции».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «СВОЕ СЧАСТЬЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Свешников».
12.10 Цвет времени. Леон Бакст.
12.30 «СТАРОМОДНАЯ КОМЕДИЯ».
14.05 Дороги старых мастеров. «Древо жизни».
14.15 Уроки режиссуры. «Моё сценическое пространство».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Три революции Максима Горького».
17.40 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова. Концерт №3 для фортепиано с оркестром. Дирижер Валерий Гергиев. Солист Денис Мацуев.
18.25 Цвет времени. Рене Магритт.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 Искусственный отбор.
21.20 Линия жизни.
22.10 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Чәршәмбе

29 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+
10.00, 23.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00 «Спортивная среда». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Ватандашлар». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «У ВАС БУДЕТ РЕБЕНОК». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПЕРЕЕЗД». 12+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.00 «ОСКОЛКИ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись».
7.35, 18.35 «Мария-Антуанетта, последняя королева Франции».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ПЕРЕД ЭКЗАМЕНОМ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Там, где зимует весна...»
12.00 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
12.30 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА».
14.05 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
14.15 Уроки режиссуры. «Как я выбираю литературный материал».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 К 95-летию со дня рождения Валентина Берестова. Писатели нашего детства.
15.50 «Белая студия».
17.40 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова. Избранные романсы. Мария Гулегина и Александр Гиндин.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.25 Власть факта. «Германский мир на рубеже эпох».
22.10 «ПОСЛЕСЛОВИЕ».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Пәнҗешәмбе

30 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+
10.00, 0.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.10 «Соотечественники». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.05, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПЕРЕЕЗД». 12+
14.30 «Реки России». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ШПИОН». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.

9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись».
7.35, 18.35 «Вильгельм Завоеватель. Герцог Нормандии на английском троне».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 К 75-летию Владимира Винокура. XX век. «В кругу друзей с участием Владимира Винокура».
12.25 «ПОСЛЕСЛОВИЕ».
14.00 «Забытое ремесло».
14.15 Уроки режиссуры. «Наш учитель - Женовач. Мы - Женовачи».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Гардероб Петра I».
15.50 Острова. Валерий Золотухин.
17.40 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова. Симфония №2. Дирижер Евгений Светланов.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Юрий Козлов. «Белая вода».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Тайна двух океанов». Иду на погружение!»
21.25 «Энигма. Макс Эмануэль Ценчич».
22.10 «ЛЮБИМАЯ ЖЕНЩИНА МЕХАНИКА ГАВРИЛОВА».
23.30 Цвет времени. Эль Греко.

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15, 0.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Җомга

31 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
23.10 «ОПАСНЫЙ ЭЛЕМЕНТ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «48 ЧАСОВ». 16+
11.30 «БЕДНЫЕ РОДСТВЕННИКИ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТО ВМЕСТЕ». 12+
14.35 «Реки России». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Иннокентий Смоктуновский. Пророчество для гения». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Моя мелодия». 12+
23.45 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Театральная летопись».
7.35 «Хранители жизни. Боткин».
8.15 Цвет времени. Рене Магритт.
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.25 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ».
10.20 «АРШИН МАЛ АЛАН».
11.55 Открытая книга. Юрий Козлов. «Белая вода».
12.25 «ЛЮБИМАЯ ЖЕНЩИНА МЕХАНИКА ГАВРИЛОВА».
13.45 «Забытое ремесло».
14.05 85 лет со дня рождения Сергея Бархина. Линия жизни.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Макс Эмануэль Ценчич».
16.15 Цвет времени. Марк Шагал.
17.30 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова.»Остров мёртвых». «Симфонические танцы». Дирижер Юрий Башмет.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Чистая правда барона Мюнхгаузена».
20.40 «МОЙ МЛАДШИЙ БРАТ».
22.15 «2 Верник 2».
23.30 «ОБЛЕПИХОВОЕ ЛЕТО».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «СТРАЖНИК». 16+
22.15 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА». 16+

Шимбә

1 апрель. «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Ватандашлар». 16+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
14.30 «Халкым минем...» 12+
15.00 «Наша Республика - наше дело». 16+
16.00 «Уроки истории». 6+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.25 «БЕГЛЕЦЫ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 14.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Рөстәм Абязов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.15 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Су буенда учак яна». 6+
17.15 «Мәхәббәт чишмәләре». Зәһрә Шәрифуллина җырлый. 6+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Акча корты». «Мунча ташы» спектакле. 16+
23.25 «СИНА КАЙТАМ». 16+

«ЭФИР»

5.00, 14.35 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Библейский сюжет». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ЛЮБОВЬ В РОЗЫСКЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «Кто следующий, мечтатели?» 12+
15.00 «Блин. Ком». 16+
15.30 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВЕК АДАЛИН». 16+
22.50 «ТАНЦЫ НА ГРАНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 3». 12+
16.35 К 75-летию Владимира Винокура. 16+
18.20 «Первое апреля как повод для улыбки». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «МАДАМ ПАРФЮМЕР». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «ПРИНЦЕССА И НИЩЕНКА». 16+
15.05 «Аншлаг и Компания». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ИЗ ЗАМКНУТОГО КРУГА». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Тайна третьей планеты».
7.55 «МОЙ НЕЖНО ЛЮБИМЫЙ ДЕТЕКТИВ».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «АЛЕКО».
11.15 Земля людей. «Ульчи. Охота жить».
11.45 «Эрмитаж».
12.15 «Даты, определившие ход истории».
12.45 «Ну, погоди!»
14.00 «Ярославль. Замок Никиты Понизовкина».
14.30 «Эти огненные фламинго. В мире красок и тайн».
15.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.25 «Петр Барановский. Хранитель храмов».
16.55 «ДУЭНЬЯ».
18.30 «Возвращение в Ивановку».
19.45 «Именем Рахманинова...»
20.45 «ЛЕВ ГУРЫЧ СИНИЧКИН».
22.00 «Агора».
23.00 150 лет со дня рождения Сергея Рахманинова. Валерий Гергиев, Денис Мацуев и Российский национальный молодёжный симфонический оркестр.

«НТВ»

5.05 «Жди меня». 12+
5.50 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Страна талантов». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

2 апрель. «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 Виталий Агаповның юбилей концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». Искәндәр Биктаһиров. 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Татар сүзе».
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00, 0.35 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ОДИНОКАЯ ЖЕНЩИНА ЖЕЛАЕТ ПОЗНАКОМИТЬСЯ». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Татар халык җырлары». 6+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 Фердинанд Сәлаховның юбилей кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Музыкаль мәйдан». 16+
13.40 Спектакль «Зәйтүнәкәй». 16+
15.05 «Мин бәхетле». Ришат Төхфәтуллин концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 Спектакль «Җилкәнсезләр». 16+

«ЭФИР»

5.00, 14.35 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Библейский сюжет». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «ВСПОМИНАЯ ТЕБЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КАВКАЗСКАЯ ПЛЕННИЦА». 12+
15.00 «Блин. Ком». 16+
15.30 «Первые в мире». 12+
15.45 «ЛЮБОВЬ В РОЗЫСКЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДОМ У ОЗЕРА». 16+
22.35 «КТО СЛЕДУЮЩИЙ, МЕЧТАТЕЛИ?» 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Все хотят летать». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 Ледовое шоу «История любви Шахерезады».
13.55 К 90-летию Александра Митты. «О любви, компромиссах и предчувствиях». 12+
14.50 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА».
16.40 «Век СССР». «Запад». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «На футболе с Денисом Казанским». 18+

«РОССИЯ»

6.00 «ПРОСТАЯ ДЕВЧОНКА». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «ПРИНЦЕССА И НИЩЕНКА». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
8.05 «СЕЛЬСКИЙ ВРАЧ».
10.00 Диалоги о животных.
10.40 «КУЛЬТПОХОД В ТЕАТР».
12.10 Письма из провинции.
12.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Генрих Шлиман.
13.10 «Дюймовочка».
13.40 «Игра в бисер» «Х.К. Андерсен. Сказки».
14.20 «Коллекция».
14.50 «ДАЧНИКИ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.30 «Пешком...»
18.00 «Львиная доля».
18.30 «Возвращение в Ивановку».
19.30 Новости культуры.
20.10 «БЕЗЫМЯННАЯ ЗВЕЗДА».
22.25 К 150-летию со дня рождения Сергея Рахманинова. Валерий Гергиев, Денис Мацуев и Российский национальный молодёжный симфонический оркестр.
23.55 «ЛЮБОВНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ МОЛЛ ФЛЭНДЕРС».

«НТВ»

5.00 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.40 «Звезды сошлись». 16+

Алдаркараклар кармагына эләгү өчен күп кирәкми. Хәзерге вакытта алар күбрәк читтән торып, ягъни телефон, интернет аша кәсеп итә, әмма күзгә карап талаучылар да җитәрлек. Тукай районының Сәет авылында яшәүче күп санлы гаилә шундыйларның берсенә ышану нәтиҗәсендә ата-бабай нигезеннән колак кага, чынлыкта, тораксыз кала.

Сәет авылында сәер хәлләр

Вакыйганың сәбәбе ачык булса да, сәер яклар да бар монда. Әйтик, дөнья күргән, инде берничә тапкыр авызы пешкән, мошенникның фаш ителәчәге ачык булган җинаятькә баруы гаҗәп тоела. Хәер, бусын мондый затларга хас комсызлыкны йөгәнли алмау дип бәяләргә кирәктер. Ә менә зарар күрүчеләрнең кәкре каенга терәтелүләре мәгълүм килеш дүрт ел буе эндәшми торулары аңлашылмый.

2021 елның апрелендә алар өенә адвокат В.Журавлев (кайбер исемнәр үзгәртелә) килә һәм 1972 елгы Г. Гайнетдинованы аптырашта калдырган хәбәр ирештерә, ягъни йорт һәм җир кишәрлегенең 2017 елда ук Алия атлы хатын-кызга сатылуын, аның исеменә теркәлүен, димәк, аларга күчемсез милекне калдырып китәргә кирәклеген әйтә. Без беркая да китмибез дип озатып җибәрәләр аны. Гаиләнең барыр урыны да булмый бит.

Г. Гайнетдиновага әлеге мөлкәт мәрхүм әтисеннән кала. 2016 елда аны 1994 елгы кызы Илмира Гарданова исеменә күчерә. Адвокат килгән вакытта анда җәмгысы 8 кеше, Гүзәлия ханымның 28 яшьлек улы, ире Айнур, дүрт баласы белән кызы Илмира гомер итә. Соңрак мәгълүм булганча, өй һәм җир алдан И. Хәбибдияров дигән Чаллы кешесе мөлкәтенә әверелгән, аның тарафыннан сатып җибәрелгән булып чыга.

Сәер вакыйга Сәеттә генә түгел, район күләмендә шаукым куптара. Авылдагы «Ирек» җәмгыяте житәкчесе бу хакта район хакимияте башлыгы Ф. Камаевка да җиткерә, аның кабинетында үткәрелгән киңәшмәдә күчемсез милекнең законлы хуҗасының вәкиле В. Журавлев, районның теләсә кайсы төбәгендә шәхси йорт салу өчен башка кишәрлек бирелсә, килешүгә барырга, ягъни Сәеттәге мөлкәтне калдырырга риза икәнлекләрен белдерә. Сәмәкәй авыл җирлеге башлыгы А. Усмановка әлеге мәсьәләне хәл итү йөкләнә, ләкин анда алмашка бирердәй кишәрлек булмый.

Әлбәттә, тикшерү эшләре башлана һәм чуалган йомгакның очы риэлтор Ирек Тимергалиевтә икәне тиз ачыклана. Шулай да тикшерү озакка сузыла, чөнки бу чорда шома бәндәнең Чаллыда кылган шундый ук галәмәтләре өйрәнелә, суд утырышлары бара. 1980 елгы ошбу ир-атны һөнәри мошенниклар рәтенә куймыйча булмый. Мөслим районында туып үскән Ирек моңа кадәр дә алдаркараклыклары өчен Азнакай, Бөгелмә, Чаллы шәһәрләрендә хөкем ителә, шартлы рәвештә иректән мәхрүм ителү, мәҗбүри эшләр, штраф кебек җиңелчә җәзалар белән котылып килә. Соңрак Чаллыда ныклап килеп каба, ике мошенниклыгы өчен җинаять эше кузгатыла. Тикшерү барышында аның хокук вә мәнфәгатьләрен безгә мәгълүм шул ук адвокат яклый. Файдасы тими, Тукай районында ыгы-зыгы барган чорда Чаллы суды И. Тимергалиевне 5 ел да 10 айга колониягә озатырга дигән карар чыгарып куя.

Сәеттәге явызлыклар буенча җинаять эше бер ел узгач, ягъни былтыр җәйдә генә кузгатыла. Тикшерү барышында ачыклanganча, 2016 елның көзендә Г. Гайнетдинова һәм И. Гарданова автобус тукталышына ябыштырылган игълан белән танышалар. Анда ана капиталын акчага әверелдерергә ярдәм күрсәтү тәкъдим ителә. Аналы-кызлылар әлеге мөмкинлектән файдаланырга, әйтүләренчә, 400 мең сум чамасы акчаны иске өйләрен төзекләндерүгә тотарга, димәк торак шартларын яхшыртырга ниятлиләр. Шул рәвешле, алар игъланда күрсәтелгән адрес буенча Чаллыга барып, ишегенә «Туган як» дигән язма эленгән офиска кереп, риэлтор Ирек Тимергалиевкә мөрәҗәгать итәләр. Анысы, кәгазьләр белән танышканнан соң, моның өчен әни кеше исемендәге йортны бер түбә астында яшәүче кызына сатарга, исәп-хисапны ана капиталы белән ясарга кирәк булачагын әйтә, ягъни әлеге акча Г. Гайнетдиновага күчәргә тиеш була. Ошбу мәшәкатьле эш өчен риэлтор 30 мең сум сорый.

Шуннан соң И. Тимергалиев авыл кешеләрен барып ала, тиешле оешмаларга йөртә, барысын да үзе эшли, клиентларга документларга кул куярга гына кирәк була. Тәмам ышанычны яулаган кеше кушканнарны күндәм рәвештә үтәү, иң әүвәл, кәгазьләрне укып та тормыйча имза сырлаулар хәлиткеч роль уйный да инде.

Эшләр майлаган кебек бара. Пенсия фондыннан ана (гаилә) капиталы сертификаты алынгач, «Камкомбанк» офисында И. Гарданова кредит (ипотека) килешүе төзи, төгәлрәге, кул куя, аңа әлеге акчаны күчерү өчен банк картасы бирелә. Риэлтор кушуы буенча Г. Гайнетдинова да Саклык банкы картасы ала, ахырда акча шунда, сатучы счетына килергә тиеш була бит. Ни хикмәт, хатын-кызлар банк карталарын И.Тимергалиевтә калдыралар. Нәтиҗә буларак, 2016 елның октябрь аенда И. Гарданова картасына килгән 453 026 сумлык ана капиталы банкоматларда аз-азлап кәгазь акчага әйләндерелеп мошенник кесәсенә керә.

Аналы-кызлылар И. Тимергалиев белән нотариаль конторапарда була, иң хәтәре, аның исеменә «генераль» дип тамгаланган ышаныч язуы бирәләр.

Риэлтор, чынлыкта, Сәеттәге күчемсез милекнең хуҗасына әверелә. Акча таләп иткән хатын-кызларны ана капиталы килмәгән әле дип алдый, тора-бара шалтыратуларга җавап бирми башлый. Чөнки бу арада җир һәм өйне танышы И. Хәбибдияров исеменә теркәү һәм башка законсыз гамәлләр кылу белән мәшгуль була.

Илнур Хәбибдияров шул елларда аңа ана капиталы хисабына торак алу мәсьәләсе белән мөрәҗәгать иткән була, әйтүенә караганда, шуннан соң Тимергалиев биргән реклама белдерүләрен Чаллыда һәм башка төбәкләрдә ябыштырып йөрүче булып эшли, күп тапкырлар ышаныч язулары бирдем, сорашып тормыйча ул биргән кәгазьләргә кул куйдым, ди ул. Күрәсең, риэлтор караңгы эшләрендә аны да файдаланган, Сәеттәге күчемсез милекнең аңа күчүе дә раслый моны. Берничә ел узып, әлеге хәл калкып чыккач, биргән күрсәтмәләрендә бу хакта полиция хезмәткәрләреннән генә ишеттем, Сәет авылында булмадым, йортта яшәүчеләрне күрмәдем дип үзен агартып сөйли ул. Шул ук вакытта аннан сатып алучы Алия Хәйдәрова авылга Хәбибдияров һәм ирем белән өчәүләп бардык, идәндә аяк киемнәре аунап яткан тәртипсез өйгә кермәдем, ишекне ачкач та начар ис бөркелгәч, кире борылдым, анда кешеләр юк иде, ди. Шунысы хак, теркәү палатасында эшләр тәмамлангач та, соңрак базар бәясе 1 млн 80 мең сум дип белдерелгән күчемсез милек өчен килешенгән 900 000 сумны хуҗага, ягъни И. Хәбибдияровка бирә ул. Моны Илнур да раслый, акчаны тулысынча Ирек Тимергалиевкә тапшырдым, ди. Димәк, мошенник Сәет кешеләрен төп башына утыртып, ана капиталын да кушкач, барлыгы 1353 026 сум керем ала. 2016 елда җирле хуҗалык җитәкчесе Р. Хаҗиев шалтыратып, кискен рәвештә сөйләшкәч, Сәеткә өч мәртәбә килеп китә ул һәм хуҗаларга нибарысы 20 мең сум акча калдыра.

Шулай итеп, 2017 ел башында ук йорт һәм җир кишәрлеге чит кешегә күчә. Бу җәһәттән, 400 мең сум тирәсе акчаларыннан колак кагуларын белә торып та, аналы-кызлыларның 2021 ел язына чаклы чаң какмаулары кабат гаҗәпләндерә. Бу гаилә турында начар сөйләүчеләр дә юк авылда, бар да исерткеч эчемлекләр эчмәвен искәртә. Олырак ике малай башка авылдагы коррекция мәктәбендә укый, кечерәк кыз белән малай Сәмәкәйдәге балалар бакчасына йөри. Шулай да барысы да тәртиптә түгелдер кебек, чөнки гаиләнең 2021 елда районның балигъ булмаганнар эшләре комиссиясендә исәптә торуы да мәгълүм. Хокук саклау органнарында авылдашлар биргән уңай бәяләмәләрне тулысынча кире кагулар да бар.

Яңа хуҗа салымнарны түләп баруын, коммуналь хезмәтләрне үзенә күчермәвен әйтә, анда кемнәр яшәгәнен белмәдем, ерак шәһәргә күченергә җыенгач кына сатып китәргә уйладым, ди. Ул чакта үзе дә риэлтор булып эшләгән кешенең шундый проблемалы мөлкәткә акча сарыф итүе гаҗәп үзе. Күрәсең, әлеге эшкә И. Тимергалиевнең катнашы булуы турында әйтмәсә дә, ул да хезмәттәшенә ышану аркасында мәшәкатьле булган дияргә генә кала.

Инде ирегеннән мәхрүм ителгән И.Тимергалиев законсыз гамәлләрен тулысы белән таный. Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Данияр Мөхәммәдиев аның җинаятен ике өлешкә бүлә. 453 меңлек ана капиталын кесәсенә шудыруын зур күләмле урлау, ә йорт һәм җир кишәрлеген сатуын кешеләрне торакка хокукыннан мәхрүм итеп кылынган мошенниклык дип бәяли. И. Тимергалиевкә ике җинаятьтә гаепләү белдерелгән эш ноябрь аенда Тукай районы судына тапшырыла. Димәк, Минзәләдәге тикшерү изоляторында утыручы мошенникны тагын бер хөкем көтә. Эш моның белән генә дә бетмәс кебек. Чөнки И. Тимергалиевнең шундый ук башка гамәлләре тикшерелә, мәсәлән, Минзәләдә кылган алдаркараклыгы буенча яңа җинаять эше кузгатылу мөмкинлеге бар икән.

Тикшерү комитетында кайбер зарар күрүчеләрнең тырышып-тырышып та мөлкәтләрен кире кайтара алмавы сәбәпле, Тимергалиевнең күләгәдә калган җинаятьләре булу ихтималын да әйтәләр. Эш шунда ки, мошенник кармагына эләгүчеләр полициягә мөрәҗәгать итсә дә, анда, кагыйдә буларак, җинаять составы юк дигән карар чыгарыла, мәсьәләне гражданлык законнары нигезендә судта хәл итәргә тәкъдим ителә. Ә анда исә, полициядәге кебек үк, мошенник кармагына эләгүчеләр кул куеп раслаган документлар буенча фикер йөртелә. Димәк, уңышка ирешү мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә.

Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Р.Т. Билданов бу очракта Сәет кешеләрен яклаучылар табылу, иң әүвәл, искечә әйткәндә, хуҗалык рәисе Р.Хаҗиев аларны «җитәкләп» дәүләт оешмаларына йөртүе коткара дип саный. Әлбәттә, эшнең тикшерү комитеты карамагына эләгүнең әһәмияте бәхәссез. Ә бу исә Тимергалиевнең ана капиталын, димәк, балаларга дигән акчаны урлавы нәтиҗәсе. Эш зурга киткәч, Тимергалиев җәзаны йомшарту йөзеннән, әлеге матди зыянны кайтара. Иң мөһиме, йорт һәм җир яңадан элеккеге хуҗалар исеменә теркәлә, чөнки сатып алучы Алия Хәйдәрова аларны кире кайтарырга була, ягъни бүләк итү турындагы рәсми килешү төзи. Моны элеккеге хезмәттәше И.Тимергалиевнең 900 мең сумны түли башлавы белән аңлата. Тикшерү комитетында исә без телгә алган кешеләр И.Тимергалиев белән бергә, төркем белән кәсеп иткәннәр, моны дәлилләп кенә булмый, диләр.

Йомгаклап шуны искәртик, кешене тораксыз калдыручы «кара риэлторлар» бар. Ошбу «хезмәтчеләре» белән эш иткәндә, бик сак булырга кирәк.

Наил ВАХИТОВ.

ПОРТФЕЛЬЛЕ АФЕРИСТ

Казанда аферист йөри. Шома егеткәйне кулындагы портфеленнән танып була. Шул портфеленнән өркеп, бөтен халык аферист тирәсендә бии. Сүз К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Портфель» пьесасына нигезләнеп Илфак Хафизов язган инсценировка буенча Илнур Гарифуллин куйган «Аферист» исемле премьера турында бара.

Язучы, галим Нәкый Исәнбәтнең исеме көннән-көн ныграк сокландыра. Ул фәнни эшчәнлеге белән генә түгел, төрледән-төрле жанрда иҗат ителгән әдәби әсәрләре белән дә мәдәниятебез тарихына керде. Н.Исәнбәтнең беренче сәхнә әсәрен 13 яшендә язуы мәгълүм. Гражданнар сугышы елларында, сәхнәгә куяр өчен яңа әсәрләр кирәк булгач, авылдашлары, язу сәләтен белеп, Нәкыйга килә. Аларның гозерен үти-үти, язучы шундый остара ки, 1930 елларда аның искене җимереп, өр-яңа мәдәният булдырырга хыялланучы пролеткультчылардан көлеп иҗат ителгән «Культур Шәңгәрәй», нэпманнарны фаш иткән «Пикуләй Шәрәфи»е, ришвәтчелек, казна малын туздыру, эшнәлек, куштанлык темаларын күтәргән «Портфель» пьесалары зур сәхнәләргә менә. Алар авторга сөенеч тә, бер үк вакытта көенеч тә була. Уфада, мәсәлән, «Портфель» спектакленнән соң матбугатта зур җәнҗал куба. Шуннан китә «җидегәнчелек»тә гаепләүләр... Әмма язучы бернигә дә карамыйча, һәр чорга сәхнә әсәрләре аша үзенең карашын белдерергә көч таба. «Спартак» трагедиясен, «Болак арты республикасы»н, Бөек Ватан сугышы турында «Мәрьям» драмасын, ханнар заманына кайтып, «Түләк батыр» либреттосын, «Сәхипҗамал Волжская» пьесасын, «Мулланур Вахитов» драмасын, «Муса Җәлил» трагедиясен, «Хуҗа Насретдин» комедиясен, «Идегәй» драмасын, балалар өчен «Кырлай егете»н һ.б. иҗат итә. Бу әсәрләрнең исемнәре үк Исәнбәтнең заманга битараф булмавын күрсәтә.

«Н. Исәнбәт драма жанрларының һәртөрлесеннән күренекле әсәрләр бирде, – дип язган танылган актерыбыз Габдулла Шамуков. – Ул көлке, үткен комедияләр, тирән дулкынландыра торган драмалар, рухы тетрәтә торган трагедияләр тудырды. Профессиональ осталыкка ия булу ягыннан без аны татарның иң зур драматургларының берсе дисәк тә ялгышмабыз. Нәкый Исәнбәтнең һәрбер драматик әсәре дип әйтерлек үткен конфликтка корылган, һәрбер әсәрендә фикерләр, характерлар бәрелеше күрсәтелә. Бай драматургик материал нигезендә актив хәрәкәт итүче характерларның бәрелеше аша кызыклы спектакль туа... Гомумән, Н.Исәнбәтнең драматургиясе, бигрәк тә аның үткен итеп язылган комедияләре, Татар дәүләт академия театрының иҗат йөзен билгеләүдә төп рольне уйнады дияргә кирәк. Аның драматургиясе бик күп артистларыбызга үзләренең сәхнә талантларын җәелдерергә бай материал булып хезмәт итте. Бүгенге көндә халкыбыз алдында танылган зур сәхнә осталарыбызның шактый өлеше, күбесенчә, Н. Исәнбәт тудырган яңадан-яңа катлаулы характерларны сәхнәдә гәүдәләндерү аша үсте».

«Аферист» спектаклендә вакыйгалар кечкенә генә Камышлау шәһәрендә бара. Биредә барлык җитәкче вазыйфалар да кешенең сәләтенә, казанышларына карап түгел, ә туганлык һәм кода-кодагыйлык буенча бүленгән. Көтмәгәндә прокурорның килеп чыгуы шәһәр башлыгын һәм аның эшнәләрен хафага сала. Күптән түгел генә «Идегәй» спектаклендә Идегәй ролен башкарган Илнур Гарифуллинның бүген режиссер вазыйфасында көч сынавы театрның баш режиссеры Туфан Имаметдинов белән дуслыгы сәбәпле генә түгел, Нәкый аганың иҗатына мәхәббәтеннән дип уйлыйсы килә. Ул вакыйгаларны хәзерге заманга күчергән, чөнки ришвәтчелек, эшнәлек, куштанлык, казна малын туздыру темалары яңарганнан-яңара гына бара сыман. Сәхнәдә хатыннар солярийга йөри, Татарстан гимны, «Бәхеттә-шатлыкта» җыры яңгырый, радиоидарәле квадрокоптер очып йөри һ.б. Күренеш саен, кирәксә-кирәкмәсә дә, рус сүзләрен кыстырулары гына колакны яра, күңелне тырный. Илнур үзе Тинчуринга рус ТЮЗыннан килсә дә, татар театрында үзебезнең татар артистлары катнашындагы спектакль ләбаса! Рольләрдә Илфак Хафизов, Алмаз Фәтхуллин, Зөлфәт Закиров, Альбина Гашигуллина, Зөлфия Вәлиева, Рөстәм Гайзуллин, Диләрә Фәттахова, Айдар Фәтрахманов, Булат Зиннәтуллин катнаша. Прокурор, табиб, полиция, ЗАГС хезмәткәрләре рольләрен Ренат Шәмсетдинов башкарып, сатирик комедиягә хас булмаганча сүлпән һәм берникадәр таркау барган спектакльгә җан кертә.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазадаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 24.03.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2610

16+